Бер төркем галимнәр иҗат иткән Татарстан тарихына кагылышлы басмадагы әлеге темага багышланган сәхифәдә үзәктән иңдерелгән репрессияләү буенча план күрсәткечләрен арттырып үтәү, ягъни башка төбәкләрдән калышмау, ә бәлки узып та китүдә җирле җитәкчеләр аеруча өлгерлек күрсәткәннәр, диелә. Татарстан АССРына 1937 елгы разнарядка буенча, 500 кеше беренче категория (ягъни атып үтерергә) һәм 1500 кеше икенче категория (мәҗбүри читкә сөрү) билгеләнгән булса, республика җитәкчелегенең чамадан тыш тырышлыгы нәтиҗәсендә 2196 кеше атып үтерелгән. 1938 елда, дип яза галимнәр, массачыл террор отыры көчәйгән. 9–11 майда республикада СССР Югары Судының күчмә сессиясе эшләгән. Шушы өч көндә генә дә ике йөзгә якын кеше үлемгә хөкем ителгән.

Ә гомумән алганда, 1929 елның ноябреннән алып 1938 елга кадәр ТАССР ОГПУ-НКВД каршында эшләүче «өчлекләр» карарлары белән, сәяси сәбәпләр буенча, 17119 кеше хөкемгә тартылган, шуларның 2977се атып үтерелгән.

Хакыйкать хакына, болардан тыш, диелә китапта, «дело»ларның күпмедер өлеше Мәскәүгә юлланып һәм алар СССР ОГПУ-НКВД коллегиясенең гадәттән тыш киңәшмәләрендә һәм Эчке эшләр халык комиссары белән СССР прокуроры катнашындагы «икелек»тә каралып, хөкем чыгарылган. Әлбәттә, «корыч юлбашчы» көйләп җибәргән тегермән ташларының никадәр адәм башын тартканлыгы турында мәгълүмат юк.

Тарихчылар шулай ук Татарстан «Хәтер Китабы» редакциясе китергән саннарны да күрсәтә: ТАССРдагы төрле репрессив органнар тарафыннан 5687 кеше атып үтерелгән булып күренә (105–108 бб.) [Галлямова: 2014].

Бу мәсьәлә буенча эзләнүләр язучы һәм гыйлем иясе, үз җилкәсендә «халыклар атасы»ның золымын татыган фидакяр Адлер ага Тимергалин иҗатына мөрәҗәгать итүгә этәрде. Тулы бер институт башкарырлык өч томлы «Миллият сүзлеге»ндә әдип искәртә: «1930–1953 елларда ГУЛАГ системасы аркылы 5 миллионнан алып 9 миллионга кадәр кеше үткән, шуларның 1,3–3,7 млн кадәресе сәяси гаепләнүчеләр булган» [Тимерга-

лин: 2016. 1 т.]. Шул ук сүзлекнең өченче томында 81 биттә Татарстан ОГПУ-НКВД органнары һәм суд «тройкасы» карарлары буенча атып үтерелгән корбаннар саны китерелә. Мәсәлән, «зур террор» котырынган ике елны гына аерып алганда 1937 елда 2519 кеше һәм 1938 елның (23 август–31 декабрь) араларында 627 адәм атып үтерелгән. Адлер ага шулай ук, кайбер чыганакларда республикада сәяси яктан зыян күргән кешеләр саны җиде меңгә якын, дип белдерә. Әлеге санны ул галим Рүзәл Йосыповның бер язмасыннан алынуы турында искәртә [Мәдәни җомга, 2012 ел, 3-нче сан].

Ә менә монысы халыкара аренада, кем әйтмешли, ат уйнаткан сәясмәннәр фикере. Бу фикер соңгы арада Франциядә мөселманнарга карата коточкыч һөҗүмгә бәйле. Ислам динен тотучыларны, террорчылыкта гаепләп, уптым илаһи җинаятьче дип тамгаладылар. Ушбу гаделсезлеккә каршы Төркия Президенты Рәҗәп Таип Эрдоган чәчрәп чыкты. Ул иң зур җинаятьчеләр мөселман түгел, ә бәлки, башкалар, дип белдерде. Фикерен дәлилләү йөзеннән, ул Франция Президенты Макронга җавап хатында кешелек тарихында гөнаһсыз инсаннарны күпләп катил кылган җәллад-диктаторларның исемлеген вә алар тарафыннан үтерелгән җан санын игълан итте. Әлбәттә, бу исемлектә беренче урында – Адольф Һитлер, икенче булып аның «якын әшнәсе» Иосиф Сталин. Рәҗәп бәй мәгълүматлары буенча, даһи юлбашчы 20 миллион кешенең башына җиткән. Өчлекне исә Кытай компартиясе юлбашчысы Мао Цзе Дун йомгаклый.

Заманында католик дине башлыгы – Рим папасы – «халыклар атасы»ның эшчәнлегенә вә аның кылган гамәлләренә тискәре мөнәсәбәттә булуын яңгыраткач, бер көн дә армиядә хезмәт итмәгән башы белән генералиссимус дәрәҗәсенә күтәрелгән зат:

– Рим папасының ничә дивизиясе бар соң, – дип мыек астыннан мәкерле итеп елмайган, диләр...

Шәхес культын фаш итеп күп санлы мәкаләләр һәм берничә китап язган тарихчы һәм педагог, Казан университеты профессоры Алтер Литвин: «Сталин күрсәтмәләре буенча атып үтерелгән бер гаепсез йөз меңнәрчә кешене, ГУЛАГта корбан булган миллионлаган совет ватандашын, Катыньда һәлак булган поляк хәрбиләрен һәм бик күп совет кешеләренең реабилитацияләнүе һәм тиранның мәхкәмә карары белән кешелеккә карата җинаятьче буларак фаш ителүе белән, аның портретлары һәм эшчәнлеге белән мавыгулар үзеннән-үзе юкка чыгуына ышанам», – дип яза [Литвин: 2013. С. 46].

Сүз уңаеннан, Алтер әфәнденең атасын юлбашчы турында анекдот өчен ун елга ирегеннән мәхрүм иткәннәр икән. Менә ул: утызынчы елларда бер грузин ишәккә атланып Мәскәүгә барган, имеш. Ишәкне бәй-

ләргә урын таба алмыйча аптырап беткән. Кремль янында узганда, тукталe, милләттәше янына кереп чыгарга була бит, дип уйлый. «Халыклар атасы» кабул итә моны.

– Сосо, туган, кояшлы Гөрҗестаннан кайнар сәлам, гамарджоба! – дип сүз башлый. Хуҗаның кәефе шәптән түгел икән, коры гына исәнләшкән.

– Нишләп йөрисең, ни гозерең бар?

– Менә Мәскәү хәтле Мәскәүдә ишәгемне бәйләргә урын табалмый интегеп йөреш.

– Вах! Харап икән...Менә мин монда 170 миллион ишәк белән идарә итәм, ә син бер бөртек ишәгеңә урын табалмыйсың, булдыксыз, тай моннан исән каласың килсә, – дип кабинетыннан сөреп чыгарган, имеш.

***Фикерләүгә дә мөмкинлек юк...***

Әлбәттә, репрессия корбаннары булып беренче чиратта милләтебезнең асыл затлары – галим-голяма, иҗат әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре шәһит киткән. Халыкны иман юлына өндәүче, аның рухи дөньясын сафландыручы дин әһелләре шулай ук күпләп юк ителгән. Күренекле дин эшлеклесе, гыйлем иясе, журналист һәм мөгаллим Ризаэддин Фәхреддиннең тормыш юлы шушы рәхимсез, шомлы вакытта нинди кыерсытуларга, рәнҗетелүләргә дучар булганын гына искә алып китик. ЧК һәм ГПУ хөкеме йөргән заманалар турында галим: «Бу дәвер хакында язарга түгел, хәтта күңел белән фикерләүгә дә мөмкинлек юк», – дип язып куйган. Россия мөселманнарының Диния нәзарәте җитәкчесе, мөфти буларак, Риза хәзрәт үзенең фикердәше Кәшшафетдин казый Тәрҗемани белән берлектә властьларга дин эшләрен алга таба алып бару турында җиде пункттан торган «үтенечләр» яза. Документта, аерым алганда, балаларга дин сабагы укыту, мөгаллимнәрне сайлап алу, муллаларга салым түләүдә ташламалар ясау, дөньяви мәктәпләргә мулла балаларын да кабул итүне үтенә. Үтенеч хаты Республиканың Гыйльми үзәк рәисе, әдип Галимҗан Ибраһимовка тапшырыла. Әдәбият классигы, мәхдүмнең югары җитәкчелеккә юлламасы аерым игътибарга лаек. Ул, руханиларыбыз артык комсызлана, алар, имеш, идеология фронтының хуҗалары булырга, татарлар массасының акылы өстеннән хакимлек урнаштырырга телиләр, шуңа да аларның дәгъваларына карата һичнинди йомшаклык күрсәтмәскә кирәк, дигән вердикт чыгара «кызыл» әдибебез. Мәгәр влач алдында моның ише ялагайлык исәпкә алынмаганын беләбездер. Дөресен әйтергә кирәк, диктатор мөселманнарның башлыгы мөфти хәзрәтләренең бөтен мөселман дөньясына танылганын һәм хөрмәт ителгән мәшһүр зат икәнен истә тотарга һәм аны турыдан-туры репрессияләргә батырчылык итмәгән, әмма аның балаларын җәберләп, җәзалап үтертүдән тартынып тормаган. Риза хәзрәт турындагы истәлекләрдә гаиләсенең бик авыр хәл-

дә калуы, гаиләсе белән ачлык газапларын кичереп яшәве турында хәбәрләр бар. Бервакыт ул икмәк сатып алырга дип чиратка баскач, аны танып алганнар һәм, мыскыл итеп орышып, кибет тирәсеннән куып җибәргәннәр. Гаиләсен тәэмин итү өчен хәзрәт ипине юклы-барлы акчасына коммерсантлардан кыйммәткә сатып алырга мәҗбүр була.

Риза хәзрәт Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез белән тыгыз элемтәдә торган. Алардан үзенә кирәкле китап, кулъязма алдырткан. Үзенең истәлекләрендә ул иң авыр чакларда, гаиләсе ачлыктан интеккәндә посылкада китап урынына азык-төлек җибәрсеннәр иде, дип теләве һәм дөрестән дә аның өмете аклануы турында һәм Аллаһның рәхмәте белән хыялы тормышка ашуы, милләттәшләренә атап дога кылуы турында язып калдырган.

* * *

Соңгы елларда тиранны сагыну, аның хөрмәтенә һәйкәлләр кую, музейлар оештыру турында матбугатта, интернетта хәбәрләр еш күренә башлады. Әнә башкаланың үзәгендә үк «халыклар атасы» исемендә шаурма кафесы ачканнар. Аның персоналы НКВД хезмәткәрләре киеменнән, имеш. Ашханә хуҗасы тарих һәм юлбашчы шәхесенә мөкиббән икән... Новосибирск, Волгоград, Түбән Новгород өлкәсе Бор каласында, Хабаровск өлкәсе Сосновка авылында Сталинга һәйкәлләр, бюстлар куелуы билгеле.

Әле шушы арада гына янә бер ыгы-зыгы булып алды. Бу юлы диктаторның иң якын мөрите Лаврентий Берия тирәсендә. Имеш, Росатом башлыклары Халык казанышлары күргәзмәсенә атом проекты тарихына багышланган экспозициягә атомчы галимнәр белән бер сафка бу палачның да сынын куймакчылар икән. Моңа ошбу галимнәрнең туганнары катгый каршы булган, ди. Кремльгә һәм Росатом җитәкчелегенә юлланган хатта: «Илебез тарихында Берия – иң җирәнгеч затларның берсе. Аның шәхесе күптәннән лаеклы рәвештә законсызлык вә чикләнмәгән кансызлык, әхлаксызлык символына әйләнде. Атом проектының тарихына зур өлеш керткән күренекле галимнәр белән бер рәткә бу җәлладны куеп, аны акларга маташуга юл куймаска кирәк. Чөнки 2000 елның 29 маенда “массачыл репрессияләргә җинаятьчел механизм корганнары өчен” РФ Югары Суды аны һәм аның хезмәттәшләрен реабилитацияләүдән баш тартты», – дип искәртелә анда.

Бу урында «халыклар атасы» турында мәзәк искә төште. Мәгълүмдер ки, аның тыкшынмаган җире булмаган. Аеруча тарих, тел өйрәнү, фәннең төрле тармаклары, мәдәният, сәнгать һәм башкалар. Руханилар семинариясеннән куылган башы белән акыл сатарга яраткан ул. Алдап-йолдап Италиядән Капри утравында үпкәсен дәвалап яткан Максим Горькийны

кайтарткан. Кремльдә «Герцоговина Флор» тәмәкесен изеп махрасын төрепкәсенә төеп маташканда революциянең «давыл хәбәрчесеннән»:

– Алэксей Максимыч, это ви написали роман «Мат», – дип сораган икән.

– Грешен, Иосиф Виссарионович, да, я написал роман «Мать».

– Хароший роман. Читал. А ви ни магли бы написат роман «Атэц», – дип әйтә.

– Ну что ж, раз такое дело можно и попытаться...

– А ви попытайтесь, попытайтесь, как гаварит мой друг Лаврентий Палыч, папытка ни пытка...

Тиранның үлеме дә, тормышы да, кылган гамәлләре кебек, бүгенгәчә шомлы вә караңгы булып кала бирә. Аларда ниндидер сер, фаҗига яшерengән, бәлки Аллаһ Тәгаләнең каһәре шулдыр... 1953 елның мартында Сталинның үлеме турында хәбәр Парижга килеп ирешкәч, зыялы дворян нәселеннән чыккан әдип, нечкә күңелле классик шагыйрь, прозаик һәм Нобель бүләге иясе Иван Бунин, «ниһаять, хисапсыз гөнаһсызларның канын эчеп тончыккан ерткыч дөмеккән», дип әйткән, имеш. Нәкъ шул ук фикерне атаклы Совет кинойолдызы Любовь Орлова да яңгыраткан, диләр...

### Әдәбият

1. Ә. Еники. Әсәрләр. 5 т. Казан, 2004.
2. А.Г. Галлямова // История Татарстана и татарского народа 1917–2013. Учебное пособие. Казань, Изд. КГУ, 2014.
3. М. Кашапов. Шәхесләр: язмышлар балкышы. Казан: «Идел-пресс», 2013.
4. А.Л. Литвин. Жизнь как выживание (воспоминания и размышления о прошлом). Москва: «Собрание», 2013.
5. М. Мәһдиев. Сайланма әсәрләр. 5 том. Казан: ТКН, 2009.
6. Сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабы. Т. 8. Казан, 2003.
7. А. Тимергалин. Миллият сүзлеге. Т. 1. Казан, ТКН, 2016.
8. Рүзәл Йосыпов // Мәдәни җомга. 2012 ел, 3-нче сан.
9. Татарстан Республикасы Тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивы. Ф. 3. Тасв. 3. 69 эш.

***А.Г. Ахунов***

## ҖЫЕННАР ҺӘМ «КАРАВЫЛ ТАУЛАРЫ»

***Аннотация:*** *Укучыга тәкъдим ителгән язма халык демократиясенә нигезләнгән «җыен» институтына багышлана. Славян халыклары тарихындагы «вече» дип аталган халык җыйналышларына охшаш җирле үзидарә органнары татар халкы тарихында да мөһим роль уйнаган. Царизм чорында сәяси сәбәпләр аркасында, мондый бәйсез һәм даими эшләүче җирле үзидарә оешмалары эшчәнлеге асылын үзгәртергә мәҗбүр ителгән. Алар елына бер генә тапкыр уздырылучы халык бәйрәме булып калган. Милли әдәбиятыбызда «җыеннар» күбесенчә «халык бәйрәменең бер төре» итеп өйрәнелә. Җыеннарның төп асылын ачып бирүче «каравыл таулары» системасы турында да мәгълүмат бирелә. Автор бу язмада үзенең Урал алды төбәгендәге «җыеннар» һәм «каравыл таулар» исемлеген барлаудагы күпьеллык эзләнүләр нәтиҗәсен тәкъдим итә.*

***Терәк сүзләр:*** *халык демократиясе, җирле үзидарә, вече, халык җыены, каравыл тавы, сигнал, чаң кагу, сөрән салу, учак ысулы, халык бәйрәмнәре, җыен бәйрәме.*

***Кереш сүз.*** Урта гасырлардагы «халык демократиясе» турында сүз чыкты исә, без шунда ук аны «үзидарә халык җыелышлары» төшенчәсе белән бергә бәйлибез. Һәм, әлбәттә, үзебезнең белем «багажыннан» чыгып, Новгород, Псков феодал республикаларын һәм андагы «вече» дип аталган халык җыйналышларын күз алдыбызга китерәбез. Чөнки алар белән без мәктәп чорыннан ук, тарих дәреслекләре аша танышбыз. Чынлап та нәрсә соң ул «вече»? «Википедия» түбәндәге мәгълүмат бирә: «*Ве́че – народное собрание... до образования государственной власти раннефеодального общества... одна из исторических форм прямой демократии на территории славянских государств*» [Материал из Википедии]. Тагын бер интернет-ресурста тулырак белешмә бирелгән: «*Вече – это главная форма самоуправления в Древней Руси, собрание, сходка городской или племенной общины для решения вопросов войны и мира, избрания князей и воевод, принятия законов, решения вопросов по договорам с другими землями, житейских повседневных вопросов... Вечевые собрания созывались по звону вечевого колокола. Иногда...через “герольдов” — “бирючей”* (“глашатайлар” – А.А.)... *Вече имело постоянное место сбора...*» [https://zen.yandex.ru/media/helperia/вече]. Үзенең вазифасы буенча, «вече җыелышлары» викинглардагы «Тинг», англосакслар-

дагы «Витенагемот» һәм украиннардагы «Козацкая Рада» дип аталучы халык җыйналышына охшаш булган [Материал из Википедии]. Тема яхшырак аңлашылсын өчен аларның берсенең тарихын китерү урынлы булыр. 1478-нче елда «Яңа ас-Славия» (гади укучыга күбесенчә ул «Новгородская вечевая республика» исеме астында билгеле) дип аталган ирекле «ушкуйниклар» төзегән дәүләт мәскәүлеләр тарафыннан басып алына, бөек кенәз указы буенча, андагы идарә итү системасы җимертелә. «Вечевые собрания» дип аталган ирекле халык җыелышлары катгый тыелган һәм часовнялардан «вече» кыңгыраулары алып ташланган... Әйе, сүз дә юк, күрше халык тарихын ярыйсы беләбез. Ә татар дөньясында «халык демократиясе» торышы ничек булган икән? Булганмы бездә «вечеларга» охшаш «халык җыйналышлары»? Җавап түбәндәгечә булыр. Нәкъ шундый ук, дөресрәге, шуңа охшаш система белән, Идел Болгары һәм Казан ханлыгы җирләре дә идарә ителгән! Тик, кызганычка каршы, «җыеннар» дип атап йөртелүче, безнең «татар вечелары» тарихы бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Бәйсезлек өчен көрәш тарихын язучылар гына алар турында искә алгалаштыра. Милли әдәбиятыбызда исә «җыеннар» күбесенчә «халык бәйрәменең бер төре» итеп өйрәнелә. Чынлыкта бит, алар тарихыбыз белән тыгыз бәйле, бик тә мөһим, аерым бер «халык институты» булганнар, шулай дисәк, хата булмас. Әгәр дә җыеннарны «бер төбәктә урнашкан торак пунктларны берләштерүче җирле үзидарә берәмлекләре» дип атасак, безнеңчә, дөрес булыр. Халык авыз иҗаты нигезендә (риваятьләр, хатирәләр буенча) теге яки бу «җыен бәйрәме»н уздыручы авыллар төркемчәләрен ачыклап, анализ ярдәмендә, борынгы төбәк җыеннары исемлеген төзү фәнни әһәмияткә ия булыр, дип уйлыйбыз. Безнең татар дөньясы тарихында шулай ук халык демократиясе нигезендә барлыкка килгән җәмәгатъ белән идарә итү системалары – «Сайлаулар» һәм «Шура» («Диван»; «Совет») да «җыен институтлары» белән тыгыз бәйләнгән булуы аңлашыла. Аларның тәүгесе гавам эченнән лаек шәхесләрне җитәкче, башлык итеп күтәрү механизмын тәшкил итсә, соңгысы – шул лаеклы шәхесләрнең киңәш итешеп, ханга дәүләт белән идарә итүдә дөрес юлны күрсәтү механизмыдыр.

***«Җыен», «Каравыл тавы» төшенчәләре.*** Иң башта «җыен» төшенчәсенә аңлатма биреп китәбез. Аңлатмалы сүзлектә түбәндәге мәгълүмат бирелгән: «*Җыен ул – 1. Нинди дә булса мәсьәләне хәл итү өчен җыйналган җәмәгать җыелышы; 2. Элек бер төркем авылларда, гадәттә сабан эшләре тәмамлангач, үткәрелә торган бәйрәм, ул һәр төркем авылда берәр атна булып, айдан артык дәвам иткән*» [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 1981. 796 б.]. Татар телле «Википедия»да бераз тулырак белешмә бирелгән: «*Җыен яки Корылтай – борынгы татарларда милли җыелыш,*

*корылтай. Элек-электән үк татарлар тирә-юньндәге берничә авылның халкын берләштереп, бер җыен уздыра торган булганнар...Чәчү беткәч, Җыен узган. Сабан туен бер авыл үзе уздырса, Җыенны берничә авыл җыелып уздырган. “Җир җылынгач, Җыен җыела” – халык мәкале... 5–10 авыл җыелышып бер җыен уздырганнар. Әмма революциядән соң коммунистлар Җыенны бетереп, аның вакытында Сабан туен уздырырга булдылар*» [https://tt.wikipedia.org/wiki/Җыен]. Халык җыеннарында кемнәр катнашкан соң? «Җыеннарны» оештыручылар, җитәкчеләре кем булган? – дигән сорауларга да җавап табыйк. Язучы Г. Минский әсәрендә «җыен утыру» турында искә алына. Шуннан бик мөһим өземтә китерәбез: «*Мәхәлләләрдә җыен утырулар башлана... Түрдә – “җыен агасы”, уң ягында – “уң би”, сул ягында – “сул би”*». Бу юлларда – сайланып куелган «җыен» җитәкчелеге турында бик тә мөһим мәгълүмат сакланган! Составы буенча ул юриспруденциядәге «Третéйский суд» корылышы белән тәңгәл килә түгелме?! Риваятьләр һәм борынгы язма чыганаклар буенча, «җыенда» «киңәш тотучы» социал катламнар – «ил агалары», «авыл башлыклары» (старосталар; старшиналар), «ару кешеләр», «ил картлары», «аксакаллар» (старейшина) исемләнә. «Җыеннар», билгеле урында уздырылып, үзенең аерым атамасы белән йөртелгән.

Берничә сүз белән «җыен» җыелу урыннарын тасфирларга кирәктер. Риваятьләрдә бу урыннарда намаз уку, явым-төшемнән ышыклану, иң мөһиме, кышларын җылынып чыгу өчен, махсус биналар корылуы турында сөйләнелә. Мисалга, Казан янындагы «Хан болыны» дигән «җыен» урынында Отуч мәчете искә алына. Уфа каласы янындагы Каратун дигән тау башында (Чесноковка тавы), Мең волостьлары киңәшкә (сход; собрание; корылтай; җыен) җыела торган урында, махсус таш мәчет булуы турында да искә алына. Ә гади авылларда «җыен» урыннарында, шулай ук олы юл буйларында да, мич белән тәэмин ителгән алачыклар торганы мәгълүм. Халык телендә аларны «Күшек-сарайлар» дип атаганнар.

«Җыеннар» ничек һәм кайчан җыелган соң? Сорауга җавапны эзләгәндә «җыен» институтының тагын бер мөһим һәм аерылгысыз атрибуты ачыкланды. Урыс халкында «вече» кыңгыравы сигналы буенча җыелышканнар, дидек. Ә безнең халыкта бу вазифаны «Каравыл таулары» үтәгән! Безнең әдәбиятта «каравыл таулары» турында күп искә алына, әмма шушы ике төшенчәне бер җепкә бәйләмиләр. Чынлыкта, элек «каравыл таулары» «җыен» институтының аерылгысыз өлеше булган. «Каравыл тавы» төшенчәсенә дә аңлатма биреп китик. Аңлатмалы сүзлектә «Каравыл тавы» сүзтезмәсенә түбәндәге аңлатма бирелгән: «*Каравыл тавы – 1) борынгы заманнарда дошман явы килүен сагалап, күзәтеп тору урыны – гадәттә нинди дә булса табигый биеклек, тау; 2) соңрак – яшьләр-*

*нең билгеле бер калкулыкка җыелып үткәрелә торган язгы уеннар*» [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 1981. 50–51 бб.]. «Татар-урыс сүзлеге» дә шундыйрак аңлатма бирә: «*Каравыл тавы – 1) сторожевая высота, горка (для наблюдения врага); 2) весенние игры молодёжи на определённой горке*» [Каравыл тавы: 1966]. Димәк, дошман явы килүен сагалап, күзәтеп торучы «каравыл посты» урнашкан табигый биеклекне, яисә тау башын «каравыл тавы» дип атаганнар икән! «Каравыл таулары» биек булмаган очракта, махсус курганнар, агач таганнар кебек өстәмә ясалма корылмалар ярдәмендә аларны биегәйтеп, ерактан күренерлек итеп ясаганнар. Бөтен тирә-юнь уч төбендәгедәй күренеп торган. Мисалга, БРның Чакмагыш районы Калмашбаш авылы янында «Аю каравылы» («Аюгара», «Биектау» дип тә йөртелә) дигән «каравыл тавы» бар. Авыл картлары: «*...аяз көннәрдә тау башыннан 50 чакрымдагы Кушнарин тавы башындагы Грибушин чиркәве күренеп тора иде*» – дип хәтерли иделәр. Шушы гаят зур тау массивының бер үркәчен «Кызлар уйный торган тау» дип тә, яисә, кыскартып, «Кызлар тавы» дип тә йөртәләр. Авыл яшьләре элек шул тау башына «Кичке уен»нарга чыкканы мәгълүм. «Аю каравылы» тавы итәгендә торган бер тау сыртын «Туплау тавы» дип атыйлар. Авыл халкы тау итәгендә урнашкан, авыл көтүенең аерым вакытта тупланып тору урыны буенча шул атама бирелгән, дип уйлый. Әмма, кем белә, бәлки «Аю каравылы»ннан алынган сигнал буенча, кораллы гаскәр шунда туплангандыр?! Гадәттә, ашыгыч хәбәрне җиткерү өчен яхшы атка атландырып чапкын җибәргәннәр. Әмма, камалышта калганда, дошман дозор-засадасына юлыкканда, кытлык заманда бу ысул файдасыз булган. Бәла-каза вакытларында, дошман явы килүе турында «каравыл тау» башыннан сигнал бирелү белән халык тавыш ярдәмендә кисәтелгән. Аны төрлечә атаганнар: «тавыш күтәрү», «сөрән салу», «каравыл кычкыру», «тревога күтәрү» һәм башкалар. Шагыйрь Һади Такташның «Мокамай» шигырендә карак тоту мизгеле турында: «*Әйшә тәтәй тоткан – каравылын кычкырткан*», дигән юллар белән халыкны аякка бастыруның бер мисалыдыр. Ягъни, бу җитез түтәй күрше-күләнен кычкырып – «сөрән салып» аякка бастырган. Мәчет манарасыннан мәзин-азанчының кычкырып азан әйтеп халыкны намазга чакыруы – хәбәр бирүнең бер төре түгелмени?! Славян халыкларында «сөрән салучыны» – «глашатый», аурупа манерында «герольд», «биручей» дип йөртелүе билгеле. Соңгысы – «биручей», татар сүзе булса кирәк, «боеручы», «боерыкны кычкырып иглан итүче кеше», дип аңлатыр идек. Билгеле, кеше тавышының физик мөмкинлеге чикләнгән. Бик тырышканда бер чакрымга (термин «чакыру» сүзеннән ясалган ахрысы) ишеттерергә була, әлбәттә. Сигнал бирүнең башка чараларын да санап китәргә кирәктер. Һәрбер авылда

таганга чылбыр ярдәмендә асып куелган зуррак тимер (яки җиз) кисәгеннән торган һәм тимер «бәргечтән» гыйбарәт булган махсус «чаңнар» торган. «Чаңга» сугып (кагып) шактый ерак араларга сигнал бирергә мөмкин булган. Шул типтагы «чаңнар» кайбер «каравыл тауларына» да куелган булган, имеш. Яу вакытларында байрак ярдәмендә гаскәр белән җитәкчелек итү үрнәгендә, «каравыл тау»ларда байрак-әләмнәр куллану очраклары да булгандыр, дип фаразлыйбыз. Әмма начар һава шартларында һәм төнен бу ысул файдасыз булган. Ә менә биек урыннан учак төтене ярдәмендә сигнал бирү ысулы – иң уңайлы һәм үтемле чара булган ахры. Мисалга, куе төтен чыгарып учакны тоташ яндырсаң, – бу бертөрле сигнал була, ә киресенчә, учакны әйбер белән каплап-каплап алып өзек-өзек төтен чыгарсаң, – икенче төрле сигналны аңлата. Шулай, учак төтене белән әвәрә кылып, ерак араларга хәбәр бирергә мөмкин. Ә төннәрен якты итеп учак ягып сигнал бирелгән. Мондый элемтә төрен фән телендә «учак ысулы» яки урысча тәрҗемәдә «костровой метод связи» дип атала. «Каравыл тау»ларда хәвеф барын кисәтү өчен кизү торган «каравылчы» дип аталган махсус кешеләр алдан дөрләп янырдай һәм куе төтен чыгарырдай учаклар хәстәрләп куйган. Дошман явы килүен шәйләп алу белән, каравылчылар учакка ут төртеп җибәргән. Күз күремендә урнашкан «каравыл тау»ларда да, моны күреп алган «каравылчылар» учак тергезгән. Чылбыр реакциясе буенча, хәвеф сигналы тиз арада тоташ бер регионга җәелә алган. «Җыен» оештырыла торган урыннар хан заманнарында, соңрак хәрби-кантон системасы чорларында, хәрби ополчение, коралллы алайлар (отрядлар, командалар) туплау үзәкләре вазифасын да үтәгән. Гаскәр җыю хәбәрен «каравыл таулары» аша җиткерү бик отышлы булган. Соңыннан инде, «каравыл тау»ларның кирәге калмагач, халык хәтерендә моңсу кайтаваз төсле, «сөрән», «сөрән сугу» дигән йола «бәйрәмнәре» уздырылганы мәгълүм. Яшьләрнең «кичке уен»га чыгып аралашу гадәтен кайбер урыннарда икенче төрле «Каравыл тауга чыгу» дип тә атаганнар. Аңлатмалы сүзлектәге сүзтезмәнең икенче мәгънәсе шуңа ишарә. Бу урында безнең тарафтан төзелгән «Каравыл таулары» исемлеген китерү урынлы булыр.

***Идел-Урал буйларында «Каравыл таулары»***

| № | Тау исеме | Кайсы авыл янында | Урнашкан административ районы |
|---|---|---|---|
| 1 | Каравыл тавы | Дәвеш | ТР, Яшел алан |
| 2 | Каравыл тавы | Чишмәбаш | ТР, Кукмара |
| 3 | Каравыл тавы асты | Өркеш | ТР, Кукмара |

| № | Тау исеме | Кайсы авыл янында | Урнашкан административ районы |
|---|---|---|---|
| 4 | Каравыл тавы | Түбән Чәбия | ТР, Кукмара |
| 5 | Каравыл тавы | Нурма | ТР, Мамадыш |
| 6 | Каравыл тавы | Каравылтау (Клявлино) | ТР, Норлат |
| 7 | Каравыл тавы | Сарман | ТР, Сарман |
| 8 | Каравыл тавы | Минзәләбаш (Бикбулат) | ТР, Сарман |
| 9 | Каравыл тавы | Рангазар | ТР, Сарман |
| 10 | Каравыл тавы (Урыс теленә калькалаштырып, «Охранная гора» дип тәрҗемә ителгән) | Чубуклы | ТР, Зәй |
| 11 | Каравыл тавы (икенче төрле Мир тавы диелә) | Зәй-Каратай | ТР, Лениногорски |
| 12 | Каравыл тавы | Югары Мактама | ТР, Әлмәт |
| 13 | Каравыл тавы | Илбәк | ТР, Азнакай |
| 14 | Каравыл тавы | Карабаш | ТР, Бөгелмә |
| 15 | Каравыл тавы | Иске Байсар | ТР, Актаныш |
| 16 | Каравыл тавы | Рсай | БР, Илеш |
| 17 | Каравыл тавы (икенче төрле Карагыл тавы диелә) | Бишкурай | БР, Туймазы |
| 18 | Каравыл тавы | Усман-Ташлы | БР, Ярмәкәй |
| 19 | Каравыл тау | Сөярмәт | БР, Ярмәкәй |
| 20 | Каравыл тавы (Тылат сыртындагы тау) | Чакмагыш | БР, Чакмагыш |
| 21 | Аю каравылы (тауның башка исемнәре – Аюгара яки Биектау) | Калмашбаш (Кырла Калмашы) | БР, Чакмагыш |
| 22 | Каравыл тавы | Аблай | БР, Чакмагыш |
| 23 | Каравыл тавы (мәктәптә төзелгән рефератларда «Патрульная гора» дип тәрҗемә ителгән) | Иске Күчәрбай | БР, Благовар |
| 24 | Каравыл тавы | Түбән Сәет | БР, Кушнарин |
| 25 | Каравылтау | Тозлыкуш | БР, Бәләбәй |
| 26 | Каравылтау | Кәдергол | БР, Дәүләкән |
| 27 | Каравылтау | Карламан | БР, Кырмыскалы |
| 28 | Каравыл тау | Нугадак | БР, Авыргазы |
| 29 | Каравылтау | Үтәй-мулла | БР, Авыргазы |

| № | Тау исеме | Кайсы авыл янында | Урнашкан административ районы |
|---|---|---|---|
| 30 | Каравылтау | Якшымбәт | БР, Күмертау |
| 31 | Каравылтау | Каран | БР, Мәләвез |
| 32 | Каравыл тау | Ахун | БР, Учалы |
| 33 | Каравылтау | Сәет-баба | БР, Гафури |
| 34 | Каравылтау | Армыт-рәхим | БР, Ишембай |
| 35 | Каравылтау | Таштимер | БР, Әбҗәлил |

Күрүегезчә, исемлек әлегә тулы түгел, бу бары тик исәпкә алуның башы гына, дисәк, хата булмас. Халкыбыз яшәгән төбәкләрдә мондый тарихи истәлекләр саны бихисап күп булган.

***Җыенда күтәрелгән мәсьәләләр диапазоны.*** Җыеннарда күтәрелгән мәсьәләләр «диапазоны» турында да тәфсирләп язарга кирәктер. Гади көнкүреш мәсьәләләре белән беррәттән җыеннарда гамәлдәге вазгыятькә бәйле ашыгыч сәяси мәсьәләләр дә күтәрелгән. Яуда катнашу, восстание күтәрү, кем ягында булу, яңа чыккан указ-боерыклар буенча фикер алышу, кайсы авылдан күпме рекрут алу, солдат бирү кебек четерекле сәяси мәсьәләләр каралган аларда. Тәүдә Казаннан, азак Мәскәүдән төшерелгән боерык-указларга «җыеннарда» тикшерү ясап, халык өчен зарарлымы, файдалымы дип фикер алышып, халыкка төшендереп бирелгән. Финанс белән бәйле эшләрдән – хөкүмәт эше белән йөргән түрәләрне кайда урнаштыру, ясак түләүдә кем-күпме өлеш кертәчәге, «чират кунакларын» (ятим балалар; караучысы булмаган карт-коры) карау билгеләнгән. Ям һәм ара юлларын төзекләндерү, күперләр салу, ям стансыларын тәртиптә тоту, атларын алмаштыру, Аргыш, Иске Казан юлларында ял урыннары, юл мунчалары булдыру, кышларын юл читләренә маяклар утырту хезмәтен бүлешү мәсьәләләре каралган. Мәгърифәт өлкәсендә – кайсы авылда югары баскыч мәдрәсә ачу, яңа мәчет-мәдрәсә төзүдә иганә җыю, мәчет-мәдрәсәләрне тоту, хәлфә-мөгаллимнәргә түләү, зәкят күләме кебек мәсьәләләр каралган. Сәүдә өлкәсендә – кайсы авылда базар ачу, ярминкәләр оештыру, базар чираты, товар бәяләре турында килешелгән. Межа баганаларына, билге ташларына, мал-туар питрачларына (янбашларына), чолык агачларына куела торган тамга-билгеләрне ил-төбәк халкына таныту, җирәбәләр бүлешү кебек бәхәсле нәрсәләр каралган. Көнкүреш мәсьәләләрдән – кайчан чәчүгә чыгу, сабан туйлары уздыру, печәнгә, уракка төшү, көтү йөртү урыннары, көтү чыгу көннәре билгеләнгән. Гомумән, «җыеннарда» рәсми администрация «кулы җитмәгән», яисә, киресенчә, алар белмәскә тиешле, яшерен мәсьәләләр каралган. Өстән төшерелгән гаделсез боерык-кануннарга карата туган тискәре

мөнәсәбәт, ризасызлык, башта «җыен»нарда әйтелеп, халык күңеленә ут салган. Рәсми түрә-чиновниклардан аермалы, халыкның үзидарә органы буларак, власть вертикаленнән төшерелгән, дин ирегенчикләү, салым күләмен арттыру, хокукларны чикләү кебек, «халыкны кыса торган» фәрман-боерыклар үтәлеше шикле булган. Күпчелек очракта андый боерык-указлар, халыкның кискен каршылыгы сәбәпле, үтәлмичә калган. Ул гына да түгел, көчләп чукындыру, салым арттыру, хокукларны чикләү кебек әмерләр халык арасында чуалыш, фетнә дә китереп чыгарган.

***Патша хөкүмәтенең җыеннарны бетерү өчен көрәше.*** Сәясәтне үз файдасына бора алмауда «җыеннарның» киртә булуы колониал хөкүмәтнең ачуын кабарта килгән. Җирле үзидарә демократиясен – «башбаштаклык», дип санаган патша хөкүмәте «җыеннарны» тыю, аны оештыручы, халыкны әйдәп баручы, илтәбәр ару кешеләрне эзәрлекләү эшен бер дә туктатмаган. Җирле халыкның кискен каршылыгы сәбәпле, хөкүмәткә яшерен сәясәтнең барча ысулларын да кулланырга туры килгән. 1705–1711 еллардагы Алдар-Күчем «явын» авырлык белән бастыргач һәм 1735 елда кабынып киткән Килмәк абыз-Акай «ихтилалын» бастыру барышында җәза гаскәре җитәкчеләре шактый тәҗрибә туплаган. Баш күтәрүчеләр отряды хәрәкәтен, туплану механизмын өйрәнә торгач, шуны аңлаганнар: «Фетнәчеләр сафын ишәйтүдә, сугыш хәрәкәтен дәвам итүдә "халык җыеннары", "каравыл таулары" булышлык итә икән!» Бу хакта хөкүмәтнең югары даирәләренә дә җиткерелгән. Фетнәне бастыру максатында, Рәсәй императрицасы Анна Иоанновна 1736 елның 11 февралендә «җыеннарны» тыю турында хөкүмәт указы чыгарган. Бу указда: «*Запрещается... без позволения городовых командиров сборищев делать*», – диелгән була [Полное собрание законов Российской империи с 1649 г.: 1733–1736. Т. IX]. Халык «җыеннарын» оештыручы ару кешеләр – «көтү башлыклары» да каты эзәрлекләнгән. Шулай, сәяси мәсьәләләрне күтәрүчеләрне җәзалап, халыкта тотрыклы курку хисе тәрбияләнгән. Коточарлык җәза чаралары кулланылса да халык чуалышлары еш кабатланган. Халык восстаниеләре чорында, Идел буе, Урал яклары вакыты белән Мәскәүгә «баш бирмичә» дә яшәп алган. Андый шартларда халык үзидарәсе институтын бетерү читен булган. 1798-нче елда хәрби-кантон идарәлеге системасы кертелгәч, мишәр, башкорт, типтәр-бобыль иррегуляр «казак» гаскәрләрен мобилизацияләүдә, эшчәнлеген тәэмин итүдә, «җыеннар», «каравыл таулары» роле зур булган. Моны колониаль хөкүмәтнең вазгыятьне үз файдасына боруы дип тә, кире чигенүе дип тә бәяләргә мөмкин. Әмма шау-шу тудырган беренче Ватан сугышы (1812), хөр фикерле «декабристлар» восстаниеләре тәмам булуга, Рәсәй империясенең карагруһ көчләре кабат баш калкыткан.

Дәүләттә хакимият вертикален ныгыту, мөһим үзгәртү эшләре җәелдерелгән. Властьларга комачау булган «җирле демократия» калдыкларын бетерү – мөһим бурычларның берсе дип каралган. 1828-нче елда, Империянең Дәүләт Советы күрсәтмәсе буенча, илдәге барлык рәсми булмаган җыелышларны юк итү боерыла. Күрсәтмәдә: «*Уничтожить всякие не дозволенные и соблазнительные сборища, под каким бы видом и названием оные не существовали*», – диелгән була [Полное собрание законов Российской Империи: 1828. Т. III]. Рәсәй Хәрби министрының урыннардагы хакимият башлыкларына җибәрелгән 1833-нче елгы махсус күрсәтмәсе буенча «җыеннар» җыелу тыелган: «*А с 1833 года запрещены были окончательно всякие собрания – джиены, происходившие в башкирских и мишарских селениях по древнему обычаю с очень давних времён…*» [ФЦГВИА. Ф. 1833 «Канцелярия военного министра». Д. 9219. Л. 13]. Бу чорда Урал алды халыкларының күпчелек өлеше хәрби-кантон идарәлеге системасы буенча яшәгән була. Алда әйтелгәнчә, борынгы «җыеннар», «каравыл таулары» системасы иррегуляр гаскәр эшчәнлеген тәэмин итүдә файдаланылган, дидек. «Казаклыкта», «башкортлыкта» хезмәт иткән халыкларда, әлбәттә, «җыенның» бәйрәм өлешен бетереп булса да гаскәр эшчәнлегенә кагылышлы өлешен тыю – гаскәрне көчсезләндерүгә бәрабәр булыр иде. Бу очракта турыдан-туры «тыю алымын» куллану да хата. Шуңа күрә «җыеннарны» бетерүдә патша хөкүмәте астыртын, яшерен чараларга күчкән. Төрле административ чикләргә, сословиеләргә бүлгәләнгән халкыбыз яшәгән төбәкләрдә һәр губерна, һәр өяз хакимиятләре «җыеннарны» тыю турында үз кануын чыгарган. Өстәвенә, төрле катлам, төрле җенес кешеләре өчен ул кануннар төрлечә булган. Икенче төрле итеп әйткәндә, мондый ысулны – «таралыш географиясен чикләү» дип атарга мөмкин. Элгәре «җыеннар» башкарган вазифаларны рәсми түрә-чиновникларга йөкли барып, тәүгеләрне идарә өлкәсеннән бөтенләй читләтүгә ирешелә. Эзлеклелек белән алып барылган сәясәт, билгеле, «җимешләрен» бирмичә калмаган, әкренләп «җыеннар», асыл функцияләрен югалтып, ахыр чиктә, сезонлы гына үткәрелә торган гади бәйрәм йоласы булып калган. Ә бит чын «җыен» – сәяси вазгыятькә карап даими үткәрелгән халык үзидарәсе «коралы» булган, аларга ел фасылы да, һава торышы шартлары да комачау булмаган. Мондый алымны конспиралогиядә «эчтәлеген үзгәртеп, төп асылын бозу» дип йөртәләр. Кире процессларны булдырмау максатында, бәйрәмгә әйләндерелгән «җыен»-«сабантуй»ларын да юк итәргә карар кылына. Урыннардагы хөкүмәт вәкилләре пычрак, мәкерле, яшерен алымнар кулланудан да тартынмаган. Ямьсез күрсәтү максатында (бу дискридитация, яла ягу методы була), төрле тәртип бозу, хәмер куллану очраклары халыкка «күпертеп» күрсәтелгән. За-

рарлы якларга басым ясап, халыкны бу бәйрәмнәрдән биздерүгә, аны инкяр итүгә этәкнәнәр. «Эчтән җимертү методлары» да киң кулланылган. Чын илаһият белән «эш йөртүче» хуҗа-сәетләр, ишан – шәехләр урынына, колониаль властьлар тарафыннан оештырылган «Диния нәзарәте» мөфтиләрен дә бу эшкә җиккәннәр. «Җыеннар» үткәрүне туктату турында ОДМС махсус дини «указлар» чыгарган. «Указларда»: «*Зеины (джиены)... драки, грабежи, насилия, с употреблением горячительных напитков – запрещается магометанским законом!*», – дип катгый әйтелгән була [ЦГИА РБ. Ф.И-2. Оп.1. Д.2815]. Мөселманнарга «үз оешмасы булып тоелган» «Диния нәзарәте» исеменнән эш йөртелүе, билгеле, ризасызлык хисен күпкә киметкән. Шулай да, чынлыкта кем коткысы белән эш йөртелүе яхшы чамаланган. 1859-нчы елда, мөфти Г.С.Сөләйманов инициативасы белән, «Диния нәзарәтендә» «Дело о ликвидации проведения обычая джиен», дигән «Эш» ачып җибәрелә. Бу папкага «җыеннарны» бетерү юнәлешендә башкарылган чара язулары теркәлеп барган [НА РТ. Ф.1. Оп.3. Д.6030. Л.18]. Мөфти, үз «указы» ныклап көченә керсен өчен, губернатордан да «җыеннарны» тыйган хөкүмәт законы чыгаруны сораган [Шунда ук]. Мөфтинең бу «инициативасын» күтәп торган кебек, Казан губернаторы П.Ф.Козлянинов имзасы белән, шул ук 1861 елда барлык губерна түрә-чиновникларына махсус «циркуляр» җибәрелә. Анда «җыен бәйрәме» үткәрүне тыярга кушылган була. Шул исәптән, полиция хезмәткәрләренә: «*Предписать всем становым приставам принять зависящие меры к удержанию татар от проведения Зиена, как вредного для них*», – дип күрсәтмә бирелгән. Шундый күрсәтмә алгач, губерна идарәлегенең 2-нче өстәл полиция бүлегендә дә №266-нчы санлы «О прекращении в Казанской губернии вредного для магометанской религии татарского праздника “зиина”, дигән “Эш” ачылган» [Шунда ук. Л.29 об.]. «Җыен бәйрәмнәре»н тыю мәсьәләсе 1870-нче, 1885-нче елларда да «Диния нәзарәте» һәм губернаторлар тарафыннан күтәрелә. Җирле «сүзе үтә торган» дин җитәкчеләре дә бу эштән читтә калмаган, билгеле. Проблеманың чын асылына төшенмәгән «голямалар» дә «җыен-сабан туйларын» хурлап, фәтвалар чыгарган. Мисалга, Оренбург губернасыннан Әбү-Сәгыйт Шодави дигән мулланың: «*Мөселманнарда “сабантуй” һәм “җыен” дигән бәйрәмнәр бар. Аларның тәүгесен “шайтан туе” дип, икенчесен “шайтан бала тапкан көннәре” дип атасак, хата булмас!*» дигән бик яңгыравык итеп «бәяләгән» фәтвасы сакланып калган. Үз борынынннан ерак күрмәгән аумакай түрәләр дә, «җыеннарны» бетерү инициативасы белән, властьларга хат-үтенечләр яудырган. Мәсәлән, алда искә алынган «Дело»да «Мәмдәл авылы крәстиәне» Х.Галеевнең 1884-нче елгы Казан губернаторы Л.И.Черкасов исеменә язылган, өяздәге та-

тар авылларында «җыен бәйрәмен» туктатуны сораган үтенече саклана [Шунда ук. Л.л. 1–3]. Шул ук папкада Казан өязеннән земство җыелышы әгъзалары, сәүдәгәрләр А.Я. Сәйдәшев һәм М.И. Галеевнең «җыеннарның тамырын корытыр өчен» «Рәсәйнең эчке эшләр министры Д.А. Толстойга мөрәҗәгать итәргә кирәк», дип башлап йөрүләре турында 1887 елгы документ саклана [НА РТ. Ф. 1. Оп. 3. Д. 7233. Л. 1]. Алда әйтелгәнчә, мөфти С.Ш. Тевкелев та 1884-нче елда, үзеннән алдагы мөфтиләр үрнәгендә, Казан губернаторы Н.Е. Андриевский исеменә «җыен» тыюны сораган «мөнәсәбәт» җибәргән. Губернатор, үз чиратында, проблеманы бик тә кискен хәл итеп куйган. 1887-нче елда ул урындагы полиция хезмәткәрләренә «җыен» оештыручыларны «Җинаятьләрне кисәтү һәм булдырмау турындагы Устав (низамнамә)»нең 157 һәм 170 маддәләре буенча эзәрлекләргә боерган [Шунда ук. Л.л. 10–10 об.]. Ягъни, «җыен» уздыру – җинаять ясауга тиң итеп карала башлаган. Канунны бозучыларны хөкем иткән мировой судьялар «Җәзалар турындагы Устав»ның 29-нчы, 30-нчы маддәләрендә каралган җәзалар кулланырга тиеш була [Шунда ук]. Бу маддәләр буенча – 50 сум штраф түләтү һәм 7 тәүлеккә кадәр төрмәгә ябылу җәзалары каралган була.

***Үзгәреш җилләре.*** Рәсәй хөкүмәте 1864-нче елда «Положение о губернских и уездных земских учреждениях» дип аталган мөһим документ кабул итә [Герасименко: 1990]. Бу норматив документ нигезендә илдә «земство реформасы» башланып китә. Земстволарны җирле үзидарәнең бер төре итеп карарга мөмкин. Әмма халык демократиясенә нигезләнгән «җыеннардан» аермалы буларак, болары ярым дәүләти, ярым җәмәгать оешмалары булган. Казан губернасында земстволар 1865-нче елда ук оештырылган, Уфа губернасында бераз соңрак – 1875-нче елда кертелгән, ә менә Оренбург губернасына бу үзгәрешләр 1913-нче елда гына барып җиткән. Безнең төбәкләрдә земстволар оештырылуын «рәсми урыс хөкүмәте белән властьларга лояль булган милли зыялылар арасындагы формаль булмаган “компромисс”, “килешү”, дип бәяләргә мөмкин. Бу чорда инде Рәсәйдә шактый уңай үзгәрешләр күзәтелгән – “декабристлар”, “народниклар” кебек хөр фикер ияләре үсеп чыккан. Бергә утлар-сулар кичергән татар халкын “колония халкы” итеп кабул итүне, аңа “бобыль”, “инородец”, “туземец”, дип өстән карау хата булуын аңлаган урыс зыялылары пәйда булган». Башка милләт, башка диндәге, әмма дәүләтне ныгытуда үз өлешен керткән һәр халык та милли ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә хокуклы булуны инкяр итмәүчеләр алар сафында була. XIX гасыр азакларын татар дөньясы урталай ярылган кыяфәттә каршылаган. Җәмгыятьнең бер ягында хөкүмәт структурасының инде бер өлешен тәшкил итүче, шул ук вакытта туган кавеме мәнфәгатьләрен

кайгыртырга онытмаган алдынгы карашлы татар зыялылары торган. Аларның күпчелеген югары катлау вәкилләре – дворянлык алган, төрле «зауряд» дәрәҗәләргә ия булган, вәкаләтле вазифалар башкарган хәрбиләр, түрә-чиновниклар тәшкил иткән. Бу тараф метраполия халыклары белән тигез хокукта булуны, ислах-реформалар үткәрелүен көткән, яңа «җәдитчә тормышта» яшәүне максат иткән. «Җәдитчелек» дип бу очракта Аурупа цивилизациясе һәм урыс дөньясы казанышларына нигезләнгән тормышта яшәү теләге аңлатыла. Татар җәмгыятенең икенче ягын, «иске элита» җитәкчелегендә, «борынгыдан килгән кадими тормышны» дәвам итүне, «шәригать кушканча яшәүне» төп максат, мәсләк иткән гади халык тәшкил иткән. Төрле кысым-киртәләргә карамый, гореф-гадәтләре саклаган, теш-тырнагы белән туган телен, динен югалтмаска тырышып көн күргән төп халык массасы шушы якта булган. Бу очракта «кадимчелек» – борынгы дәверләрдән килүче, Төрки, Шәрыкь һәм Ислам дөньялары кыйммәтләренә нигезләнгән тормышны дәвам итеп яшәү теләген белдергән. Җәмгыятьнең ике котыпка тартылгандай аерылу процессын татар әдәбияты дәреслекләрендә капма-каршы лагерьларга бүленеп, дошмани ике көчнең көрәше кебегерәк күрсәтелде. «Җәдитчеләрне» – уңай итеп, ә «кадимчеләрне» тискәре буяулар белән манчып, «карагруһ явы» итеп сүрәтләделәр. Чынлыкта исә андый конфронтация булмаган, билгеле. Болар бер-берсенә бәйләнгән, берсен-берсе тулыландыра торган ике агым гынадыр. Нигезенә кадәр җимерелсә дә, яңадан аякка басарга, яңадан милләт булырга азапланган җәмгыятьнең авыр хәлдән чыгу өчен сайлаган төрле юллары гына дип бәяләнсә, дөрес булыр.

Йомгаклап әйткәндә, патша хөкүмәте тарафыннан җитди чаралар күрелсә дә «җыеннар» бөтенләй юкка чыгарылмаган. Асылы үзгәргән кыяфәттә, кыр эшләре тәмамлануны бәйрәм итү чарасы буларак, язгы – «сабантуйлар» һәм көзге «ярминкәләр» рәвешендә, ул безнең көннәргә кадәр үк килеп ирешкән. Өлкән буын кешеләре Сабан туен икенче төрле әле дә «җыен», «мәйдан», дип атавын дәвам итә. Чәчү тәмамлануга шатлану чарасы буларак, бер көнлек «Сука бәйрәме», «Сабан туе» йола бәйрәмнәрен үткәрүне Совет хөкүмәте рөхсәт итсә дә, берничә көннәр буе кунакка

Колхозлашу чорында, «халык күп бәйрәм итә, шуңа эшкә салкын карый!» дигән сылтау нигезендә, халык бәйрәменең бу төре юкка да чыгарылган.

***Бүгенге көнгә әйләнеп кайтыйк.*** «Перестройка» – «үзгәртеп кору» чоры йогынтысында, чын демократия нигезләрен аңлаучы сәясәтчеләр тәкъдиме белән, хөкүмәт 2003-нче елда «Җирле үзидарә турында» 131-нче санлы Федераль канун да кабул итте [Федеральный закон от 06.10.2003 N 131-ФЗ (ред. от 30.12.2021) «Об общих принципах орга-

низации местного самоуправления в Российской Федерации»]. Канун, Федераль Җыелышның ике палатасында да расланып, РФ Президенты имзасы белән дөнья күрде. Тик шунысы кызганыч, аны «дәррәү» күтәреп алучы, тормышка ашыручы гына сирәк. Бу канун эшләгән очракта, халык демократиясенә нигезләнгән борынгы «җыеннар» үрнәгендә, кала-авылларда яшәүче гади кеше хокукы көчлерәк якланган булыр иде. Мәкаләне йомгаклап әйтәсе сүзебез шул – «җыен» һәм «каравыл тау»ларның урыннарын, атамаларын алга таба да ачыкларга кирәк. Казанда бу юнәлештә ярыйсы күп эшләр дә эшләнгән. Мисалга, Р.К. Уразманова төзегән тарихи-этнографик атлас бик әһәмиятле чыганак булып тора [Уразманова: 2001]. Китапның исеме – җисеменә дә туры килә. Чөнки атласта «җыеннар» бәйрәм йоласы буларак исәпкә алынган. Шунсын да әйтергә кирәк, хезмәтнең Көнбатыш Башкортостан регионына караган өлеше генә бераз «йомшаграк» чыккан. Авторның безнең як кешесе булмавы үзен сиздерә. Авыл исемнәрендә, географик атамаларда хаталар да җибәрелгән. Безнең якларда куелган башкорт телле юл күрсәткечләрдә җибәрелгән хаталар шикелле, монда да шундый ук хәл күзәтелә. Монда шушы «җыеннар» исемлеге дә тулы түгел. Күз йөртеп кенә чыкканда да берничә дистә «җыен» исемлеккә кертелми калганы тоемлана. Җыеннар исемлеген ачыклау үрнәгендә, «каравыл таулары» исемлеген дә бергәләп ачыкларга кирәктер. Исемләнгән хезмәтне тагын да тулыландыру максатында үзебез ачыклаган «җыеннар» исемлегеннән, Көнчыгыш Татарстан һәм Көнбатыш Башкортостан төбәкләренә кагылышлы өлешен укучыга тәкъдим итәбез.

| тәр-тип № | Җыен атамасы | Кайсы авыллар җыелган? | Хәзерге административ район |
|---|---|---|---|
| 1. | **«Ашыт җыены»** | Ашыт (Куш-елга); Таш-елга; Кабан-Бастырык; Дүрт-мунча; Түбән Биш; Бишсубашы; Шыкмай; Бура-киртә; Әхмәт; Кадер; Югары Пәнәче; Урта Пәнәче; Түбән Пәнәче; Кәрәкәс; Бигеш; Карман; Югары Лаҗы; Түбән Лаҗы | ТР, Түбән Кама һәм Зәй |
| 2. | **«Мәрди җыены»** | Мәчти авылы тирәсе авыллары | ТР, Актаныш |
| 3. | **«Бикә җыены»** | Иске һәм Яңа Кормаш; Сәфәр; Адай; Усы; Үрияды; Балтач; Кыр-Каентүбә; Бикчәнтәй; Чат; Иске-, Яңа- Җиаш; Шәбезбашы; Анач; Әтәс; Чирү; Чынык; Иске Теләкәй; Кәлтәү; Татар Суксуы; Мари Суксу | ТР, Актаныш |

| тәр-тип № | Җыен атамасы | Кайсы авыллар җыелган? | Хәзерге административ район |
|---|---|---|---|
| 4. | **«Илбәк җыены»** | Әҗәкүл; Куян; Актаныш; Актаныш-баш; Уразай; Илчебай; Ирмәш | ТР, Актаныш |
| 5. | **«Кара җирек җыены»** | Тыңламас; Такталачык; Иске Ташим | ТР, Актаныш |
| 6. | **«Тавык җыены»** | Югары Үрьяды; Түбән Үрьяды | ТР, Актаныш |
| 7. | **«Кәкере җые-ны»** | Кәкре-Елга; Түбән Якый; Әлки; Масгыт; Кәтем | ТР, Азнакай |
| 8. | **«Зи буе җыены» яки «Сары ай-гыр җыены»** | Югары Чаллы; Урта Чаллы; Түбән Чаллы; Имәнлебаш; Шепкә; Аксар; Болгар; Каенлы; Тоба; Кече Аты; Кы-зыл Чапчак | ТР, Түбән Кама |
| 9. | **«Шәңгәлче җы-ены»** | Шәңгәлче; Иштирәк; Аулаш; Мартыш; Ташлык | ТР, Түбән Кама |
| 10. | **«Биклән җые-ны» яки «Казан-ский җыены»** | Биклән; Бакча-сарай; Суыксу; Чыбы-клы; Югары Нәлим; Сармашбаш | ТР, Тукай һәм Зәй |
| 11. | **«Кырык каен җыены» яки «Карамалы җыены»** | Карамал; Дүсем; Ләшәү Тамагы; Са-райлы; Кужак; Мәндәй; Якшы Каран; Чуар; Буралы; Ташлыяр; Тимеркәй; Утар; Баллы Тамак | ТР, Азнакай һәм Сарман |
| 12. | **«Сайфулла җые-ны» яки «Нөркә җыены»** | Олы Нөркәй; Иске Имән; Сарсаз-Тә-кермән | ТР, Минзәлә |
| 13. | **«Тирсә җыены»** | Иж елгасы кушылдыгы Чаж буе авыл-лары җыелган | ТР, Әгерҗе |
| 14. | **«Мәлле җыены»** | Мәлле Тамак; Нарат-Асты; Югары-, Түбән- Табын; Кәүҗияк; Туйгильде, Тегермәннек; Мәлле Шәрип; Мөтрәй; Мөслим | ТР, Мөслим |
| 15. | **«Ямалый җые-ны»** | Татар Ямалыйы; Иске Кабан; Яңа Ка-бан; Такталачык | ТР, Актаныш һәм БР, Красно-кама |
| 16. | **«Җамал җые-ны»** | Иске һәм Яңа Кабан; Такталачык авыл-лары җыелган. Ике республика чиге белән бүленгәч, «Ямалый җыены»ның БАССР ягында калган өлеше | БР, Краснокама |
| 17. | **«Бийкен җые-ны»** | Янавыл районы Әмҗә (Әмзә) елгасы буе авыллары җыелган | БР, Краснокама |

| тәр-тип № | Җыен атамасы | Кайсы авыллар җыелган? | Хәзерге административ район |
|---|---|---|---|
| 18. | **«Әлбәк җыены»** | Савызбаш; Кузгау; Җанҗегет; Иске һәм Яңа Мөште | БР, Краснокама |
| 19. | **«Уран җыены»** | Сәвәләй; Тау; Шулган; Салих; Югары Чат; Ямады; Кызыл-Яр; Йөгәмеш | БР, Янавыл һәм Тәтешле |
| 20. | **«Кайпан җые-ны»** | Иске Кайпан; Яңа Кайпан; Бүләк арты Кайпан (Кайпан-Бүлгарт); Калтәү; Шәрдәк; Сала-елга; Яңа Сала-елга; Бәдрәш; Ташлы-елга; Беләш, Авык; Карман; Салдау; Яңа Салдау; Аксәет; Чокыр; Югары, Түбән-Кодаш | БР, Тәтешле |
| 21. | **«Ачы җыены»** | Агыйделнең уң ягындагы «Урман як» яки «Идел эче» дип аталган төбәктә уздырылган. Чама белән БРның Краснокама, Калтасы районнары территорияләрендә булырга тиеш. Хатирәләр буенча Ачы исемле авыл да булган, диләр | БР, ? |
| 22. | **«Лаяшты җые-ны»** | Лаяшты; Араптан; Исмаил; Ишкар; Җитембәк; Чишмә; Сәет авыллары җыелган. | БР, Дүртөйле, Илеш |
| 23. | **«Әпкәрим җые-ны» яки «Колай җыены» яки «Абзай җыены»** | Әпкәрим; Абзай; Колай; Кушманак | БР, Борай |
| 24. | **«Олы җыен» яки «Уваныш җыены» яки «Җиләк җые-ны»** | Шабай; Каразирек; Котлыяр; Ямакай (Җөмәкәй); Кузбай; Ваныш-Алпавыт; Миңне; Байсәкә; Варҗы-тамак | БР, Борай |
| 25. | **«Кече җыен» яки «Тазлар җыены»** | Иске һәм Яңа Тазлар; Каргалы; Кан-сөяр; Бакалы | БР, Борай |
| 26. | **«Борай җыены»** | Борай; Чишмә-Борай; Үтәгән; Иске һәм Яңа Мостафа; Дүсмәт; Борай Әҗәге; Мулла; Шабай | БР, Борай |
| 27. | **«Күгәрчен җые-ны» яки «Көрҗә җыены»** | Сәет-Көрҗә; Таңгатар | БР, Борай |

| тәр-тип № | Җыен атамасы | Кайсы авыллар җыелган? | Хәзерге административ район |
|---|---|---|---|
| 28. | **«Ишбулды җые-ны» яки «Исәм-бай җыены» яки «Кузбай җые-ны»** | Кузбай; Ишбулды; Исәнбай | БР, Борай һәм Янавыл |
| 29. | **«Әйкәрим җые-ны» яки «Көпшә җыены»** | Имән; Нөркә; Сәйтәк; Усман | БР, Балтач |
| 30. | **«Танып буе җы-ены»** | Танып елгасы буе авыллары җыелган | БР, Балтач һәм Борай |
| 31. | **«Татыш җые-ны» яки «Бөр-тек җыены»** | Иске һәм Яңа Татыш; Аткүл; Ялгыз-на-рат; Иске һәм Яңа Каенлык; Иске һәм Яңа Бөртек; Иске һәм Яңа Хаҗи | БР, Краснокама |
| 32. | **«Чатра җыены»** | Чама белән Агыйделнең сул як якасын-дагы «Ил як» дигән төбәктә уздырыл-ган | БР, ??? |
| 33. | **«Буралы тавы җыены» яки «Уразай җые-ны»** | Буралы; Этәй; Теләпән; Югары Яркәй; Югары һәм Түбән Череккүл; Югары һәм Түбән Йонны; Исмаил; Базытамак | БР, Илеш |
| 34. | **«Базы җыены»** | Базы (Кый-кичү) елгасы тамагы авыл-лары | БР, Илеш һәм Дүртөйле |
| 35. | **«Казы җыены» яки «Шәмсет-дин (Шәмшады) күле җыены»** | Иске Баеш; Үткен; Мәмәдәл; Юкәлекүл (Яубазы); Иске Уртай; Гөлек; Казман; Әкәнәй (Кәчүән); Иске Яндыз; Мәскәү (Имәнәй); Иске Яндыз; Ишмәт; Каеш; Сабанай; Имай-утар; Урман-асты; Илек; Таскаклы авыллары.<br>Тагын Агыйделгә коючы Талбазы инеше буе чирмеш (мари) авыллары: Шалкан; Акуди; Акудибаш һәм Иске Базан халкы җыелган | БР, Бөре, Дүртөйле һәм Чакмагыш |
| 36. | **«Күәш җыены» яки «Ильский Күәш җыены»** | Югары-, Урта-, һәм Түбән- Карга (Кар-гавыл) авыллары; Әсән; Юкәлекүл; Юнтирәк; Иванай (Җобанай); Көшел; Гөблекөчек; Тәкәрлек | БР, Дүртөйле |
| 37. | **«Җуа җыены» яки «Нажы буе җыены»** | Әсән; Нажытамак; Коралачык; Игмәт; Абдулла; Югары һәм Түбән Манчар авыллары җыелган | БР, Дүртөйле һәм Илеш |

| тәр-тип № | Җыен атамасы | Кайсы авыллар җыелган? | Хәзерге административ район |
|---|---|---|---|
| 38. | **«Каратал җыены» яки «Бишкурай җыены»** | Бишкурай; Илек; Көшел; Тилегән; Иләкшиде; Югары һәм Түбән Манчар; Сүлте; Имәнлекул; Янтуган; Дүртөйле; Коралачык | БР, Дүртөйле һәм Чакмагыш |
| 39. | **«Тусары җыены» яки «Талбазы җыены»** | Сыйрыш елгасы тамагы тирәсе авыллары: Карача-елга; Талбазы; Гүмәр; Сәет; Чыршы-Тартыш; Ислан; Күсәдек һәм Агыйделгә коючы Талбазы инеше буе чирмеш (мари) авыллары: Усак; Куян; Ялгаш халкы җыелган | БР, Бөре, Кушнарин һәм Чакмагыш |
| 40. | **«Көпшә җирендәге җыен» яки «Дөмәй җыены»** | Иске һәм Яңа Дөмәй; Дүрмәнәй; Иске һәм Яңа Балак; Яңа Сөйдәм; Базы Күәше Караны (Каран-Мостай); Сөрмәт; Яңабирде; Тамьян; Иске һәм Яңа Илек; Сыйрышбаш (Әҗәк); Иштирәк; Күктау; Карабаш; Рсай; Үрмәт; Куян; Күккуян; Суккул; Туктагыл; Тыпый; Камай; Череккүл; Югары Яркәй; Йонлы; Ишмәт; Корыч; Кандалакбаш; Гөрдебаш; Мулланур; Иске Күккүл | БР, Бакалы, Илеш һәм Чакмагыш |
| 41. | **«Мәскәү төбәге җыены»** | Мәскәү; Тайняш (Туйнаш); Әхмәт; Рафыйк; Шаранбаш-Кенәз | БР, Чакмагыш, Шаран |
| 42. | **«Нажар җыены» яки «Җуа җыены»** | Ык елгасы буендагы Зирекле, Түбән Зәет, Алпай тирәсе авыллары җыелган | БР, Шаран |
| 43. | **«Шалтык җыены»** | Нарат-асты; Тархан; Шаран; Нурый; Чулпан; Түгәрәк; Сөнбаш; Базгыя | БР, Шаран |
| 44. | **«Чикәй җыены» яки «Сөн буе крестьян җыены»** | Иске һәм Яңа Чикәй; Иске һәм Яңа Тырбый; Шаранбаш-кенәз; Учтым; «Завод Каръяудысы» (Яңа Каръяуды) | БР, Бакалы һәм Шаран |
Язучы һәм галим Мөхәммәт Мәһдиев «Мирас» журналының 1992 елның август санында Габдрәшит хәзрәт турында «Тарихи кыңгыравык» дип аталган язмасын бастыра. Әлбәттә, аның бу мәкаләсе каршылыклы, шактый сак язылган, ул да Тукайларга ияреп, Габдрәшит хәзрәтне «надан карт» дип тә тамгалап узган. Әмма Мәһдиев тә аның көрәшче шәхес икәнен танырга мәҗбүр булган. «Р. Ибраһимов үз гомерендә матбугатта җылы сүз ишеткән кеше түгел, – дип яза ул. – Югыйсә, царизмның кан дошманы иде. ... Әмма Рәшид казый Ибраһимов шәхес иде. Көрәшче иде. Милләт, халыкны исә көрәшчеләр генә алга алып бара».

Миркасыйм Госмановның «Казан утлары» журналының 1994 елгы май ае санында басылган «Котсыз еллар кайтавазы» дип аталган күләмле язмасында кабат Габдрәшит Ибраһим темасына әйләнеп кайта. Тарихчы Индус Таһировның 1994 елда Казанда басылып чыккан «Бәйсезлек баскычлары» китабында да Габдрәшит хәзрәт шәхесенә зур урын бирелә. Ул еллардагы татар матбугатында япон һәм төрек галимнәренең дә Габдрәшит Ибраһим турында язмалары дөнья күрә. Габдрәшит Ибраһимның «Дәүре галәм (Дөнья тирәли)» хезмәтенең кечкенә бер өлеше, «Япония хәбәрләре» исеме астында, «Мирас» журналының 1995 елгы 3–4 саннарында дөнья күрә, аны галим Энгель Нигъмәтуллин әзерләп бастыра.

Галимә, үзе дә себер татары Флора Әхмәтова-Урманче һәм аның улы Айдар Урманче 1909 елда Казанда, «Бәянел-хак» газетасы нәшриятында басылып чыккан «Дәүре галәм» (Дөнья тирәли) китабын яңадан бастырырга әзерлиләр. Башта ул Чаллыда чыга торган «Ислам нуры» газетасында 1996–1997 елларда тулысынча дөнья күрә, аннан 2001 елда «Иман» нәшриятында аерым китап булып басылып чыга. Габдрәшит Ибраһимның 1907 елда Петербургта, 2001 елда «Иман» нәшриятында чыккан «Тәрҗемәи хәлем» китабын һәм «Дәүре галәм» (Дөнья тирәли) хезмәтен бергә туплап, Флора ханым аны 2001 елда Казанда яңадан бастырып чыгара, ул нибары 200 данә була. Шуны истә тотып, күренекле якташлары турында себер татарлары Габдрәшит Ибраһимның «Дәүре галәм» китабын 2007 елда Төмәндә, «Искер» нәшриятында 2000 данә

яңадан бастырып чыгаралар, бу мәшһүр галимнең 150 еллыгына матур бүләк була.

Күрәсез, XXI гасыр башында Габдрәшит Ибраһим милләтенә инде яңа рәвештә – үз китаплары аша кайта башлый. 2004 елда Казанда, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институтында, татар тарихында беренче тапкыр, Габдрәшит Ибраһим иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклана. Яшь галим Фәрит Галимуллин «Публицистические произведения Г.Р. Ибрагимова как источники для изучения татарского общественно-политического движения (начало XX в.)» дигән темага тарих буенча диссертация яклый, аның фәнни җитәкчесе танылган галим Миркасыйм Госманов була. Бу хезмәтендә Фәрит Галимуллин егерменче гасыр башындагы татар хәрәкәтенә, Габдрәшит Ибраһимның бу милли күтәрелештә тоткан урынына, аның сәяси эшчәнлеге турында җентекле анализ ясый. Ул шулай ук аның «Автономия яки Идарәи мохтарият» хезмәтенә һәм «Иттифак әл-мөслимин» фиркасендәге эшчәнлегенә зур бәя бирә. Аңа кадәр Фәрит Галимуллинның «“Ислам императоры” – Рәшит казый» мәкаләсе «Казан утлары» журналының 2000 елгы март санында, «Рәшит Ибраһимовның “Автономия”»се язмасы «Идел» журналының 2001 елгы март санында, шул ук «Идел» журналының рус вариантында «Деятельность А. Ибрагимова на Дальнем Востоке (1908–1910 гг.)» мәкаләсе (2002, №2), шулай ук «Научный Татарстан», «Мәгариф» һәм башка газета-журнал битләрендә күләмле язмалары дөнья күрә.

«Габдрәшит Ибраһим – туган халкының, дин кардәшләренең хокукларын эзлекле яклаучы, шулай ук колонизаторлык сәясәте алып барган көчләргә каршы көрәшүче булды, – дип яза Ф. Галимуллин. – ... Мәгълүм булганча, Г. Ибраһим гомер буе бөтен дөньядагы мөселманнарны бер милләткә берләштерү һәм татарларга милли бәйсезлек яулап алу идеяләре арасында “өзгәләнде”. ... Татарлар арасында Г. Ибраһим Русиянең милли-дәүләт корылышын чын фәнни нигездә үзгәртеп кору теоретикларының берсе иде» [Ибраһим: 2011].

Яңа гасырда Габдрәшит Ибраһим мирасын өйрәнергә яңа буын вәкилләренең килүе сөендерә. Алар арасыннан мин тарихчылар Айдар Хәбетдинов, Лариса Усманова, Диләра Усманова, Әлфрид Бостановларны аерып күрсәтер идем. «Иттифак әл-мөслимин» фиркасе материалларын җентекләп өйрәнгән галим Айдар Хәбетдинов әле моннан егерме ел элек Габдрәшит хәзрәтне «татарның беренче сәясәтчесе» дип атаган, аны шул замандагы мөселман иҗтимагый хәрәкәтенең үзәк фигурасы икәнен әйткән, автономия принципларына тугры калган бердәнбер сәяси эшлекле булуын таныган. Айдар Хәбетдинов соңгы егерме елда рус һәм татар телләрендә Габдрәшит Ибраһим турында күп мәкаләләр язып бастырды,

алар Татарстанда гына түгел, Мәскәү матбагаларында да дөнья күрде. Лариса Усманова исә Габдрәшит Ибраһимның Япония чорын шунда барып өйрәнгән һәм шул турыда күп санлы хезмәтләр язган бердәнбер галимә. Соңгы елларда аның «Гасырлар авазы – Эхо веков» журналында Габдрәшит Ибраһим турында дистәләгән фәнни мәкаләсе басылып чыкты, Ерак Көнчыгышта мөселман-татарлар тарихына багышланган инглиз телендәге китабының бер өлеше Габдрәшит Ибраһим хакында иде. Әлфрид Бостанов исә якташы Габдрәшит хәзрәтнең Төркиядәге Бөгеределек авылында сакланган көндәлек күчермәсен Казанга алып кайтып, аны аерым китап итеп чыгаруы белән үзенчәлекле. Дөрес, бу тарихи көндәлек төрек галиме Ибраһим Мараш тарафыннан бу гасыр башында ук табылып, ул хакта матбугатта игълан ителгән иде, әмма Габдрәшит Ибраһимның «Бөгеределек көндәлеге» китап булып Казанда бары тик 2013 елда гына басылып чыкты һәм бу изге гамәлне яшь галим Әлфрид Бостанов башкарды.

1907 елда Габдрәшит Ибраһимов төрекчәдән тәрҗемә итеп, Петербугта бастырып чыгарган «Мең дә бер хәдис» китабы 2005 елда Казанда, «Раннур» нәшриятында кабат дөнья күрә, аны басмага галим Сәлим Гыйләҗетдинов әзерли. Китап авторы Гариф Бик булса да, тәрҗемә иткәндә Габдрәшит Ибраһим комментарий-шәрехләрне татар тарихыннан һәм тормышыннан алып, үзе яза, шуның өчен, хөкүмәткә каршы язган, патшага каршы котырткан, дип, аны хөкем итәләр, китапны җыеп яндыралар. Әмма йөз елдан соң бу китап яңадан милләткә әйләнеп кайта!

2011 елда исә гасыр буе көткән тагы бер вакыйга була – «Җыен» нәшриятының «Шәхесләребез» сериясендә «Габдерәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык» китабы басылып чыга, аны басмага Миркасыйм Госмановның шәкертләре әзерли. Бу китапта татар, төрек, япон, алман галимнәренең Габдрәшит хәзрәт турында фәнни язмалары, аның үзенең мөһим дип табылган хезмәтләре, тарихи документлар һәм сирәк фотолар урын алган, мәкаләләр татар һәм рус телләрендә бирелгән.

Башка татар тарихчылары да, үз чорларын һәм темаларын өйрәнгәндә, Габдрәшит Ибраһим белән бәйле материалларны табып дөньяга чыгардылар, шундыйлардан Искәндәр Гыйләҗев һәм Илдус Заһидуллинны атарга мөмкин. Шулай ук чирек гасыр Малайзиядә яшәгән милләттәшебез, галимә Әлмира Әхмәтова да фәнни хезмәтләрендә Габдрәшит Ибраһимга зур урын бирде, дөнья энциклопедияләре өчен аның турында фәнни мәкаләләр язды.

2015 елның июнендә, тарихта беренче тапкыр, Казанда Габдрәшит Ибраһимның иҗади эшчәнлегенә багышланган Халыкара фәнни конференция булды, анда Татарстан, Төркия һәм Япония галимнәре катнашты

һәм чыгыш ясады. 2017 елда тагы бер шатлыклы вакыйга булды – Казанда Габдрәшит Ибраһимның кызы Фәүзия Ибраһимованың «Аш остасы. Ханымнарга һәдия» дип аталган китабы ике телдә басылып чыкты. Китапны В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты 1915 елгы нөсхә буенча әзерләп бастырды. Китапны халыкка тәкъдим итүдә Габдрәшит Ибраһимның оныкчыгы, Төркия кунагы Нәслихан Арул Оксой да катнашты, бу нур өстенә нур булды. Шунысын да әйтергә кирәк, бу очрашу Габдрәшит Ибраһимның тууына 160 ел тулган көннәрдә булды, тарихи-мәдәни чаралар Казанның «Татар утары»нда һәм Мәрҗани исемендәге Тарих институтында үтте.

Шул ук елны «Безнең мирас» журналы да укучыларына зур бүләк ясады – 2017 елның гыйнвар саныннан башлап, Габдрәшит Ибраһимның «Ислам дөньясы» (Галәм-и Ислам) китабын бастыра башлады. Аны төрекчәдән татарчага галимә Асия Рәхимова тәрҗемә иткән, кереш сүзне дә ул әзерләгән. Бу титаник хезмәтнең беренче китабы дүрт ел буе журнал битләрендә басылып килде, 2021 елның гыйнварыннан исә икенче китабы басыла башлады. Кереш сүздән күренгәнчә, «Безнең мирас» журналы редакциясе Габдрәшит Ибраһимның бу китабын тулысынча татар телендә дә бастырып чыгарырга уйлый икән, бу инде чын мәгънәсендә Габдрәшит хәзрәтнең милләткә кайтуы булачак!

Бу олуг галимнең хезмәтләренә рус телендә дә ихтыяҗ бар икән – быел Казанда басылып чыккан «Мусульмане на Дальнем Востоке России: история и современность» китабында Габдрәшит Ибраһимның «Ислам дөньясы» китабының Ерак Көнчыгыш өлеше гарәпчәдән русчага тәрҗемә итеп бирелгән. Монда аның нигездә, 1908 елда Себер буенча Ерак Көнчыгыш тарафына сәяхәтенең Иркутск, Томск, Чита, Улан-Уде, Владивосток, Харбин, Манчжурия өлешләре урнаштырылган. Китапның төзүчесе, монография авторы тарихчы Алексей Старостин Габдрәшит хәзрәтнең энциклопедик дәрәҗәдә күзәтүләрен, шул чордагы мөселман-татарлар тормышын һәм ислам диненең торышын рус теле аша киң катлам укучыларга җиткергән.

Инде үземнең дә Габдрәшит Ибраһим темасына ничек зурлап тотынуымны язып үтәргә кирәк, бу хәлләр 2007 елда башланды һәм минем тормышымның аерылгысыз өлешенә әйләнде. Дөрес, мин аның турында элек тә укып, ишетеп белә идем, үзем дә 90-нчы еллардан заманында ул оештырган «Иттифак» фиркасен яңадан торгызып җитәклим, тарихта да аның исемен еш очрата идем. 2007 елның мартында, Германиягә китап ярминкәсенә килгәч, мин Мюнхен шәһәрендә себер татарлары белән очраштым, алар моннан йөз ел элек Габдрәшит Ибраһим ярдәмендә Себердән Төркиягә күчерелгән Бөгеределек авылыннан булып чыкты.

Бу татарлар алман илендә инде күптән яшиләр, әмма Төркия белән дә элемтәләрен өзмиләр икән. Фаяз Каплан дигән милләттәшемнең өстәлендә Коръән белән янәшә, Габдрәшит Ибраһим китапларын күреп, мин бик гаҗәпләндем, алар бу шәхесне олылап, һаман да татарчалап, «бабай» дип йөртәләр.

Бу татарлар мине Бөгеределек авылының йөзьеллык юбилеена чакырдылар, шул җәйдә уздырылачак икән. Мин моны Казанга, Бөтендөнья татар конгрессына кайтып әйттем, Мәдәният министрлыгы бу бәйрәмгә Татарстаннан зур делегация җибәрде. Мин дә бу тантанада катнаштым, чыгыш ясадым, Бөгеределек халкына үземнең «Күчем хан» китабымны бүләк иттем, Себердә яшәүче туганнарыннан күп сәламнәр тапшырдым. Чөнки аңа кадәр мин Себердә, Габдрәшит Ибраһимның туган якларында – Тара шәһәрендә, Омскида, ул яктагы татар авылларында булып кайттым, анда Габдрәшит хәзрәтнең 150 еллык гомер бәйрәмен мәчетләрдә Коръән укытып, зур залларда очрашулар уздырып билгеләп үттек. Шушы вакытлардан мин Габдрәшит хәзрәтнең тормышы һәм иҗаты белән ныклап кызыксына башладым һәм аны тарихчы һәм язучы буларак өйрәнергә тотындым.

Ул вакытта минем татар матбугатында Габдрәшит Ибраһим турында зур-зур язмаларым басылып чыкты: «Милләт бабасы» («Ватаным Татарстан», 2007, 5 май), «Татарның бөек мөһаҗире» («Мәдәни җомга», 2007, 8 июнь), «Төркиядә татар авыллары» («Шәһри Казан», 2007, 4–8 август), «Себердәге татар авыллары» («Мәдәни җомга», 2007, 13 июль–10 август), «Тубыл каласы таш кала...» («Шәһри Чаллы», 2008, 12 март–14 май), «Төркия: шәһәрләр һәм шәхесләр» («Мәдәни җомга», 2008, 11 июль–1 август), «Себер иленә сәяхәт» («Казан утлары», 2008, №8–10), «Истанбул шәхесе» («Мирас», 2008, №11).

Минем тарафтан Габдрәшит Ибраһимның тормышын һәм иҗатын өйрәнү алга таба да дәвам итте, болар барысы да диярлек вакытлы матбугатта яктыртыла килде. Алар арасында «Габдрәшит Ибраһим һәм исламчылык», «Габдрәшит Ибраһим һәм Тукай», «Габдрәшит Ибраһим укыган авылда», «Курган якларында Габдрәшит Ибраһим эзләре», «Томскида Габдрәшит Ибраһим эзләре», «“Һиҗрәт” романында Габдрәшит Ибраһим образы һәм Япония темасы», «Япония-Татарстан бәйләнешлары», «Великий татарский миссионер», «Габдрәшит Ибраһим – Япониядә татарны танытучы», «Габдрәшит Ибраһимның Төркиядә һәм Германиядә сәяси эшчәнлеге (1910–1915)», «Габдрәшит Ибраһимның Европадагы сәяси эшчәнлеге (1915–1916)» һәм бу темага башка язмаларым бар иде.

Моннан тыш ул елларда Габдрәшит Ибраһимов турында махсус докладлар белән төрле Халыкара фәнни конференцияләрдә катнаштым.

2008 елның 3–5 апрелендә Төркиянең Истанбул шәһәрендә үткән «Төрки әдәбиятта Истанбул» дип аталган Халыкара Симпозиумда «Габдрәшит Ибраһимов иҗатында һәм тормышында Истанбул» дигән темага доклад ясадым. 2008 елның 23–25 октябрендә Казан шәһәрендә үткәрелгән «Татар галимнәренең ислам үсешенә керткән өлеше» дип аталган фәнни конференциядә «Габдрәшит Ибраһимовның милләт һәм ислам үсешенә керткән өлеше» дигән темага доклад ясадым. 2008 елның 29–30 ноябрендә Тубыл шәһәрендә үткән «Выдающиеся деятели тюрко-татарского мира XIX–XX вв. и их роль в научной и общественной жизни сибирских татар» дип аталган, Габдрәшит Ибраһимның 150 еллыгына багышланган фәнни конференциядә Габдрәшит хәзрәт турында «Татарның бөек миссионеры» («Великий татарский миссионер») дип аталган доклад ясадым. 2012 елның 22–23 май көннәрендә Төркиянең Бөгеределек авылында һәм Җиһанбәйле илчесендә Габдрәшит Ибраһимга багышланган мәдәни чараларда, Кония шәһәренең Селчук университетында уздырылган фәнни конференциядә катнашып, чыгышлар ясадым, аның туган яклары турында фотоальбомның презентациясен күрсәттем. Бу тантаналарда Габдрәшит Ибраһим иҗатын өйрәнүче һәм пропагандалаучы галимнәргә, шул исәптән, миңа да, Габдрәшит Ибраһим исемендәге махсус бүләк тапшырылды. Шулай ук 2015 елның июнендә Габдрәшит Ибраһимга багышлап Казанда узган Халыкара фәнни конференциядә, 2017 елның апрелендә аның кызы Фәүзия Ибраһимның китабын тәкъдим итү чараларында да катнашып, чыгышлар ясадым. 2018 елның 23–24 июлендә Казанда, Мәрҗани исемендәге Тарих институтында узган «Япония-Татарстан багланышлары» дип аталган Халыкара фәнни конференциядә «“Һиҗрәт” романында Габдрәшит Ибраһим образы һәм Япония темасы» дип аталган темага доклад ясадым. 2019 елның 15 ноябрендә Томски шәһәренең Татар мәдәният үзәгендә уздырылган «Хәмитов укулары»нда катнашып, «Томскида Габдрәшит Ибраһим эзләре» дип аталган темага чыгыш ясадым.

Һәм ниһаять, ун елдан артык эзләнүләрем нәтиҗәсендә, мин Габдрәшит Ибраһим турында ике китап язып бастырдым – «Һиҗрәт» тарихи романы һәм «Габдрәшит Ибраһим – милләтнең хокук яклаучысы» дип аталган фәнни-популяр язмалар җыентыгы. 480 битле, үзе өч китап-трилогиядән торган «Һиҗрәт» китабы башта үзебезнең хисапка Казанда, 2017 елда басылып чыкты, икенче тапкыр аны 2020 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарды, анысы 560 бит. Ә «Габдрәшит Ибраһим – милләтнең хокук яклаучысы» фәнни-документаль китабым 2021 елда дөнья күрде, аны да үз хисабыбызга чыгардык. Бу китапларны язар өчен миңа Россия һәм чит ил архивларында да эшләргә, Себердә һәм Төркиядә яшәү-

че милләттәшләрем белән бик күп очрашулар уздырырга, Бөгередәлек авылы һәм Кония шәһәрләрендә өйдән-өйгә йөреп, йөз ел элек һиҗрәт кылган татарларның шәхси архивларын өйрәнергә туры килде. «Һиҗрәт» китабы басылып чыккач, мин аны күтәреп, тагы Себергә, Төркиягә чыгып киттем, Омск, Тара шәһәрләрендә, Үләнкүл авылында, Төркиянең Бөгередәлек авылында, Анталиядә, Искешәһәрдә, Татарстанның Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә бу тарихи китапның презентацияләре узды. Хәзер бу китапларны төрекчәгә һәм башка телләргә тәрҗемә итү турында сүзләр бара.




Габдрәшит Ибраһимның бай мирасын өйрәнү дәвам итә. Эшләгән эш күп кебек күренсә дә, эшлиселәре тагы да күп... Дөньяның бер генә илендә дә Габдрәшит хәзрәтнең музее юк, архивы бер урынга тупланмаган, аның исемендә урамнар, премияләр дә юк, һич югы «Габдрәшит Ибраһим укулары» дип аталган фәнни җыеннар да юк. Себер моны күтәрә алмый, чит илләрдә дә бу тема галимнәр өчен генә кирәк, димәк, Габдрәшит хәзрәтне күтәрү тагы Казанга, безгә кала...

Аллаһы Тәгалә Габдрәшит хәзрәткә озын гомер бирә – ул 87 яшендә, Токиода, үзе тәрбияләгән татар һәм япон мөселманнары арасында бакыйлыкка күчә, шунда җирләнә. Ул кайда гына яшәсә дә, иманына һәм милләтенә тугры булып кала – мөселман-татар булып яши, мәңгелеккә дә шул рәвешле – Гомәр улы Габдрәшит булып күчә... Үз бәйсез дәүләте булса, аның ханы-солтаны булырлык шәхес безгә ничек яшәү һәм көрәшү үрнәген калдырып китә...

Габдрәшит хәзрәт, дин, дип, милләтен ташламый, милләт, дип, диннән китми, икесен дә тигез алып бара, безгә дә шул юлны үрнәк итеп калдыра. Остазыбызның урыны җәннәттә булсын, ерак Япон илендәге кабере нур белән тулсын, эчкерсез догаларыбыз, туган яктан искән җилләр белән бергә, аның рухына барып ирешсен! Амин!

**Әдәбият**

1. Бостанов Әлфрид. Кереш сүз / Габдеррәшит Ибраһим. Бөгределек көндәлеге. Казан, 2013.

2. Бәйрәмова Фәүзия. Туран иле. Казан, 2008.
3. Бәйрәмова Фәүзия. Милләт һәм дәүләт. Казан, 2009.
4. Бәйрәмова Фәүзия. Дала Атлантидасы яки эчкен татарлары. Казан, 2013.
5. Бәйрәмова Фәүзия. Милләт тарихы. Казан, 2016.
6. Бәйрәмова Фәүзия. Һиҗрәт. Тарихи роман. Казан, 2017.
7. Бәйрәмова Фәүзия. Милләт язмышы. Казан, 2020.
8. Бәйрәмова Фәүзия. Габдрәшит Ибраһим – милләтнең хокук яклаучысы. Казан, 2021.
9. Валеев Ф.Т. Сибирские татары: культура и быт. Казань, 1992.
10. Галимуллин Фарит. Публицистические произведения Г.-Р. Ибрагимова как источники для изучения татарского общественно-политического движения (начало XX в.). Рукопись диссертации, библиотека Казанского Государственного университета (Габдрәшит Ибраһимов буенча диссертация кулъязмасы, Казан дәүләт университеты китапханәсендә саклана). 2003.
11. Галимуллин Фәрит. Габдерәшит Ибраһимның тормыш юлы / Габдерәшит Ибраһим. Казан, 2011.
12. И.А. Гилязов, Л.Р. Гатауллина. Российские солдаты-мусульмане в германском плену в годы Первой мировой войны. Казань, 2014.
13. Госманов Миркасыйм. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан, 1984.
14. Госманов Миркасыйм. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан, 1994.
15. Ибраһимов Габдеррәшит. Дәүре галәм (Дөнья тирәли). Тәрҗемәи хәлем. Казан, 2001.
16. Ибраһим Габдерәшит. Фәнни-биографик җыентык. Казан, 2011.
17. Ибраһим Габдерәшит. Бөградәлек көндәлеге. Казан, 2013.
18. Ибраһимова Фәүзия. Аш остасы. Ханымнарга хәдия. Казан, 2017.
19. Исхакый Гатаулла. Габдрәшид хәзрәт Ибраһимов. Казан утлары, 1994, № 5.
20. Кәримуллин Әбрар. Язмыштан узмыш...// Идел, 1990, № 5–6.
21. Кәримуллин Әбрар. Япония вә төрки-татарлар // Социалистик Татарстан, 1991.
22. Мусульмане на Дальнем Востоке России: история и современность. Казань, 2021.
23. Мәһдиев Мөхәммәт. Тарихи кыңгыравык // Мирас, 1992, № 8.
24. Тюркоглу Исмаил. Себерияле мәшһүр сәяхәтче Габдерәшит Ибраһим / Габдерәшит Ибраһим. Казан, 2011.
25. Тәүфикъ Әйди. Габдрәшит Ибраһим // Идел, 1991, № 1.

26. Усманова Диляра. Габдерашит Ибрагим и журнал «Der Neue Orient»: недолгое сотрудничество / Габдерәшит Ибраһим. Казан, 2011.
27. Усманова Лариса. Габдерәшит Ибраһим Япониядә / Габдерәшит Ибраһим. Казан, 2011.
28. Хабутдинов Айдар. Лидеры нации. Казань, 2003.
29. Хабутдинов А.Ю., Мухетдинов Д.В. Всероссийские мусульманские съезды 1905–1906 гг. Нижний Новгород, 2003.
30. Шихова М.Х. Село Яланкуль и его жители – потомки Авасбакы-шейха. Шаджара. Омск, 2018.
31. Abdurresid Ibrahim. Alem-i Islam ve Japonyada Islamiyetin Yayilmasi. cild II. Istanbul, 2003. Abdurresid Ibrahim. Alem-i Islam. Konya, 2012.
32. Abdurresid Ibrahim. Alem-i Islam ve Japonyada Islamiyetin Yayilmasi. cild I. Istanbul, 2003.
33. Abdurresit Ibrahim. Uluslararasi Abdurresit Ibrahim ve Turk-Japon iliskieleri bilgi soleni 22–23 mayis 2012. Konya. BILDIRILER. Konya, 2012.
34. Ismail Turkoglu. Sibiryali Meshur Seyyah ABDURRESID IBRAHIM. Ankara, 1997.
35. Ali Merthan Dundar. Panislamizmden Buyuk Asyaciliga. Istanbul, 2006.
36. Ali Merthan Dundar. Japonyada turk izleri. Ankara, 2008.
37. Toplumsal Tarih. Turkya. 1995, Nomer – 19–20.
38. Larisa Usmanova. The turk-tatar diaspora in northeast asia. Tokyo, 2008.
39. Sebastian Cwiklinski. Abdurresid Ibrahim’in Birinci dunya sabasinda Almanya ve Isvec’teki faaliyetleri / Abdurresit Ibrahim. Uluslararasi Abdurresit Ibrahim ve Turk-Japon iliskieleri bilgi soleni 22–23 mayis 2012. Konya. BILDIRILER. Konya, 2012.
40. ГАОО. Ф. 10. Тасв. 4. Эш 412.

*Тәэминә Биктимирова*

## ИСЛАМИЯТ ГАЛИМЕ

Кылган гамәлләре һәм дөньяга карашы, таланты белән халкыбыз тарихында һич тә югалмаслык урында булырга тиешле олуг шәхесләребез арасында исламият галиме, нәшир һәм мөхәррир, мәшһүр мөгаллим Кәшшафетдин хәзрәт Тәрҗемани да бар.

Аның гомер юлы 1877 елның 22 июлендә Казан губернасы Спас өязе (Татарстанның хәзерге Әлки районы) Иске Әнҗерә авылында башлана. Әтисе – Кыяметдин Камалетдин улы 90 яшенә кадәр Иске Әнҗерә авылының мулласы, әнисе Мәгъмүрә Гатаулла кызы остабикәсе булып, халыкка игелекле хезмәт күрсәтеп яшәгән хөрмәтле затлар булганнар икән. Әйтеп үтим, Кыяметдин мулланы, яхшылыкның кадерен белгән авылның игелекле кешеләре, колхозлашу чорында да, һәртөрле җәберләнүләрдән саклап кала алганнар.

Башлангыч белемне үз әтисеннән ала Кәшшафетдин, соңрак әтисе аны Казанга, үзе белем алып чыккан атаклы Мәрҗани мәдрәсәсенә илтә. Сәләтле бала мәдрәсәне уңышлы тәмам итә һәм шунда ук мөгаллим булып кала.

Күп тә үтми, яшь мөгаллимне Яңа Бистәдәге 1805 елдан бирле эшләп килгән унберенче Җәмигъ мәчетенә имам итеп сайлыйлар. Имамлык вазифасын уңышлы башкару белән бергә, ул үз йорты ишегалдында махсус бина салдырып, мәдрәсә дә ачып җибәрә. Архив материалларыннан күренгәнчә, ул мөгаллим һәм имамлык вазифаларын 1904–1917 елларда дәвам иткән.

Шунысы да мәгълүм, мәдрәсә Кәшшафетдин хәзрәтнең тырышлыгы белән Казанның иң алдынгы уку йортларының берсенә әверелә. Ул 4 сыйныфлы булып, анда Коръән, дин белеме, Ислам тарихы, хокук, гарәп теле һәм грамматикасы белән беррәттән, ана теле, арифметика, матур язу, география һ.б. фәннәрдән төпле белем бирелгән. Шәкертләрнең күбесе Казан, Сарытау, Вятка һәм Самара губерналарыннан килгән яшьләрдән торган икән. Кәшшафетдин Тәрҗемани белән бергә мәчет һәм мәдрәсәдә киң тәҗрибәле һәм белемле белгечләр – Әхмәтҗан Исхаков, Әхмәт Урманчеев, Мөбарәкҗан Мансуров кебек танылган дин галимнәре эшләгән. Мәдрәсәдә укуларның җәдиди булуын әйтү дә урынлы булыр сыман.

Шушы елларда аның Галимҗан Баруди җитәкчелегендә чыга торган «Әд-дин вә әл-әдәб» журналында иҗади хезмәттәшлеге дә башланып китә.

Тагын архив материалларына мөрәҗәгать итик, чөнки документ алдынгы карашлы мөгаллимнәрнең нинди шартларда эшләгәнен ачык күрсәтә.

Казан губернасы халык училищелары директоры Н.А. Феликсов 1907 елның 5 маенда Казан уку округы попечителе А.Н. Деревицкийга язган хатында болай дип күрсәтә: «Миңа килеп җиткән мәгълүматларга караганда, Яңа Бистәдәге Якупов мәдрәсәсендә (бу Галимҗан Барудиның бертуган энесе Салихҗан Баруди эшләгән мәдрәсә) мөгаллимнәр өчен курслар ачылган. Курсларда аларга мөселман дине буенча гына түгел, ә бәлки тарих, география, арифметика, геометрия, педагогика фәннәре укытылачак икән. Курсларда Салихҗан Галиев белән Тәрҗемановтан башка Галимҗан Галиев (ягъни Мөхәммәдия мәдрәсәсе) укытучылары дәресләр бирәчәкләр һәм сүз әле тагын укыту программалары хакында да барачак икән. Курслар тиешле рөхсәт белән ачылмаганга... мин бу хакта губернаторга да хәбәр җибәрдем» [ТР МА. Ф. 92. Тасв. 2. Эш 7084. Б. 3.; Медресе: 2007. С. 319]. Курсларны ачу өчен ничә мәртәбәләр рөхсәт сорап та бер генә тапкыр да уңай җавап бирелмәвен Феликсов күрсәтеп торырга кирәк санамаган, ахры.

Чынлап та курслар «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә ачыла һәм Казан, Уфа, Вятка һәм башка губерналардан 60лап мөгаллим килә. Тик, ни кызганыч, өметләр җимерелә. Фәннәрне укытуда фикер алышырга, белемнәрен күтәрергә дип өметләнгән мөгаллимнәр укыган мәдрәсә бинасын 24 май көнне 60 городовой чорнап ала. Бинада тентү ясала, барлык дәреслекләр һәм мөгаллимнәрнең язмалары, дәфтәрләре тартып алына. Хәтта, мәдрәсә бинасы ябылып куела. Мөгаллимнәрдән сорау алына һәм тиз арада күбесе Казаннан сөрелә.

Бу документ үзе генә дә Тәрҗемани кебек хәзрәтләребезнең, күренекле зыялыларыбызның нинди шартларда татар мәгарифен үстерү өчен авыр көрәшләрен күрсәтә. Ә Кәшшафетдин исә гомере буена Галимҗан, Салихҗан Галиевләрнең фикердәше, хезмәттәше булып кала.

1915 елны Кәшшаф Тәрҗемани үзенең остазы «Шиһабетдин Әл Мәрҗани хәзрәтләренең тууына 100 ел тулу мөнәсәбәте илә» Шәһәр Шәрәф, Габдулла Гыйсмәти, Таһир Ильяси, Газиз Гобәйдуллиннар белән берлектә зур кыйммәткә ия булган хатирәләр җыентыгы хәзерләүдә тырышлык күрәсәтә. Аның шушы мәҗмугада «Мәрҗанинең мәсаиле игътикадиядә тоткан юлы» дип исемләнгән язмасы галимнең иман гыйльме тәүхид, Кәлям, Ислам фәлсәфәсе, Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары, галәм яратылышы, пәйгамбәрләрне олылау, ислам хакимнәренә, шәригать һәм хикмәт мәсьәләләренә карашларын җентекләп тикшерүгә багышланган [Мәрҗани: 1915. Б. 222–271].

Февраль революциясеннән соңгы чор – татар халкының милли азатлыкка өметләнеп көрәшкән чоры. Татарның иң күренекле, иң алдынгы шәхесләре үз дәүләтебезне торгызу омтылышы белән яшиләр, бергәләп

киңәшү өчен бер-бер артлы съездлар үткәрәләр. Милли Мәҗлес оештырыла, Идел-Урал штаты төзү идеясе күтәрелә. Шушы көрәшчеләр арасында Кәшшафетдин хәзрәт тә иң алгы сафта бара. Ул үзен дини һәм милли хокуклар өчен көрәшче буларак таныта, 1917 елгы Бөтенроссия мөселман корылтайларының барысында да һәм Милли Мәҗлес эшендә катнаша, Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Милли идарә әгъзасы итеп сайлана. Дин әһелләренең тормышларын яхшырту, дини корылмаларның һәм алар каршындагы уку йортларының төзеклеге турында кайгырту мәсьәләләрен алга куйган «Мөселман руханилары иттифагы» Уставын һәм документларын әзерләгәндә дә башлап йөрүчеләрнең берсе була.

Кәшшафетдин Тәрҗеманинең милли берләшүгә һәм иҗтимагый-мәдәни үсешкә юнәлдерелгән эшчәнлеге фикердәшләре арасында киң яклау таба. 1917 елда СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Мәркәз Диния нәзарәтенә казый итеп сайлануы шул хакта сөйли дә инде. Ул инде гаиләсе белән Өфегә күчеп килә. Бу урында хәзрәтнең гаиләсе хакында искәртеп китсәк тә артык булмас. 1913 елны яшьли никахлашкан хатыны Хәдичә ханым вафатыннан соң, ул Галимҗан Барудиның туганы Гайшә Хөсәен кызына өйләнә. Бу никахтан Мәрьям һәм Сара исемле ике кыз баласы да була. Хәдичә ханым белән уртак ир баласы – Идрис Тәрҗеманов – ялгышмасам, Бөек Ватан сугышында һәлак була.

Икенче никахы гомер буе бергә-бергә эшләгән, 1917 елда мөфти булып сайланган Галимҗан Баруди белән араларын тагын да якынайта. Алар Диния нәзарәтенең эшен шулай бергә алып баралар. Озак та үтми, Кәшшафетдин Тәрҗемани мөфтинең рәсми урынбасары булып та сайлана, 1920–1930 елларда Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсенең алыштыргысыз мөдәррисе дә була ул.

1921 елда Идел буенда һәм бигрәк тә Татарстанда коточкыч ачлык башлангач, Диния нәзарәтенең Г. Баруди җитәкчелегендә халыкны ачлык афәтеннән коткару планы эшләнә. Диния нәзарәтенең Мәскәү шәһәрендә өч кешедән торган вәкаләтле комиссиясе барлыкка китерелә. Кәшшафетдин хәзрәт Үзәк Диния нәзарәтенең Ачларга һәм ятим балаларга ярдәм итү буенча вәкаләтле комиссиясе рәисе вазифасын үз өстенә ала. Чөнки хәзер Диния нәзарәтенә Үзәктә оештырылган ачларга ярдәм комитеты (Помгол) белән бергәләп эшләргә кирәк була. Чөнки бары тик бу оешма аркылы гына чит ил мөселманнары белән бәйләнешкә керергә мөмкин була. 1921 елның ноябрендә Галимҗан Баруди белән бергә шушы эшне юлга салу максатында Кәшшафетдин Тәрҗемани Мәскәүгә килә. Ярдәм комитетына күренекле дин әһелләре дә чакырыла. Мөселман дөньясында зур абруй казанган дин галимнәреннән Таһир хәзрәт Ильяси, Гобәй-

дулла Буби – Төркиягә, Садыйк хәзрәт Иманколый Урта Азиягә ярдәм җыярга китәләр. Мисыр, Маньчжурия, Финляндия, Кытай, Әфганстанга ярдәм сорап үтенеч хатлары җибәрелә. Бу тырыш хезмәтнең нәтиҗәләре дә шактый сизелә. Бу урында эмиграциягә китәргә мәҗбүр булган ватандашларыбызның ярдәмен дә олы рәхмәт хисләре белән искә алу һич тә артык булмас.

Аллаһның рәхмәте булсын, мөселман илләреннән ярдәм җибәрелә дә. Бу хакта Таһир хәзрәт Ильяси хакында язылган мәкаләмдә дә әйтеп киткән идем инде. Әмма татар халкын ачлыктан коткаруда изге эш кылган шәхесләребезнең исемнәрен күбебез белми дә бит әле.

Кәшшафетдин хәзрәт «Ачларга ярдәм» комитетында 1923 елның ахырына кадәр эшли. 1924 елның август аенда Кәшшафетдин Тәрҗемани мөхәррирлеге һәм нәширлегендә «Ислам» мәҗәлләсе, ягъни журналы чыга башлый, ләкин 1927 елның ахырында аның чыгу туктала. Бу хәлне журналның авторларына, дингә карата һөҗүм якынаю белән генә аңлатып буладыр. Тик шунысы ачык: «Ислам» мәҗәлләсе һәм аның җаваплы мөхәррире Кәшшаф казый Тәрҗемани дөньякүләм танылa. Өфедәге Диния нәзарәте СССРның барча мөселманнары мәркәзе булып китә. Моны изге берләшү дип бәһаләргә мөмкиндер.

1926 елның март азагында Диния нәзарәтенә Согуд Гарәбстаны Мәккә шәһәреннән, ягъни Ислам динебезнең бишегеннән тарихта беренче мәртәбә буларак бөтен дөнья мөселманнары конгрессына чакыру килә. Кәшшафетдин хәзрәт шунда ук Мәскәүгә барып, Тышкы эшләр халык комиссары Г.Н. Чичериннан вәкилләр җибәрү өчен рөхсәт алып кайта. 27 апрельдә Өфедә мөселманнарның рәсми җыелышы үткәрелә. Кәшшафетдин казый, Мәккә-Мәдинә вә бөтен Гарәбстан тарихы, вә дини хәлләре турында киң мәгълүматлы чыгыш ясый. Ниһаять, 6 май көнне СССР мөселманнарыннан җиде вәкил – мөфти Ризаэддин Фәхреддин, Кәшшафетдин Тәрҗемани (Диния нәзарәтеннән), Габдрахман Гомәри (Әстерхан), Таһир Ильяси (Казан), Габделхак карый Габделрафик (Төркестан мөселманнарыннан), Мәһди Мәгъкули (казакъ халкыннан), Мөсәҗәлетдин Хәлил (Кырымнан) юлга чыгалар һәм нәкъ 1 айдан Мәккә шәһәренә барып җитәләр.

Конгрессның эше һәм анда безнең делегатларның эшлекле катнашулары хакында «Ислам» журналының 1926 елдагы 8 (20) санында җентекләп язылган. СССРдан барган вәкилләр барысы да Конгрессның эшендә, аерым алганда, төрле комиссияләргә сайланып, актив катнашканнар. Кәшшафетдин Тәрҗемани җитәкчелегендәге өченче комиссия Конгресста каралган иллегә якын мәсьәлә буенча резолюция проектларын әзерли, шуларның күпчелеге гомуми мәҗлестә кабул ителә. «Кон-

грессның әһәмияте дини берләшүгә нигез салуындадыр», – дип аңлата соңыннан хәзрәт.

Мәккәдән кайткач, Диния нәзарәтендә СССРның бөтен өлкәләреннән килгән вәкилләрнең җыелышы үткәрелә. Анда мәркәз Диния нәзарәтенә яшерен сайлаулар үткәрелә. Кәшшафетдин хәзрәт үзенең фидакяр хезмәте белән мөселманнар арасында шундый зур хөрмәт казана ки, сайлауларда мөфти Риза Фәхреддингә караганда да күбрәк тавыш җыя. (Р. Фәхреддингә 350 ак, 36 кара (шар), Кәшшаф Тәрҗеманигә – 368 ак, 21 кара (шар).

1936 елның 12 апрелендә Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин вафат булганнан соң, мөфтилек вазифасы тулысынча Кәшшафетдин Тәрҗеманига күчә. Тик 1936 елның июлендә, кайбер мәгълүматларга караганда – 1938 елның 17 октябрендә, Кәшшафетдин хәзрәт Тәрҗемани кулга алына. Истәлекләргә караганда, ул төрмәдә дә, лагерьда да тоткыннарның хөрмәтен казанган, аны олылылап, хөрмәт иткәннәр. Гаделсезлектән арыган йөрәге тибүдән туктагач, тоткыннар аның җәсәден үзләре күтәреп, тәкъбир әйтеп каберенә мөселманча куялар. Бу хәл ГУЛАГ тарихында бердәнбер, диләр.

Халкыбызның гадел көрәшчесе, дин белгече, галим хәзрәтнең гомере шулай киселә. Сүзебез аның рухына дога булып барсын.

### Әдәбият һәм чыганаклар


1. Медресе Казани XIX – начало XX вв. Казань: «Гасыр», 2007.
2. Мәрҗани. Казан: «Мәгариф матбагасы», 1915.
3. ТР МА. Ф.92. Тасв. 2. Эш 7084.

*Хәмидә Гарипова*

## АНЫҢ ЯЗМЫШЫ – ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ

***Мәшһүр якташым, танылган җырчы, ТАССРның халык артисткасы Галия Кайбицкаяның Кайбыч район үзәгендә күркәм музее эшләп килә. Анда бүген дә төрле тәрбияви-мәдәни чаралар уза. Халкыбыз хәтереннән мәңге җуелмас сандугачыбызның нәсел тамырлары сакланган төбәгендә аны онытмыйлар. Туган тел язмышы кыл өстендә торган, затлы сәхнәбезне арзанлы чүп-чар басып алырга омтылган, шул рәвешчә тамашачының зәвыгын бозу куркынычын тудырган бүгенге көндә, республикабызның мәдәни тормышында зур эз калдырган Галия апабызны искә алу урынлы булыр.***

### *Олы йөрәк – кече күңел*

Татар халык җырчысы Галия Кайбицкая – күренекле якташым, якын күргән кешем ул минем. Аның әтисе Мотыйгулла хәзрәт – Кече Кайбычта туып үскән, Каһирәдә белем алган, «Мотыйгыя» мәдрәсәсен оештырып, анда мөдәррислек һәм мөгаллимлек иткән, ятим Апушны үз канаты астына сыендырып, аңа тирән белем, күркәм тәрбия биреп, талантын ачып, татар халкының күренекле шагыйре Тукай дәрәҗәсенә күтәрелергә ярдәм иткән мөхтәрәм шәхес. Әтисенең туган җиренә хөрмәт йөзеннән, Галия апабыз яшь чагында ук Кайбицкая тәхәллүсен алган.

Миңа Галия апа үзе исән чагында аның белән якыннан аралашу бәхете елмайды. Кайчандыр Салих Сәйдәшевтән калган җыйнак кына фатирында яшәде ул, кайбычлыларга ишекләре һәрвакыт ачык булды. Нурлы карашлы, якты йөзле, нәфис гәүдәле, юмарт, гади, олы йөрәкле, кече күңелле ханым иде. Үзен беркайчан да зурга куймады, башкаларга игелекле булуы белән аерылып торды. Җаекта Мотыйгулла хәзрәт өенә кунакка кергән шәкерт, Тукайның, нәни Галиянең бишегенә иелеп, шаккатып: «Сөбханалла, машалла! Күрегезче, еламый бит бу нарасый, җырлап ята. Мөгаен җырчы булыр», – дип юраганы юш килүе турында тәмләп сөйләве, «Апуш-Тукай булмас иде, Мотыйгулла булмаса», дип кабатлавы әлегәчә исемдә. Шәхси тормышында зур югалтулар кичерә, хаксызга рәнҗетелүләргә дучар ителә Галия апа. Коточкыч репрессияләре белән талантлы шәхесләр күңеленә яра салган шомлы еллар шаукымы аны да читләтеп узмый. Иҗат чишмәләре ургып агуга, опера һәм драма театрлары сәхнәләрендәге тырыш хезмәте белән милли сәнгать диңгезендә юл ярып баруына, халык сөеклесе, бик популяр һәм гаять талантлы актриса булуына карамастан, Татарстан обкомында зур кәнәфи биләгән

бер хөсетле татар түрәсе, Галиянең мулла кызы булуын сәбәп итеп, аңа «СССРның халык артисткасы» исемен бирдертми. Җырчының олы улы, татар милли архитектурасына нигез салучы, архитектура фәннәре докторы, РААСН мөхбир-әгъзасы, профессор Сәяр ага Ситдыйков, Галия апаның Кайбычтагы музеендагы бер очрашу вакытында: «Әни үзенең халыкны рухландыручы, аның күңелен сугаручы, җәмгыятькә кирәкле һөнәр иясе булуын аңлап иҗат итте. Бу аңа чиксез авырлыкларга бирешмәскә көч бирде. Дин әһеле кызы булуы аркасында, совет заманы түрәләренең әнине мораль яктан изүен, каныгуын, көнчелек белән «тәгәрмәчкә таяк тыгу»ын, нахакка күз яшьләре түктерүен хәтерлим. Авызы тулы кан булса да, чит-ятлар алдында түкермәде ул. Күз яшьләрен йотып, сәхнәгә шат елмаеп, көр күңел белән чыгарга үзендә көч тапты. Газаплы сугыш чорында, халкыбыз ачлы-туклы михнәт чиккән елларда әни тамашачыга рухи ныклык бирергә омтылды. Тарих барысын да үз урынына куйды: әнигә тәтемәгән шәхси бәхетне безгә – балаларына татырга насыйп булды», – дип сөйләгән иде. Эчендә ачы хәсрәт уты кайнаганда да, Галия апабыз үз иҗатының халыкка кирәк булуын, аның рухын сугаруын тирәнтен аңлап, җаны-тәне белән бирелеп хезмәт куйган шәхес.

***Беренче адымнар***

1923 елда Галия Төхфәтуллина апасы Әминә, абыйсы Әдһәм белән Җаектан Казанга килә. Калага аяк басуга, Тукай каберенә барып, үз туганнарыдай якын күргән шагыйрьнең рухына дога кылалар. Туташлар Татар театр техникумына укырга керә. Галия студент чагында ук драма театрындагы музыкаль спектакльләрдә катнаша башлый.

Тирән белемгә омтылган сәләтле кыз бераздан Көнчыгыш музыка техникумына кабул ителә. Данлыклы композитор Сәйдәш Галиягә җыр дәресләре бирә. Яңарак кына аякка басып килүче татар театры җитәкчесе, режиссер Кәрим Тинчурин өметле яшь туташка Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» спектаклендәге төп рольне ышанып тапшыра. Галиянең ихлас уйнавын ошатып, театрга эшкә чакыра. Тәүге адымнарын атлаучы музыкаль театр сәнгатенең күренекле эшлекләләре: драматурглар – Кәрим Тинчурин, Мирхәйдәр Фәйзи, композиторлар – Салих Сәйдәш, Солтан Габәши, актерлар – Хәлил Әбҗәлилов, Фатыйма Ильская, Гөлсем Болгарскаялар белән бер казанда кайнау Галиянең иҗади үсешенә, киләчәктә халык күңелендә тирән эз калдырачак милли җанлы актриса, көчле рухлы шәхес булып формалашуына уңай йогынты ясый. Ул үзенең моңлы йомшак тавышы, көләч йөзе, җылы мөгамәләсе, нәзакәтлелеге, тәрбиялелеге, чибәрлеге, тирән хисләрне сизгер йөрәге аша үткәреп, тамашачы хозурына тапшырып, аларның күңелен кузгата алуы белән аерылып тора. Музыкаль драмалардагы җырлы-моңлы, кайчакта

дәртле-шаян, кайвакытта гамьле-моңсу образларны үзенә генә хас ягымлылык, эчкерсез җылылык белән җиренә җиткереп башкарып, халык арасында таныла ул. Фәйзинең «Асылъяр»ында – Ләлә, Тинчуринның «Казан сөлгесе»ндә – Мөршидә, «Зәңгәр шәл»дә – Мәйсәрә, «Кандыр буе»нда – Гөләндәм, «Сүнгән йолдызлар»да – Сәрвәр... Тырыш хезмәт җимешләре озак көттерми, актрисада рольдән рольгә үсеш күзәтелә. Мәдәни җәмәгатьчелек актив иҗат итүче актрисаның хезмәтен уңай бәяли. Ф. Бурнашның «Таһир белән Зөһрә» спектаклендә Галиянең уенын күргән Һади Такташ, «Кызыл Татарстан» гәҗитендә: «Татар сәхнәсендә тагын бер йолдыз кабынды», – дип язып чыга. Музыкаль драмаларның бизәген генә түгел, үзәген тәшкил иткән көйләренең күбесен Сәйдәш Галия тавышын күздә тотып иҗат иткәнлеге билгеле.

***Опера сәхнәсендә балку***

1940-еллар башында милли җанлы татар зыялылары үзебезнең опера театрын оештыру идеясе белән яна. Татарстан Өлкә комитеты җитәкчелеге әлеге идеяне күтәреп ала һәм күркәм башлангычны гамәлгә ашыру мөмкинлеген тудыра. Һөнәри белемле милли кадрлар әзерләү зарурияте көн кадагына баса. 1934 елда Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясе каршында Хәмит Төхвәтуллин (Галия апаның абыйсы) җитәкчелегендә ачылган беренче татар опера студиясенә бер төркем талантлы яшьләр: Ситдыйк Айдаров, Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Мәрьям Рахманкулова, Мөнирә Булатова, Усман Әлмиев, Сара Садыйкова, Нияз Даутов, Фәхри Насретдинов, Асия Измайлова, Зөһрә Байрашова, Галия Кайбицкая сайлап алына. Бер дигән вокал мөмкинлекләренә һәм актерлык сәләтенә ия, Татар драма театры сәхнәсендә тугыз ел дәвамында җырлы рольләр башкарып шомарган Галия студентлар арасында кыйммәтле йөзек кашыдай балкый. Консерваториядә уку аның дөньяга карашын үзгәртә, фикерләү дәрәҗәсен яңа баскычка күтәрә, күңел офыкларын киңәйтә, вокал мөмкинлекләрен камилләштерә. 1939 елда, укуын уңышлы тәмамлап, труппа составында ул Казанга кайта.

Опера театры сәхнәсенә тәүге аяк басуына карамастан, Галия югалып калмый. Милли опера сәнгатенең үз традицияләрен булдыруда армый-талмый, илһамланып эшли. Озак та үтми, яңа ачылган милли опера театрының әйдәп баручы солисткасына әверелә. 1940–50 елларда куелган барлык татар операларында, музыкаль комедияләрдә диярлек төп рольләрне Галия башкара. «Түләк»тә – Сусылу, «Башмагым»да – Сәрвәр, «Качкын»да – Рәйханә, «Наемщик»та – Гөлйөзем һ.б. 1939–1941 елларда Опера театрында биредә әдәби бүлек мөдире булып эшләгән шагыйрь Муса Җәлилнең «Алтынчәч» (композиторы – Нәҗип Җиһанов) операсында төп партияне җиренә җиткереп башкаруы Кайбицкаяга алкышлар

һәм дан китерә. Рус һәм чит ил операларында катлаулы партияләрне аңа ышанып тапшырулары очраклы хәл түгел. «Риголетто»да – Джильда, «Травиата»да – Виолетта, «Фауст»та – Маргарита, «Патша кәләше»ндә – Марфа, «Кар кызы»нда – Кар кызы рольләренең сәхнәдә югары зәвык белән гәүдәләнеше аның көчле талантын чагылдыра. Сирәк очрый торган яңгыравыклы, бизәкле мелизмнарга бай, ягымлы тембрлы табигый тавышы (колоратур сопрано), эзләнүчәнлеге, тырышлыгы, үҗәтлеге Кайбицкаяга башкару осталыгы биеклекләрен яуларга, сәнгать сөючеләр арасында киң танылырга ярдәм итә. Галия гүя сәхнәдә уйнамый, ә яши: һәр сүзен, хәрәкәтен ихлас, тормышчан, җанлы итеп гәүдәләндерә.

### *Окоптан-окопка җыр агыла*

Мәскәүдә Татар сәнгате декадасы уздыру максаты белән рухланып иҗат иткән сәнгатькярләрнең нияте барып чыкмый, чөнки Бөек Ватан сугышы башлана. Күп кенә сәнгать әһелләрен утлы мәхшәр үз эченә йотып ала. Төньяк-көнбатыш фронтта дошманнарны аяусыз кыручы Татар дивизиясенең оешуына 1943 елда 25 ел тула. Республика җитәкчелеге юбилярны ТАССР халкы исеменнән фронтка барып котлау өчен, сәнгатькярләрдән бер төркем туплый. Делегация составында Галия Кайбицкая да була. Баш очыннан фашист пулялары сызгырып очкан, янәшәдә туплар шартлап ярылган, артында пулеметлар аткан шартларда, көн саен берничә мәртәбә Газраил белән күзгә-күз карашкан хәлдә, Галия апалар бригадасы ай ярым дәвамында ротадан-ротага, окоптан-окопка күчә-күчә, татар-башкорт һәм башка милләт вәкилләреннән торган Татар дивизиясе солдатларының хәрби рухын күтәрү максатыннан, концертлар куеп йөри. Бер күчеш вакытында аларны артиллерия утына тоталар, артистлар утырган атлы арбаны шартлау дулкына күтәреп ата. Галия апа җиңелчә контузия ала, ярый әле чукрак булып калмый.

Галия апабыз «Почет билгесе», «Хезмәт Кызыл байрагы» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә, ТАССРның халык артисткасы исеменә лаек була. Бу дәүләт бүләкләрендә утлы фронт юлларының да өлеше бар.

### *Хәтердән җуелмас сандугач*

Халкыбызның моңлы сандугачы Галия Кайбицкаяның арабыздан китүенә чирек гасырдан артык вакыт узса да, талантлы җырчының нурлы образы халык хәтереннән җуелмады. Кайбычта, Казанда аның исемендәге урамнар бар. 1998 елда Олы Кайбычта ачылган музеенда Галия апаның үзе язган шигырьләре, хатлары, фотолары, афишалары, буклетлары, ноталар дәфтәре, пианиносы, сәхнә күлмәге, китап һәм кием шкафы, радиосы, пирчәткәләре, бизәнү әйберләре, өстәл япмасы; этисенең чалмасы, тәсбихе, китаплары; Каһирәнең «Әл-Әзһәр» дини академиясендә

белем алган Мотыйгулла хәзрәт һәм аның улы Камилнең Мәккәгә хаҗ кылуы истәлеге – изге шәмаил һ. б. ядкярләр кадерләп саклана. Галия апаның мемуарлары кызыклы, аңа багышлап язылган мәкаләләр бихисап. М. Җәлил, С. Хәким, М. Хөсәен, Г. Кутуй һ.б. шагыйрьләр аның талантын зурлап, шигырьләр иҗат иткән. С. Вәлиди «Кайбыч кызы Галия» җырын язды. Язучы-галим Ф. Галимуллин моңлы сандугачның гыйбрәтле тормыш юлын «Талантлар йолдызлыгында» документаль повестенда яктыртты. *(Бу мәкаләмне әзерләгәндә әлеге истәлекләр белән танышып чыктым, кайбер фактик материалларны язмамда файдаландым, авторларына ихлас күңелдән рәхмәтлемен. – Х.Г.)*

КФУның Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институты профессоры, ТРның халык, РФнең атказанган артисткасы, якташыбыз Лидия Әхмәтова инициативасы, Кайбыч районы хакимияте башлыгы Альберт Рәхмәтуллин ярдәме, КФУ җитәкчелеге хәерхаһлыгы белән 2013 елда Галия Кайбицкая исемендәге Халыкара вокал бәйгесе гамәлгә куелды. Бу җыр бәйгесендә ТРның, РФнең берничә төбәгенең башлангыч, урта һәм югары музыка уку йортларында белем алучы сәләтле үсмерләр һәм яшьләрдән тыш, Әрмәнстан,Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Гөрҗестан, Кытай, Ямайка, Мексика, Индонезия, Малайзия гражданнарының да катнашуы чарага күркәм бизәк өстәде.

*P.S. 1996 елда, данлыклы якташымның балалары, дуслары, киң җәмәгатьчелек белән бергәләп, аның 90 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә, Галия апага багышлап «Былбыл» поэмасын иҗат иткән һәм аны Кайбыч районы Мәдәният йортында булып узган юбилей кичәсендә сөйләгән идем. Галия апаның олы улы Сәйяр ага Ситдыйков иҗат җимешемне сорап алды. Аны Казанда зур панно рәвешендә ясатып, әнисенең 1998 елда Кайбычта ачылган музеена бүләк итте. Хәзер ул музей фондында экспонат булып саклана.*

## Татар рухы

## Татарский дух

*Д.В. Мухетдинов*

# «ТАТАРЫ В КОНТЕКСТЕ ИСТОРИИ МУСУЛЬМАНСКОГО МИРА: ОСНОВНЫЕ ЭТАПЫ»[1]

1. История татар, безусловно, является полноценной частью истории России. Однако вовсе не какой-то локальной частью, которую следовало было изучать на специализированных факультетах в рамках курса «История регионов и народов России». В определенный хронологический отрезок – это именно этап для истории всей страны. Речь идет, естественно, об эпохе Золотой Орды, которую, как я глубоко убежден, необходимо (несмотря на сопротивление некоторых русоцентрично настроенных представителей отечественной интеллигенции и даже в том числе научной общественности), рассматривать как ключевую эпоху для формирования полиэтнического государства, из которого в будущем выросло то, что сегодня мы именуем «Российской Федерацией».

2. У меня нет ни задач ни времени углубляться в дискуссии об этнической истории татар, имеющей сложности как методологические (понимание разными этнологическими школами «этногенеза и этнической истории» вообще), так и далекие от науки, которые можно назвать «идеологическими» (споры так называемых «булгаристов» и «татаристов»). История татар, подчеркну, «народа татар», который представлен сегодня в составе населения РФ, а не этнонима *татар*, который в различные периоды носили разные исторические сообщества, начинается именно с XIII в. и именно с Поволжья – Золотой Орды. Здесь оформилась государственность татар, сформировалась этническая и религиозная идентичности, сложился тот тюркский язык, который мы сегодня именуем «татарским». Естественно, ни один народ не появляется из ниоткуда и не является «чистым». Конечно, и в сложении татар приняли участие многие группы населения, местного и пришлого, и прибывавшего позже XIII в. Идентичность и язык объединили их.

[1] Тезисы выступления на Всероссийском симпозиуме на тему «Исторические предпосылки и основные этапы вхождения татар в орбиту исламской цивилизации» (Пенза, 19 марта 2022 г.).

3. История татар, таким образом, с самого своего начала связана с исламом. Естественно монгольские армии, руководимые внуком Чингисхана Бату, когда завоевали Волжскую Булгарию, встретили здесь развитую мусульманскую культуру. Мы не можем ничего уверенно сказать о том, насколько широко ислам был распространен и как глубоко укоренен в сознании разнородного населения Волжской Булгарии, не можем категорично судить о количестве мечетей, медресе, о степени развитости мусульманской книжности здесь, даже учитывая допустимые масштабы военных разрушений и гибели в ходе их строений и книг. Письменных источников почти нет, а археологические свидетельства часто слишком сильно зависят от субъективных воззрений исследователей. Однако, тот факт, что Волжская Булгария (хотелось бы подчеркнуть, первое мусульманское государство в Европе) была неотъемлемой и совсем не изолированной частью Мусульманского мира, не подвергается никакому сомнению. Впрочем, учитывая стремительную экспансию Владимиро-Суздальского княжества на восток уже с конца XII в. и его довольно частые конфликты с Волжской Булгарией в первой четверти XIII в., можно вполне скептически отнестись к мысли, что этот самый северный форпост Мусульманского мира смог бы сохранить свое положение в дальнейшем. И сюда пришли монголы (точнее – армия из монголоязычных и тюркоязычных племен во главе с монгольской – в языковом и политическом значении – династией), которые, как и все кочевники, характеризовались не столько толерантностью, сколько прагматичным безразличием к этнополитической и религиозной принадлежности своих подданных.

4. Естественно, Поволжье стало важным плацдармом для развития исламских традиций в составе новой политической системы. Традиционные связи Поволжья со Средней Азией (это, в частности, Хорезм, начиная с Саманидов), не прерывались и когда Золотая Орда была еще составной частью Монгольской империи, и в последующем, после ее распада.

Вряд ли сто́ит перечислять ставшие уже хрестоматийными факты о золотоордынских правителях-мусульманах (начиная с Берке), их контактах с мусульманскими государствами, присутствии при их дворах мусульманских деятелей (большинству присутствующих об этом известно и, вероятно, как специалисты-историки, они знают об этом больше). Отметим, что обращение в ислам – сначала представителей правящей династии, а затем и той части населения, которая ранее не было ему подвержена – было вполне объяснимым и даже исторически закономерным, учитывая усилия самих ханов (по крайней мере, в таком образе предстает в источниках хан Узбек). Политические образования того типа, которые иногда в научной литературе определяют как «кочевые империи»,

в большинстве своем рано или поздно подступали к историческому моменту, когда их правящая элита приходила к решению официально принимать какую-либо влиятельную канонизированную религию. Особенно это было характерно для таких политических образований, где кочевая элита представляла собой завоевателей, установивших власть над оседло-земледельческим населением. Чаще это было следствием естественного внутреннего развития, когда интересы правящей династии гораздо больше сближались с экономически более сильным и интеллектуально прогрессивным оседло-земледельческим населением. И это, как заметил еще академик В.В. Бартольд, часто приводило к конфликту династии с консервативно настроенной частью кочевой элиты, своего рода «поборниками традиций». Если сторонники династии побеждали, развитие государства закономерно становилось на новые рельсы исторического развития, если нет – в большинстве случаев и участь династии, и самого государства была роковой. Золотая Орда смогла пойти по первому пути. Это сделал хан Узбек, видимо, не столько полыхавший одержимостью исламом, сколько избавляясь от влиятельной, но консервативной элиты кочевых племен.

Этот политический проект по отрицанию истории татар также следует рассматривать с точки зрения евразийского проекта, за которым внимательно следил новый царь в Москве. Политические цели тех, кто выдвигает концепцию Евразии, ясно видны, если мы просто взглянем на ее очертания, которые, по сути, касаются преемственности великих евразийских государств в северном полушарии, у которых была заявленная миссия объединения цивилизаций, принадлежащих двум континентам. Сторонники проекта нацелены, в частности, на три великих евразийских государства: Древнетюркский каганат (VI–IX вв.), Золотую Орду (1242–1502 гг.) и Российскую империю (включая и Советский Союз). Поскольку первые два уже давно исчезли, по мнению сторонников проекта, евразийское наследие переходит к тому, кто еще существует, а именно, к России. Такая линия рассуждений кажется простой; но на практике она

проводится очень тонко, и упорно. Сторонники российской концепции евразийства даже заходят так далеко, что сознательно преувеличивают взаимные обмены между монгольскими кочевниками и оседлыми русскими на протяжении всего средневековья. В то же время, культивируя враждебное отношение к татарам, они продолжают проявлять тенденцию рассматривать Россию как реинкарнацию монгольской (не татарской!) империи – позиции, постоянно проявляющейся в националистической российской историографии. Естественно, такое обращение к общей исторической традиции и общности благоприятно для сближения как народов, так и государств, и в настоящее время, и в будущем, потенциально даже с конечной целью восстановления в целом более всеобъемлющей евразийской государственной структуры. В этом заключается объяснение политики России по разжиганию националистического эгоизма в новых независимых тюркоязычных государствах, которые готовы конфисковать, изолировать или полностью уничтожить татарскую историю.

Другой том о Золотой Орде, появившийся недавно (точнее, в августе 2021 г.) в Нью-Йорке, представляет собой сборник исследований, которые, как мы полагаем, направлены на поддержку идей, изложенных в книге г-жи Фаверо, обсуждавшейся выше. Главный инициатор и главный редактор этого тома, профессор Санкт-Петербургского университета А.В. Майоров, хорошо известен как представитель нового поколения российских историков-националистов. Эти ученые взяли аргументы предыдущих российских историографов – особенно в том, что касается отношений русских с татарами[1] – и адаптировали их к новым геополитическим условиям нашего времени. Профессор Игорь Фроянов (1936–2020) из Санкт-Петербургского университета сформировал новую националистическую русскую школу, которая становится все более агрессивной, в том числе и, особенно, на международной арене. Одним из самых выдающихся учеников этой школы является сам Александр Васильевич Майоров. Основной целью этих историков является пропаганда позитивной роли русских в истории и пропаганда имперской славы Великой России, что, с одной стороны, означало поддержку апологии внутренних успехов и прославление военных побед, а с другой – отрицание или, по крайней мере, минимизацию внешних неудач и иностранного вклада. В этом контексте русско-татарские отношения в Средние века представляют собой

[1] В начале XX в. профессор В.О. Ключевский, один из ведущих представителей этой националистической школы, учил своих студентов, что «борьба против степных кочевников, половцев и жестоких татар, которая продолжалась с VIII в. почти до конца XVII-го, представляет собой самую скорбную память русского народа» (В.О. Ключевский. Курс русской истории. Вып. I. 1918. С. 73). См. также: C.J. Halperin. Kliuchevski and the ‘Tatar Yoke’ // Canadian-American Slavic Studies, 34/4, 2000. PP. 385–408.

одну из наиболее чувствительных и важных областей изучения и путей проявления. Первоначальная цель вышеупомянутого сборника статей состояла именно в том, чтобы свести на «нет» или, по крайней мере, принизить роль татар в евразийской истории в целом, и в российской истории, в частности. В то время, как старая националистическая российская историография последовательно выдвигала самые серьезные обвинения против татар в рамках так называемого «татарского ига», историки новой националистической школы раскрыли еще более хитрый способ нападения на татар через преднамеренное умолчание их имени путем постоянного упоминания монголов при обсуждении вопросов, связанных с историей Золотой Орды и ее отношением к русским княжествам. По сути, националистическая российская историография уже давно стремится полностью вычеркнуть татарский период из российской истории. Поскольку это оказалось невозможным, мы столкнулись с новой попыткой заменить термин «татар» термином «монгол».

Этот коварный план возник в то время, когда западная историография запустила обширный проект по переосмыслению вклада Азии в историю и цивилизацию человечества. В этом контексте ряд ролей, сыгранных историческими факторами, которые до настоящего времени либо игнорировались, либо сводились к минимуму, также начали переоцениваться. Империя Чингизидов в целом и Золотая Орда, в частности, привлекли большую часть внимания академической среды, поскольку их образ уже был преднамеренно искажен на протяжении веков. Поэтому было оправдано тщательное изучение истории этих государств, попытка продемонстрировать их вклад в прогресс человечества. Однако этот научный проект также может оказаться полезным для имперских амбиций, от которых русские никогда не отказывались. Мы считаем, что схемы этого обмана, планируемого сегодня [представителями] националистической российской историографии, основаны на концепции о том, что «Слава предков полезна для их потомков». Другими словами, лидеры стремящейся к империализму России также объявляют себя потомками Золотой Орды, то есть императоров из знаменитой династии Чингизидов в рамках тщеславной самопрезентации как сыгравшие роль в развитие человечества через Великое Монгольское государство, что требует постоянного усиления его монгольского характера со стороны российских историков. Монголы сегодня не тюрки и не мусульмане, и у них нет имперских притязаний; напротив, они могут чувствовать себя польщенными своей (по общему признанию, вынужденной) связью с великим царем в Москве. В этой логике в такой конструкции самим татарам нет места; напротив, они представляют собой неприятный элемент, который необходимо

устранить. Для того, чтобы эта фальсификация истории когда-либо была успешной, соучастие некоторых известных специалистов из-за рубежа, особенно с Запада, конечно, очень важно и желательно.

Поэтому не случайно, что недавно опубликованный том не содержит вклада ни одного историка татарского происхождения, даже из числа тех ученых в Казани, которые приобрели большую известность благодаря своим тщательным исследованиям истории Золотой Орды и татарских ханств, особенно за последние десятилетия. К тому же к этому изданию не присоединились честные и авторитетные российские историки нового поколения, такие как, например, Вадим Винцерович Трепавлов из Москвы, известный специалист по истории Золотой Орды. Американского ученого Чарльза Дж. Гальперина, который на протяжении многих лет проводил обширные исследования по истории реальных отношений между Золотой Ордой и русскими княжествами, точно так же нельзя найти среди авторов книги, как и профессора Марии Иванич из Венгрии, известного специалиста по истории татар. Известный американский специалист по истории и культуре Центральной Азии в целом, и кыпчаков, в частности, профессор Питер Голден, даже не появляется в Указателе тома. Более того, мы не можем найти ни одного румынского специализированного исследователя среди авторов, фигурирующих в томе, хотя во введении редакторы книги подчеркивают тот факт, что «дунайские монголы оказали значительное влияние на территорию современной Румынии и Молдовы. Период монгольского господства в Юго-Восточной Европе имел непосредственное значение для политической консолидации влахов (будущих румын) и постепенного возникновения их независимых государств»[1]. Похоже, что редакторы решили не приглашать авторов, которые, возможно, не служили политическим интересам, преследуемым книгой. К сожалению, эта книга сумела привлечь внимание нескольких других иностранных историков с безупречной научной проницательностью. Однако, по крайней мере, некоторые из них, похоже, осознали ловушку, в которую они попали, и попытались возместить хотя бы часть ущерба. Например, венгерский историк Иштван Вашари почти исключительно ссылается на татарский язык во всей своей публикации[2], в то время как профессор Александр Николов из Софийского университета подчеркнул тот факт, что «Золотая Орда, где завоеванные куманы-кыпчаки были важной частью населения и, возможно, проникли в элиту, медленно начала формироваться как «татарское» государство, где татары, несмотря

[1] Alexander V. Maiorov and Roman Hautala (eds.). The Routledge Handbook of the Mongols and Central-Eastern Europe. London and New York, 2021. P. 5.

[2] Ibid. PP. 161–174.

на монгольские корни элиты, становилась все более тюркоязычной общиной и постепенно приняла ислам»[1].

Более того, Александар Узелац, научный исследователь из Белграда, также убежден, что, начиная со второй половины XIII в., Золотая Орда стала тюркским и мусульманским, то есть, татарским государством. В своем вкладе в книгу, подробно описывающем отношения между Золотой Ордой и болгарскими государствами между 1241 и 1341 гг., Ал. Узелац прямо называет Золотую Орду «татарским государством». Он также разделяет мнение арабского ученого аль-Омари (1300–1349), который назвал Золотую Орду «Кыпчакским султанатом» (с. 223). После поражения Секлера и убийства Атламыша, татарского лидера региона Нижнего Дуная, сочетание внутренних и внешних факторов «привело к сокращению татарского населения в регионе и сокращению их земель». Ал. Узелац приходит к выводу, что к концу XIV в. западные татары, населявшие Добруджу и регион, позже известный как Буджак, отделились от татар к востоку от реки Днепр и боролись за сохранение своей независимости[2]. Татарские государства также являются темой вклада Максима Моисеева в коллективный том, выделенного как таковой по самому названию исследования. Российский историк даже подчеркивает тюркский характер отколовшихся татарских государств, пришедших на смену Золотой Орде, называя их «тюрко-татарскими государствами» (с. 267) и тем самым косвенно признавая тюркский характер самой Золотой Орды. Татары также являются предметом выбора для Владислава Гулевича, украинского исследователя, чей вклад анализирует отношения между Золотой Ордой, Литвой и Польшей в XIV–XV вв.

Другие авторы книги (Витольд Святославский, Стивен Поу, Томаш Сомер, Михал Голешк) приводят аргументы, направленные на то, чтобы дать существенно иной взгляд на клише, которые давно и настойчи-

---

[1] Ibid. PP. 202. На той же странице автор также упоминает «нового хана “татарской” Золотой Орды Мунгке Темура (р. 1266–80)». Далее в своем вкладе профессор А. Николов пишет исключительно о татарах – поскольку, как мы показали выше, мы можем говорить только о монгольском руководстве Золотой Ордой до правления мусульманского хана Берке (1257–1266): «После смерти Ногая Токта-хану удалось объединить все татарские группировки под его властью» (стр. 204); «[...] татары Золотой Орды».

[2] Alexander V. Maiorov and Roman Hautala (eds.). The Routledge Handbook of the Mongols and Central-Eastern Europe. 2021. P. 224. К сожалению, румынские историки, исследующие и изучающие татарское присутствие в регионе в то время, неизменно продолжают говорить о монголах, монгольской гегемонии и т.д. Мы считаем, что изменение точки зрения в отношении такой исторической терминологии оправдано. Болгарская историография недавно признала важную роль татар в защите и продолжении существования болгарских государств XIII–XIV вв. Еще до болгар поляки также предприняли аналогичные жесты, дойдя до того, что установили конный памятник близ Гданьска в память о татарах, проливших свою кровь в защиту Польского государства. До сих пор румынская историография предприняла лишь несколько робких шагов в этом направлении.

во распространялись средневековыми европейскими хронистами, когда речь шла о массовых убийствах, совершенных монгольскими армиями по всей Европе. При более тщательном анализе выясняется, что эти изображения, намеренно представленные в апокалиптическом масштабе, на самом деле были обычным явлением во времена насилия, подобного этому, включая инциденты, происходящие между христианскими армиями. Более того, вышеупомянутые историки утверждают, что некоторые из зверств, в которых обвиняют монголов, на самом деле были совершены королевскими армиями Европы. На самом деле монголы составляли не более трети всех армий Чингизидов, которые атаковали Европу между 1236 и 1242 гг., а затем в XIII в. Подавляющее большинство (более двух третей) тех, кто сражался под знаменами монголов, были немонгольского происхождения, в первую очередь, кыпчаками и другими народами тюркского, славянского, иранского или кавказского происхождения, включая мусульман и христиан. Здесь, опять же, утверждается, что монголы сделали больше, чем они исторически действительно, совершили.

Националистически настроенные российские историки намеренно исходят из фундаментально ошибочной предпосылки, неприемлемой для любого истинного и уважающего себя ученого. По мнению таких историков, вся конструкция средневековой русской истории основана на противостоянии «русской нации/народа» и «татарского ига», с упором на истории независимой России в этой временной шкале, начинающейся в 1380 г., когда войска великого русского князя Дмитрия Ивановича решительно победили татарского полководца (беклерибека) Мамая на Куликовом поле, близ р. Дон. По этой причине эта конкретная битва была преувеличена русскими историками до эпических масштабов, в то время как князь Дмитрий Иванович был освящен Русской Церковью как святой Дмитрий Донской. Куликово поле действительно ознаменовало первую русскую победу над татарами; однако, на самом деле, это столкновение было незначительной стычкой для Золотой Орды, которая вскоре исправила свое поражение. Вскоре после этого, в августе 1382 г., войска Золотой Орды во главе с Токтамыш-ханом (1375–1397), были у ворот Москвы. Святой Дмитрий Донской бежал в Кострому, в то время как оставшиеся москвичи и бояре, похоже, не слишком стремились защищать свой город. Таким образом, татарская армия беспрепятственно вошла в Москву – и русские летописцы того времени отметили эти события весьма четко: «О взятии Москвы царем Тохтамышем и о покорении России»; «Рассказ о нисхождении Тохтамыша на Москву»; «Рассказы о взятии крепости Моск императором Тохтамышем и о порабощении Рязанской земли»[1].

[1] Apud B.D. Grecov and A.I. Iacubovschi. Hoarda de Aur și decăderea ei. Bucharest, 1953. P. 305.

В обстоятельствах 1382 г. русский князь Дмитрий Донской умолял о пощаде татарского хана и отправил своего старшего сына заложником ко двору Токтамыша в знак покорности данника. Эти реальные исторические события признаются даже западными историками, симпатизирующими по взглядам националистической российской историографии[1]. Однако, если это так, что тогда можно сказать о фундаментальном значении «легендарной победы» на Куликовом поле в сентябре 1380 г. для независимости России? Националистически настроенные российские историки не отказались от таких извращенных идей и по сей день, в том числе и некоторые авторы, внесшие свой вклад в упомянутый выше сборник исследований, опубликованный в Нью-Йорке.

Однако, что мы находим еще более проблематичным, так это тот факт, что националистически настроенные российские историки сознательно нарушают священное правило любых научных исследований в области истории. Они охотно смешивают воедино реальные события, происходившие в разные периоды времени, и оценивают более древний период времени на основе норм и концепций, установленных только позднее. Вездесущая фраза о «татарском иге» впервые была произнесена Русской Церковью в XVI в.[2], однако российские историки без колебаний переносят ее на XIV в., чтобы оправдать свое восхваление Куликовской битвы и ее значения или прославления князя святого Дмитрия Ивановича Донского как созидателя русского народа, освобожденного из-под «татарского ига». Только на самом деле и Русская Церковь, и простые россияне связывают рождение национального Русского государства с постепенной эволюцией Московского княжества, которое обязано своим возвышением поддержке, которую оно получило от татар Золотой Орды. Без их политической и военной поддержки Московское княжество никогда не смогло бы выиграть ожесточенную борьбу за господство среди множества мелких российских государств. Под татарским владычеством Русская Церковь также пользовалась многими привилегиями и свободами, которые способствовали ее постоянному развитию и укреплению. В XIV в., когда Золотая Орда была фактической сверхдержавой, никто не осуждал «татарское иго», и меньше всего Русская Церковь. Более того, если мы воспользуемся методом «если история...», мы также отметим, что, по крайней мере, средневековая русская история имела бы совершенно иную эволюцию, безусловно, гораздо менее впечатляющую, если

1 Marie Favereau. The Horde. How the Mongols Changed the World, 2021. P. 282.

2 В том же XVI в., когда исчезла Золотая Орда (Улуг-Орда), Русской Церкви через своих монашеских летописцев того периода удалось распространить тенденциозный перевод «Златая Орда» (Золотая Орда), откуда уничижительный термин «орда» был заимствован во множестве языков, включая английский и румынский языки.

бы монголо-татары не уничтожили государственную структуру Киевской Руси в XIII в. Исчезновение русского государства в Киеве впоследствии принесло большую пользу развитию Московского княжества[1]. В истории любая цена будет заплачена, рано или поздно, тем или иным способом!

С самого начала, во введении к этому сборнику исследований, редакция объявляет его заявленной целью как переоценку роли «монгольского фактора в истории Восточной и Центрально-Восточной Европы» между XIII и XVI вв. На самом деле нельзя говорить о продолжающемся монгольском факторе – детали, не ускользнувшей от внимания авторов тома, но которую многие из них, к сожалению, предпочитают игнорировать. Из 25 тщательных исследований, включенных в этот том, только 4 работы содержат термин «татарский» в своих названиях. Однако, в отличие от автора рассмотренной выше предыдущей книги, Мари Фаверо, авторы настоящего сборника не смогли полностью игнорировать этот термин, поскольку существующие исторические записи не могут быть фальсифицированы. Следовательно, материалы содержат ссылки как на монголов, так и на татар, причем некоторые авторы, особенно те, которые затрагивают темы второй половины XIII в. или позже, чаще говорят – иногда исключительно – о татарах, чем о монголах.

Даже профессор А.В. Майоров, главный вдохновитель и редактор публикации тома, в своем собственном вкладе в сборник признает эквивалентность терминов «монгол» и «татарин» как в исторических русских источниках того периода, так и в их западных аналогах; однако, не уточняя, что эта путаница была применима только к в более раннему периоду[2]. Вместо этого основная идея тома состоит в том, чтобы подчеркнуть важный вклад «Монгольского государства, обычно называемого Золотой Ордой [...] [которое] полностью изменило сложившуюся политическую ситуацию в регионе», как утверждают сами редакторы в заключении введения к тому[3]. Более того, многочисленные изменения, происходившие в истории Центральной и Восточной Европы, имеют основополагающее значение для придания продолжающейся эволюции этой части европейского континента ее специфического характера. Редакторы с самого начала стремились подчеркнуть этот «монгольский» вклад в развитие центральноевропейской истории и цивилизации:

[1] См.: Donald Ostrowski. Muscovy and the Mongols: Cross-Cultural Influences on the Steppe Frontier, 1304-1589. Cambridge University Press, 1998. PP. 244–248; Marie Favereau. The Horde. How the Mongols Changed the World. 2021. PP. 271–2.

[2] Alexander V. Maiorov. Diplomacy, War and a Witch. Peace negotiations before the Mongol invasion of Rus. The Routledge Handbook of the Mongols and Central-Eastern Europe. London and New York, 2021. P. 36.

[3] Ibid., p. 12.

«С середины XIII в. всем странам и народам Восточной и Восточно-Центральной Европы приходилось считаться с мощным централизованным государством, обладающим огромным военным потенциалом. Некоторые страны, такие как Русь и Болгария, предпочли подчиниться монголам после нескольких военных поражений. Другие, такие как Польша и Венгрия, отстояли свою независимость, но не смогли избежать влияния монголов. [...] Могущество завоевателей способствовало массовым миграциям населения, подъему международной торговли, передаче знаний и технологий, изменению старых представлений о мире и его народах, формированию в целом более терпимого отношения к носителям других культур и религий. [...] За столетия противостояния с монголами на смену прежним пришли новые политические и экономические центры, сформировались новые государства и геополитические реалии, возникла новая политическая культура, основанная на абсолютизации и сакрализации верховной власти»[1].

Как мы видим, ни слова о глубоком и бесспорно татарском характере великого государства, которым была Золотая Орда. Старые источники как из Европы, так и с Востока, ясно свидетельствуют о «татарской», «тюркской» или «кыпчакской» природе этого государства, в то время как авторитетные российские и западные специалисты с большой известностью – как старшего, так и нового поколения – обозначают Золотую Орду как «Кыпчакское» ханство или султанат, начиная с середины XIII в. Мы ранее обсуждали этот вопрос, уже приведя, по нашему мнению, достаточно аргументов, чтобы избежать необходимости повторять дискуссию здесь[2]. Более того, даже некоторые из работ, опубликованных в обсуждаемом томе, сами признают эту историческую реальность.

В том же духе мы хотели бы обратить внимание на странное совпадение, которое вполне может раскрыть политический характер возобновившейся антитатарской кампании, которая теперь также укореняется в западной, прежде всего американской, научной среде. 19 апреля 2001 г. Конституционный суд Российской Федерации признал название Республики Татарстан неконституционным. Казанские татары провозгласили свою национальную независимость 30 августа 1990 г., став одним из первых народов, заявивших о своей свободе еще до распада Советского Союза. Республика Татарстан была провозглашена после референдума, проведенного 21 марта 1992 г., когда 61,4% жителей республики проголосовали за суверенитет Татарстана. Позже в том же году, 6 ноября 1992 г., татарский парламент в Казани утвердил Конституцию Республи-

[1] Ibid.

[2] См.: Tasin Gemil. Tătarii. Relații cu otomani și români. Cluj University Press, 2021. PP. 17–59.

ки Татарстан, которая недвусмысленно провозгласила суверенитет этого татарского государства.

Однако Кремль не решился немедленно привести в исполнение решение Конституционного суда в Москве от 2001 г. Мы хотели бы напомнить нашим читателям, что татары являются второй нацией в Российской Федерации, как по численности, так и по культурному престижу. Президент России Владимир Путин терпеливо ждал подходящего момента, который совсем не случайно совпал с новым «украинским кризисом». 21 декабря 2021 г. – то есть совсем недавно – Путин принял закон, который, по сути, упраздняет Республику Татарстан и который косвенно существенно влияет на национальный характер термина «татарин». Похоже это последний удар в методичном избиении, которому татары уже давно подвергаются от рук русских. 27 ноября 2002 г. татары были вынуждены отказаться от латинского алфавита, который они использовали с 1992 г., а 3 августа 2018 г. было введено обязательное преподавание на русском языке, а их родной татарский язык был переведен в статус предмета по выбору в школах по всей Республике Татарстан. Более того, в период с 1992 по 2017 г. Конституция Республики изменялась в общей сложности 17 раз, постепенно лишаясь своей сути как гаранта татарской нации, так и государства.

Более того, Кремль также возобновил свои насильственные попытки стереть следы татарской истории и культуры на другой древней татарской земле, находящейся под российским владычеством, – в Крыму. Помимо мер, направленных на предотвращение использования татарского языка и соблюдения обычаев предков крымскими татарами, по всему региону также систематически и методично реализуется программа, направленная на уничтожение татарского исторического и культурного наследия. Например, оригинальные татарские исторические памятники изменяются, а иногда и разрушаются в результате так называемых «реставрационных» инициатив, главной целью которых является древний Хансарайский дворец татарских ханов в Бахчисарае[1]. В то же время, инфраструктурные работы которые в настоящее время разворачиваются по всему Крыму, имеют дополнительное «преимущество» в том, что они намеренно уничтожают, или иным образом распродают оставшиеся археологические памятники, которые все еще лежат под землей.

Россия ничего не делает случайно. План лишить татар их истории и их имени – старый, и он осуществляется с терпением и упорством.

[1] Автор публикации приводит на этот счет соответствующие данные (QHA, 27.09.2020/21:42; 09.02.2022/11:59). Этот текст сокращен в связи с необходимостью некоторого уменьшения объема текста

Сейчас он применяется систематически, и российское руководство пользуется подходящим на международной арене моментом. С этой целью Кремль также пытается выбрать имя или иным образом заинтересованное сотрудничество с авторитетными учеными с Запада.

*Перевод с английского translate.yandex.ru*
*под редакцией Д.М.Исхакова*

***Рабит Батулла***

## ӘРВАХЛАР ӨЧЕН ДОГА

*(Айдар Хәйретдиннең шул исемдәге китабын укып чыккач туган фикерләр)*

Татарда дин галимнәре бик аз. Совет дәверендәге дәһрилекнең (атеизм) тәэсиредер бу. Аллага шөкер, мәчетләрне күп ачтык. Ләкин яңа ачылган мәдрәсәләрдә динне өйрәтү, дини фәлсәфәне тирәнтен аңлату юк! Чөнки дин галимнәребез җитәрлек түгел. Кызганыч, ике-өч галим генә җитми шул. Күпләп, күтәрелеш чорындагы кебек, кәрван-кәрван галимнәр кирәк. Дин тирәсендә дилетантлар җитәрлек, мөҗтәһидләр генә җитешми. Муллаларыбыз Коръән аятьләрен гарәпчә укый да, шуның татарча аңлатмасын бирә, шунысына да рәхмәт, башлангыч белем өчен анысы да бик мөһим. Әмма Коръәндәге мөташабиһ аятьләрне аңлатырга аларның көче җитми.

Алдыбызда Айдар әфәнденең китабы ята. Галим бу әсәрендә гаять кызыклы мәсьәләләр, бәхәсле мәүзугълар күтәрә. Галимнәр өчен дә, бу мәсьәләләр белән кызыксынучы гади укучылар өчен дә бу китапның чыгуы вакыйга булып тора. Мин үземне гади укучыга саныйм. Шуңа күрә, китаптагы кайбер өлешләрне мин как-кат укыдым. Кат-кат укысам да, аңламаган урыннар да калды.

Китапта мәүзугълар байтак: реинкарнация (җанның бер гәүдәдән икенчесенә күчүе), намус, нәфес, җан белән шәхес төшенчәләре, җәһәннәм газаплары... Һәрбесе җитди, һәрбесе кызыксыну уята...

Бу китап – соңгы еллар дин әдәбиятындагы иң кызыклы, бәхәс кузгата торган әсәр. Тукай «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? Юк, ул үлмәгән дә, йокламаган да, ул бары тик һуштан гына язган», дип бәхәс куптарган кебек, бу әсәр дә халыкны «рухи йокыдан уятырга» тырыша. Тукайга да, Айдар Хәйретдингә дә өстәп шуны әйтим: безнең милләт үлмәгән дә, һуштан да язмаган, рухи йокыга да талмаган: татар милләте мәрткә (комага) киткән. Монысы инде бик җитди мәсьәлә, аны уятыр өчен реинкарнация түгел, реанимация кирәк. Мәрткә китмәгән булса, ул Ана теле өчен, халык санын алулардагы ялган мәгълүматка риза булмыйча, Ана телен дәүләт теле итәр өчен теше-тырнагы белән каршы торыр иде.

Әлбәттә, Айдар әфәнденең бу әсәре галимнәрне дә, гади мөселманнарны да бәхәскә тартачак. Автор моны үзе дә белеп тора. Бәлки ул махсус рәвештә бу бәхәснең булуын телидер, бәхәс гафләт йокысындагыларны да уятачак. Бу китап турында җыелышлар, конференцияләр, тәкъдир

итү кичәләре, радио-телевизион тапшырулар булырга тиеш. Барысы да катнашсын өчен.

Әсәрнең төп темасы – реинкарнация, ягъни җанның башка хайван яки башка кешенең калыбына кереп яшәве турында. Башка диннәрдә реинкарнациягә ышынучылар бик күп, ләкин бу хакта Коръәндә турыдан-туры әйтелмәгән. Әмма Айдар әфәнде «җаннарның җиргә кат-кат китерелүе турында Коръәндә моңа ишарәләр» бар, дип саный. Һәм ышанычына дәлил итеп, бер вакыйганы исенә төшерә: татар зыялылары арасыннан җанның реинкарнация аша тәннән-тәнгә күчеп йөрүләренә ышанган кешеләр әйткәннәр, имеш: алар 40 сүрәнең 11 аятен укыганнаң соң, моңа ышана башлаганнар икән (16 бит). Аятьтә язылган: ***«Алар: “Рабыбыз! Син безне ике мәртәбә үлдердең, ике мәртәбә терелттең!”»***

Төрек галиме Хәсән Чантай бу аятьне болай шәрехли: ***«Беренче терелү – туу, икенче терелү – Кыяматтә. Беренче үлем – ана карынындагы яралгының җансызлык халәте. Икенче үлем – бу дөньядан китү»***.

Айдар әфәнде реинкарнациянең булганына дәлил буларак, Коръәннең 32 сүрәсендәге 10 аятьне китерә: ***«“Без җир эчендә югалып китсәк тә, яңадан яратылган булачакбызмы?” – диделәр алар. Юк, алар – шул Аллаһка юл куючы, ышанмаучылар»*** (Г. Исаев тәрҗемәсе) (145 бит).

«Алар – шул Аллаһка юл куючы, ышанмаучылар» җөмләсен кат-кат укыдым, аңламадым, киштәмдәге егерме тәрҗемәне актарып чыктым, юк андый сүз бу аятьтә. Алар – ышанмаучылар, Аллаһка юл куямы? Алар үзләре ышанмый, Аллаһка юл биргәч, Аллаһка разый булалар түгелме соң? Тәрҗемә бик буталчык.

Шул ук аять Крачковский тәрҗемәсендә: ***«Они сказали: “Разве, когда мы заблудимся в земле, – разве мы возникнем в новом создании?” Да, они не верят во встречу со своим Господом!»***

Төрек галиме Сыткы Гүллә тәрҗемәсе: ***«Диделәр: “Туфракта югалганыбыздамы, чыннан да безме хакыйкатән, өр-яңадан яратылмыш эчендә булачакбызмы?” Дөресе шул, алар Раббылары белән кавышуны инкяр итте»***.

2020 елда чыккан «Каләм Шәриф»тәге тәрҗемә: ***«Алар (мөшрикләр): “Без (күмелгәннән соң) туфракта югалгач, өр-яңа бер яралтылыш белән торгызылачакбызмы әллә?” – диделәр. Юк алар (үлемнәреннән соң терелеп, мәхшәргә җыелуны һәм шулай итеп,) Раббылары белән очрашуны инкарь иттеләр»***.

Айдар әфәнде бу аятьне үзе менә ничек тәрҗемә итә: ***«Алар әйттеләр: “Без җирдә (җир эчендә) югалгач, без, чыннан да, яңа булдырылыштабызмыни?” – диделәр. Әйе, алар Раббылары белән очрашуны***

***кире кагучылар»*** (146 бит). «Булдырылыштабызмыни» тәрҗемәсе укырга да, әйтергә дә кыен, телеңне сындырырлык.

Тәрҗемәләрнең кайсысы ныграк аңлашылганы турында сүз куертмыйча гына, әйтик: бу аятьтә җанның бер тәннән икенчесенә күчеп йөрүе турында сүз юк бит. Монда реинкарнациянең эзе күренми. Башка диннәрдәге реинкарнацияне җанның эт, ишәк, песи калыбына кереп яшәүләре турында ишеткәләгән бар, ләкин Айдар әфәнде мисал итеп китергәннәрендә бу турыда сүз юк. Яңадан терелү турында мәгълүмат бар, әмма җанның башкалар калыбына керүе турында ләм-мим.

Дөрес яза, Айдар әфәнде, юктан бар итми Алла, Алла үзе бар, бар Затны барлыкка китерә, һәр шәйне: матдәне, галәмне. «Барлыкка китерә» гыйбарәсе урынына «булдыра, булдырыла, булдырылганнардан, булдырыштабыз» кәлимәләрен бик еш куллана автор. Ләкин бу нәрсә буталчык.

***«Шәһадәт кәлимәсеннең әйтелүе, аны әйткән кешене иман иясе, ягъни мөэмин итми»***, – ди Айдар әфәнде.

Килешәм! Ләкин «мөэмин итми» сүзтезмәсе артыктыр. «Иман иясе итми», ягъни шәһадәт кәлимәсен әйтсәң дә, син чын иман иясе була алмыйсың, чөнки син монафикъ, диндә ихлас түгел.

Сөекле Пәйгамбәребез Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисе бар, ул – гүзәллек турында. Пәйгамбәр әйткән: ***«Чибәр йөзгә карап алу – ул гыйбадәт!»*** – дигән. Димәк, гүзәллеккә соклану – ул Аллаһка гыйбадәт, бу гүзәллекне булдырганы өчен Аллаһ Тәгаләгә рәхмәт вә шөкерләр булсын! Килешәм!

***«Байтак еллар узгач кына аңладым: чынлыкта, минем мәдрәсә бетермәвем – Аллаһның бер рәхмәтедер, чөнки анда укыган булсам, үз акылым белән уйлый алу сәләтен югалткан булыр идем, мөгаен»***, – дип яза автор (9 бит).

Әлбәттә, Айдар әфәнде бүгенге мәдрәсәләр турында яза, ләкин бу сүзләр күпмедер дәрәҗәдә Курсави, Мәрҗани, Риза Фәхерддин, Барудилар укыган мәдрәсәләргә дә кагыла кебек. Бүгенге мәдрәсәләрне дә алай ук инкяр итәргә ярамый шикелле, алар, ичмасам, башлангыч дини белем биргән очракта да бик кирәкле шәйдер.

Автор мөселманнарның «кол булып яшәүләре, артта, караңгылыкта, наданлыкта калулары» турында әйтә дә, без: ***«Мөселманнарны шундый көнгә китерүчеләр – "дин галимнәре". Монысы – чынбарлык. Әмма чынбарлык никадәр ачы булса да, мөселман дөньясы һаман да борынгы галимнәрнең язганнарына ябышып ята. Ул –"галимнәр"нең үзләрен белгечләр дип санаулары, өммәтне гасырлар дәвамында авызларына каратып утыртулары – олы бер бәла»***, – дигәннәр белән танышабыз (13 бит).

Айдар әфәнде, Сез дөньякүләм мәшһүр ислам галимнәрен, шулар сафында Мәрҗани, Фәхреддин, Муса Бигиләргә дә кизәнәсез түгелме?

Мөхтәрәм Айдар әфәнде китапның буеннан-буена «барлыкка китерү» мәгънәсендә «халык» кәлимәсен куллана. Без, бүгенге татарлар, бу сүздә бары тик «кешеләр төркеме, халык» дип кенә аңлыйбыз: авыл халкы, татар халкы, шәһәр халкы буларак төшенәбез. Мирза Мәхмүтовнең «Гарәпчә-татарча-русча» сүзлегендә – «халикъ» – яралтучы, бар кылучы, Ногмани тәфсирендә – «халык», Адлер Тимергалинның «Алла» исемле мәкаләсендә [Казан утлары: 2009. №9] «хәлык» дип яза. Соңгысы төп нөсхәдәгесенә тәңгәл килә. Миңа калса, «халикъ» булса кулайрак булыр иде.

Безнең дәвергә чаклы 427–347 елларда яшәгән борынгы Юнан милләтенең акыл иясе Әфләтун бабай Алла турында болай әйткән:

– Алла ул тәнсез, шуңа күрә, ул тузмый, Алла мәңге тере! – дигән.

Ике мең ел әүвәл яшәгән Әфләтун аңлата белгән бит Алланың сыйфатын. Әфләтун бабайдан соң күпме галимнәр, күпме имамнар, муллалар, мөҗтәһидләр әйтә алмаганны әйтеп салган.

Алланың асылын аңлата башласаң, кире чыкмас фикри буталчылыкка кереп батачаксың. Христианнар Алланы кеше кыяфәтендә күзаллый, кешенеке кебек Алланың да башы, кул-аяклары бар, дип ышана. Корьән Алланың тышкы кыяфатен тасвирламый. Язучы-физик Адлер Тимергалин «Алла» исемле мәкаләсендә шактый кызыклы фикерләр язып чыкты. Алла – ул гомумгаләмдәге акыл, дип тә аңлатучыар бар. Ул – Идея, Мәгънә, диләр. Корьәндә Алланың кулы турында сүз бар. Каян килеп? Алла адәми затка охшаш түгел, ләбаса.

«Фәтех» сүрәсе (48), 10 аять. И. Крачковский тәрҗемәсендә: ***«Поистине, те, которые присягают тебе, присягают Аллаху. Рука Аллаха – над их руками».***

«Каләм Шәриф»тә аять бу рәвештә бирелгән: ***«Аллаһның кулы аларның куллары өстендә»***.

Моны ничек аңларга?

«Кул» сүзе «идарә, ихтыяр, ирадә, власть» мәгънәсендә киләдер бәлки. Бу сорауга дин галимнәре җавап бирер, дип уйлыйм.

Айдар әфәнде Хәйретдиннең язма теле шактый һәйбәт, ләкин яңа басмасындагы китапта хәреф хаталары төзәтелсә, яхшы булыр иде. Әсәргә шәп редактор кирәк.

Тел чатаклыклары турында тагын бер-ике сүз:

– ***ул чакта кыйлган иң зур хатам ошбу*** (шушы) ***булган икән*** (17 бит);
– ***бик күптөрле вакыйгалар аша уздырылдым (***уздым***)*** (17 бит);
– ***диндарлык арасындагы аерманы күрергә өйртелдем*** (өйрәндем) (17 бит);

– ***рәсми бер караш тарафтары*** (тарафдары) ***идем*** (18 бит);
– ***ни әйтергә теләгәнен шундук аңлый ала алмадым*** (аңлый алмадым яки аңламадым) (19 бит);
– ***диндә көчләү юк*** (диндә ирексезләү юк) (22 бит). Көчләү – изнасилование, насилие; ирексезләү – неволить, заставить, вынудить;
– ***барлыкны барлыкка китерер өчен Аллаһ беркайда да бармаган; кайда да булса баруның кирәге дә булмаган.*** (беркая да бармаган), кайда – где, кая – куда (42 бит). Барлыкны барлыкка китерер өчен беркайда да бармаган – тизәйкеч барлыкка килгән;
– ***сорауны күрмәмешкә сабышып*** (салышып), салышып – делал вид, сабышып – авыруга сабышып ята. Чынлап авырый. (44 бит);
– ***мәетне шунда салалар да күмеп куялар.*** Җәсәден җирлиләр, җир куенына тапшыралар, гүргә иңдерәләр. Татар яки алтынын җиргә күмә, яки мал үләксәсен күмә. Адәми затның җәсәде җирләнә, җир куенына тапшырыла, гүр иясе була. Мәрхүмне дәфен итәләр (62 бит);
– ***нинди атадан белән кайсы анадан гәүдә алачагын...*** «белән» сүзе артык (69 бит);
– ***Раббым! Мине гыйлем белән арттырсана.*** Гыйлememне, белемемне арттыр (79 бит);
– ***тынычлыкта калдырырлар да фетнәләнүгә дучар ителмәсләр, диеп уйлыйлармы әллә?*** Аңлашылмый, яңадан карап чыгасы бар. Ни-нәрсә ул «фетнәләндерүгә дучар ителү»? (83 бит);
– ***Моннан алда җәннәткә лаеклы булып та...*** Лаек – достойный, ә лаеклы нәрсә? (87 бит). Тукай бүләгенә лаек булды, «лаеклы» түгел;
– ***хәтта дөрес аңласаң булсаң да*** (дөрес аңлаган булсаң да) (112 бит);
– ***ул маңгайга төшеп торган озын чәч тарын белдерә.*** «Тар» диалекталь сүзме? Алайса, аңлатыш кирәк (112 бит);
– ***фәрештәләрнең янә генә күмелгән мәет янына килеп.*** Яңа гына җирләнгән (138 бит);
– ***яңа булдырылыштабызмыни?*** «Халикъ» сүзенең тәрҗемәсе (булдырылышта) уңышлы түгел (146 бит);
– ***Раббым, минем адашуымны фаш иткәнең аркасында, мин һичшиксез, алар өчен җирдәгене бизәкләндерәчәкмен һәм, һичшиксез, аларның һәммәсен дә адаштырачакмын.***

Бу аять хөрмәтле Айдар әфәнде Хәйретдин тарафыннан шулай тәрҗемә ителгән (157 бит).

Бу купшы җөмләләр арасында аятьнең мәгънәсе, чыннан да адаша, аять аңлашылмый. Иблиснең адашуы нәрсәдә, Аллаһның Иблисне фаш итүе нәрсәдә? Азмы-күпме Коръән белән танышкан кешегә бу

аңлашылыр да, әмма укучыларның күбесенә аңлашылмас. «Җирдәгене» сүзе нәрсәне аңлата? «Бизәк» (украшение), «бизәнә» (намаливается, прихорошивается), чыршыны бизиләр, «җирдәгене бизәкләндерәчәкмен» гыйбарәсе аңлашылмый (157 бит).

Эш менә нәрсәдә, Аллаһ Адәмне балчыктан ясап, аңа җан өрә һәм фәрештәләргә Адәм тарафына тәгъзим ясап, аңа баш иярга куша. Иблис баш тарта. Шул тәкәбберлеге өчен Аллаһ аны ләгънәтләп куа. Иблис үкенми, әле һаман Аллага яный: минем тәкәбберлегемне фаш иткәнеңә күрә, мин, һичшиксез, аларның гөнаһ кылганнарын (әшәке эшләрен) бизәп, бу яхшы гамәл, дип күрсәтәчәкмен, ди.

Тагын бер буталчык тәрҗемә: ***«аңлы булу адашудан күренеп торырлык кадәр аерымланды – кем дә кем тагутны кире какты да Аллаһка иман итте исә, ул нык тоткага ныклап тотынды»*** (159 бит).

Татар сүзләреннән генә торса да, бу җөмләнең төзелеше татарча түгел һәм аятьнең мәгънәсе аңлашылмый.

***«Нык тоткага ныклап тотынды»***, җөмләсен дә аңлавы кыен.

Каләм Шәриф нөсхәсендә дә бу аять аңлашылмый:

***«Тугры юл адашудан бик ачык аерылды. Кем дә кем тагутларны (шайтанны һәм потларны) инкяр итеп, Аллаһка инанса, ул кубуы (сыну, ватылу ихтималы да) булмаган ышанчылы тоткага тотынган булыр»***.

Эш менә нәрсәдә, аятьнең беренче юлы: хак юл белән адашканнарның юлы ачыкланды, ди. Тагутны (шайтанны) инкяр итеп, тугры юлга баскан кеше Алаһның диненә – ышанычлы тоткага ябышкан кебек булыр, ди.

Айдар әфәнде Хәйретдиннең тәрҗемәләренең авыр аңлашылуының сәбәбе: Коръәннең төп нөсхәсендәге сүзләрдән аерыласы килмәүдә. Бар сүзен сүзгә тәрҗемә, ул галимнәр өчен бик кирәк. Бар төп нөсхәдән ерак китмичә тәрҗемә ителгән Коръән: Крачковский, Муса Биги Җарулла. Бар тәфсирле тәрҗемә. Алары байтак: Иманколый, Фәрит Сәлмән, Ногмани...

Әгәр дә без Коръәннең төп нөсхәсеннән аерыласыбыз килмичә тәрҗемә итсәк, күп нәрсә аңлашылмас иде, мәгънәви тәрҗемә безгә кадерле. Әйтик: ***«Кулыңны үз муеныңа бәйләмә, кулларыңны җәеп тә җибәрмә»***, (17:29) аятен сез аңламаячаксыз. Бу аять саранлык белән артык юмартлык турында. Димәк, урта белемле татар Коръәнне аңласын өчен, мәгънәви вә шәрехле тәрҗемә кирәк. Айдар әфәнде әнә шушы кыенлыкта кала һәм аять аңлашылмый.

Автор гарәп телендәге бүгенге заман, киләчәк заманнар турында яза. Ләкин гарәп теле белән татар теле арасында шактый аерма бар. Әйтик, мулллар, вәгазьчеләр дә заманнарны бутап сөйли. Аллаһу Тәгалә әйтте, Мөхәммәт әйтте – бүгенге заман, Аллаһны, Мөхәммәтне бүген тыңлап

торган кеше генә, вакыйгага шаһит булган кеше генә: «Әйтте, китте, кайтты» – дип сөйли. Татарча бик үк яхшы белмәгән берәү сөйли. Аның дустын хулиганнар кыйнаган иде:

– Ни булган дустыңа?

– Ул ресторангнан чыкты да, өенә кайтып китте, бер исерек аның артыннан куып җитеп, аңа таш белән сугып качты.

– Син үзен шунда идеңмени?

– Юк, ул үзе сөйләде.

Егет бу вакыйганы болай сөйләргә тиеш иде:

– Ул рестораннан чыккан да, өенә кайтып киткән, бер исерек аның артыннан куып җитеп, аңа таш белән сугып, качып киткән.

Соңгы заманнарда, ни өчендер, дин тирәсендә төрле агымнар пәйда булды. Кемдер мәрхүмнең өчесен, җидесен, кырыгын Коръән укып, мәҗлес уздырырга ярамый, дип кешеләр күңеленә вәсвәсә сала, кайсысы, имеш, зиратта әрвахлар рухына дога укырга ярамый, ди. Кайберәүләр шайтан арбасы дип, трамвайга утырырга ярамый, ди. Чит илләрдә укып кайткан яшь муллаларның сүземе бу? Әллә мөселманнарның арасын бозу өчен бу вак-төяк аермалыкларны таратумы? Безнең ата-бабаларбыз Әбү Хәнифә мәзһәбен тотканнар, сөнни буларак, диннең кагыйдәләрен бик яхшы белгәннәр, язып калдырганнар, без шуннан аерылмаска тиеш.

Мондый агымнар бигрәк тә яңа гына дин дәресләре ала башлаучылар арасында була, дин белеме юк, кем ни әйтсә, шуңа ышана бу катлау халык. Динне тышкы кыяфәткә калдырып, яулыкка төренеп, артык озын итәк киеп, ике сүзнең берендә «иншаллаһ» сүзен еш кабатлап, үзенең дингә кереп киткәнлеген күрсеннәр, дип, җыелышлардан «мин намаз укып керим әле», дип демонстратив рәвештә чыгып китеп, ураза тотып шушы турыда кешеләргә сөйләп йөрүчеләр күбәеп китте.

***«Үзенең “диндар”булуы белән, шәригатьчә яшәве белән шулкадәр масая башлый ки, андыйлар, янында басып торырлык түгел. Хәер, андыйга бер-ике мәртәбә юлыксаң, өченче мәртәбәсеннән качачаксың. Ә инде андыйлар шәригать кануннары исеме белән кешеләргә үзләренең бозык фантазияләрен такканда, эшләр бөтенләй яманга китә, җәмгыять үсештән туктый, артка тәгәри, вәхшиләнә»***, – дип яза Айдар әфәнде Хәйретдин. Килешәм! Андый «диндарлар» хәттин аша, хатын-кызларга: нигә яулык бәйләмәдең, нигә намаз укымыйсың, нигә ураза тотмыйсың, дип тупас бәйләнә, бу муллалар, бу абыстайлар үзләренең тупаслыклары белән кешене диннән, мәчеттән биздерә. Юкса, «диндә ирексезләү юк», диеп язылган китапта.

«Диндә артыгын кыланмагыз! Фанатик булмагыз!» – ди Изге Коръән Шәриф. (4–171; 5– 77).

«Әрвахлар өчен дога» китабында бу хакта да сөйләнә.

Нинди генә кимчелекләре булмасын, Айдар әфәнде Хәйретдиннең «Әрвахлар өчен дога» исемле бу китабы мөселман голәмәсен гафләт йокысыннан уятыр, иншаллаһ. Гүрләрендә дога өмет итеп ятучы әрвахларга догабыз барып ирешсен! Исәннәргә тугры юлны табарга ярдәм ит, Раббым! Әмин!

* * *

1552 елдан соң татар халкының кара коллык дәвере башлана. Салымнар, хәрби хезмәт игосы халыкның билен сындыргандай була. Корьән бастыру юк (булганын да утка аталар), мәчетләр кырыла яки башка вазифага күчерелә, муллалар юк, аларны үтерәләр, сөргенгә сөрәләр. Ир-егетләр сугышларда һәлак була, егерме бишәр ел авыр хезмәттә интегә. Шушы коточкыч изүләргә чыдый алмыйча, татар халкы әледән-әле баш күтәрә, Пугачау явының күп өлеше татар-башкорт гыйсьянчыларыннан тора. Пугачауның егерме полковнигының унсигезе татар кешесе була бит. Пугачау явы Әби патшаның тәхетенә яный башлый. Һәм Әби патша үзенең атаклы фәрманын чыгарга: мөселманнарга дин ирегге бирә.

300 елдан артык милли изү астында яшәгән татар халкы мәчет-мәдрәсәләр кора, Коръәнне кат-кат бастырып чыгара башлый. Гыйлем ияләре барлыкка килә. Мәгърифәт чәчәк ата. Татарларда Күтәрелеш-Яңарыш чоры башлана. Дин гыйлеме аеруча чәчәк ата. Бу чәчәк ату йөз илле ел буе гына дәвам итә, ни кызганыч.

1917 елда тагын кара язмыш килә татар өстенә. Мәчетләр җимерелә, имамнары атыла, исән калган мәдрәсәләре «ышкул»га әверелә, исән калган мәчетләре клубка әйләнә. Өч тапкыр имля алмаштырып, татар халкын наданлык чокырына тәгәрәтеп төшерде. Яшь буынны диннән, Алладан, Коръәннән биздерделәр. Без дәһригә әвереллдек. Динсез халык – денсез халыкка әйләнә.

*Айдар Хәйретдин*

## БАТУЛЛА ӘФӘНДЕНЕҢ «ӘРВАХЛАР ӨЧЕН ДОГА» ИСЕМЛЕ КИТАПКА ЯЗГАН БӘЯЛӘМӘСЕНӘ ӨСТӘМӘЛӘР

Беренче нәүбәттә, минем китабыма игътибар итеп, аңа бәя бирергә вакыт тапканы өчен Батулла әфәндегә ихлас шөкеремне белдерәм. Милләтебезнең шөһрәтле бу кешесе язган бәяләмә китабымның дәрәҗәсен арттыра, чөнки, асылда, ул бәяләмә китап турында уңай тәэсир калдыра.

Инде Батулла әфәнде өчен аңлаешсыз калган яки өстәмә төшендерү таләп иткән кайбер мәсьәләләргә игътибар итәсе килә.

Батулла ага болай дип яза:

«Айдар әфәнде реинкарнациянең булганына дәлил буларак, Коръәннең 32 сүрәсендәге 10 аятьне китерә: ***«“Без җир эчендә югалып китсәк тә, яңадан яратылган булачакбызмы?” – диделәр алар. Юк, алар – шул Аллаһка юл куючы, ышанмаучылар»*** (Г. Исаев тәрҗемәсе). 145 бит.

***«“Алар – шул Аллаһка юл куючы, ышанмаучылар”*** җөмләсен каткат укыдым, аңламадым, киштәмдәге егерме тәрҗемәне актарып чыктым, юк андый сүз бу аятьтә. Алар – ышанмаучылар Аллаһка юл куямы? Алар үзләре ышанмый, Аллаһка юл биргәч, Аллаһка разый булалар түгелме соң? Тәрҗемә бик буталчык», – дип яза Батулла ага.

Батулла әфәнде Габделбарый Исаев тәрҗемәсенең аңлаешсыз булуына игътибар иткән. Әмма, ни кыйлыйм, чыганакта шулай язылган (кара: [Габделбари хәзрәт Низаметдин улы Исаев. Коръән Кәрим тәрҗемәсе / Фәнни мөхәррире Ә.К. Бостанов. Казан: Издательский дом «Казанская недвижимость», 2018. Б. 343]).

Безнең өчен исә Исаев тәрҗемәсендә аятьнең беренче җөмләсе мөһим: ***«“Без җир эчендә югалып китсәк тә, яңадан яратылган булачакбызмы?” – диделәр алар»***. Һәм әлеге тәрҗемәгә өстәп, Батулла әфәнде искә алган башка тәрҗемәләрне дә китерәм. Ул болай дип яза:

«Шул ук аять Крачковский тәрҗемәсендә:

«*Они сказали:* ***“Разве, когда мы заблудимся в земле, – разве мы возникнем в новом создании? Да, они не верят во встречу со своим Господом!”***»

Төрек галиме Сыткы Гүллә тәрҗемәсе:

«*Диделәр:* ***“Туфракта югалганыбыздамы, чыннан да безме хакыйкатән, өр-яңадан яратылмыш эчендә булачакбызмы?”*** *Дөресе шул, алар Раббылары белән кавышуны инкяр итте».*

2020 елда чыккан «Каләм Шәриф»тәге тәрҗемә:

«*Алар* (мөшрикләр): ***“Без (күмелгәннән соң) туфракта югалгач, өр- яңа бер ялтылыш белән торгызылачакбызмы әллә?” – диделәр. Юк алар (үлемнәреннән соң терелеп, мәхшәргә җыелуны һәм шулай итеп,) Раббылары белән очрашуны инкарь иттеләр***».

Безнең тәрҗемә:

«*Алар әйттеләр:* ***“Без җирдә (җир эчендә) югалгач, без, чыннан да, яңа булдырылыштабызмыни?” – диделәр. Әйе, алар Раббылары белән очрашуны кире кагучылар»*** (146 бит).

Беренчедән, Батулла әфәнде китергән тәрҗемәләрнең: ***«разве мы возникнем в новом создании?» – «чыннан да безме хакыйкатән, өр-яңадан яратылмыш эчендә булачакбызмы?»; «Без (күмелгәннән соң) туфракта югалгач, өр-яңа бер ялтылыш белән торгызылачакбызмы әллә?»***, бер үзенчәлегенә игътибар итик. Ул да булса, ул тәрҗемәләрнең һәммәсендә дә фигыль (***возникнем, булачакбызмы, торгызылачакбызмы***) бар, һәм ул фигыль киләчәк заман шәкелендә тора. Әмма аятьтә фигыль бөтенләй юк. Шуңа күрә мин аны фигыльсез ***«“Без җирдә (җир эчендә) югалгач, без, чыннан да, яңа булдырылыштабызмыни?” – диделәр»***, дип тәрҗемә иттем. Фигыль юк икән – телгә алынган эшнең кайчан башкарылганын белдерә торган заманга да ишарә юк. Димәк, аятьтә мәет җиргә иңдерелгәннән соң була торган хәл турында әйтелә: ***«без... яңа булдырылыштабыз»***. Бу хәл киләчәккә күчерелмәгән. Әгәр тәфсирләрдә «аять киләчәктә мәетләрнең тереләчәкләре турында хәбәр итә», диелә икән – тәфсирчеләрнең болай итүләре тупас хата һәм изге аятьнең мәгънәсен бозудан башка һичнәрсә түгел. Бу аятьтә һәм аңа тәңгәл булган башка күп санлы аятьләрдә Аллаһ Тәгалә кеше үлеп кабергә салынганнан соң, кешене җирдә терек хәлдә тоткан рухның яңа булдырылышта булуы турында хәбәр итә.

Алга таба Батулла әфәнде: *«“Булдырылыштабызмыни” тәрҗемәсе укырга да, әйтергә дә кыен, телеңне сындырырлык”»*, – дип яза да «булдырылышта» дигән сүзнең кулланылуына ризасызлыгын белдерә.

Бәхәсләшмим, ул хаклы. Әмма мин кабердә череп таркалган мәеттән аерылган рухның кичергән процессын белдерә торган башка сүз таба алмадым. Тел байлыгым җитмәде. Урыс мәктәбендә укыдым, шуның шомлыгы. «Булдырылышта» дигән сүзтезмә аятьтә (لَفِي خَلْقٍ) «*лә-фи халкын*» сүзтезмәсе белән бирелгән. Гарәпчә «халк» (خَلْق), дип яңгыраган сүз татарга таныш. Телебездә бу сүз белән тамырдаш булган *халык*, *холык*, *мәхлук* кебек атамалар бар. Элеккеге әдәби телебездә *халык кыйлырга*, *халык итәргә*, кебек фигыльләр булган, *халәкать*, *халикъ*, *хәллякъ* кебек сүзләр дә кулланылган. Әгәр аятьне тәрҗемә иткәндә *халәкать* сүзен кул-

ланып ***«без... яңа халәкатьтәбез»*** дигән булсам, болай итүем иң дөресе дә, иң матуры да булыр иде, әмма мәгънәсен аңлау кыенлашыр иде.

*Батулла әфәнде болай ди:*

«Тәрҗемәләрнең кайсысы ныграк аңлашылганы турында сүз куертмыйча гына, әйтик: бу аятьтә җанның бер тәннән икенчесенә күчеп йөрүе турында сүз юк бит. Монда реинкарнациянең эзе күренми. Башка диннәрдәге реинкарнацияне җанның эт, ишәк, песи калыбына кереп яшәүләре турында ишеткәләгән бар, ләкин Айдар әфәнде мисал итеп китергәннәрендә бу турыда сүз юк. Яңадан терелү турында мәгълүмат бар, әмма җанның башкалар калыбына керүе турында ләм-мим».

Бирედә реинкарнацияне трансмиграция төшенчәсе, ягъни җаннарның кешедән кеше булмаган башка бер мәхлукка күчүе белән бутарга ярамауга игътибар итәсем килә. Мин реинкарнация турында яздым. Әлеге күренеш җанның кат-кат кеше тәненә иңеп, кеше яшәешен кичерүен белдерә. Бу хакта Батулла әфәнде: *«Яңадан терелү турында мәгълүмат бар, әмма җанның башкалар калыбына керүе турында ләм-мим»*, – дип яза. Язганыннан аңлашылганча, ул аятьнең яңадан терелү турында хәбәр итүен генә аңлаган. Анысына да, шөкер. Батулла әфәнденең *«җанның башкалар калыбына керүе турында ләм-мим»* дигән сүзе ни мин әйтергә теләгән фикергә якын килми, ни аятьнең мәгънәсенә. Аятьтә исә кабергә салынган мәет череп таркалгач, аннан аерылган җанның башка гәүдәгә иңдерелүе турында хәбәр бар.

Бу, һәм аңа охшаган башка аятьләр, яңадан терелтелүгә ышанмаган мөшрикләрнең Мөхәммәт пәйгамбәрдән (□) ишеткән сүзгә инана алмыйча, аңа биргән сорауларын саклап калганнар. Әмма яңадан терелтелүгә инанмаганнарның сорауларында Мөхәммәт пәйгамбәрнең (□) аларга әйткән сүзләре чагыла. Моның шулай булуы 34 сүрәнең 7 нче аятендә яңадан терелтелүгә инанмаганнарның әйткәннәреннән аңлашыла: *«Көфер кыйлганнар әйттеләр: "Сезгә: "[кабердә] таркалуның бөтенләе белән таркалып беткәннән соң сез яңа булдырылыштасыз", – дип хәбәр итүче берәүне күрсәтикме сезгә?»*. Аятьтәге *«хәбәр итүче берәүне»* нәкъ менә Мөхәммәт пәйгамбәрне (□) күздә тота. Димәк, пәйгамбәребез Мөхәммәд (□) кавемдәшләренә: *«Каберегезгә кереп юкка чыкканыгыздан соң, сез яңа булдырылыштасыз»*, дип кат-кат әйтә торган булган.

Батулла минем ***«"Байтак еллар узгач кына аңладым: чынлыкта, минем мәдрәсә бетермәвем – Аллаһның бер рәхмәтедер, чөнки анда укыган булсам, үз акылым белән уйлый алу сәләтен югалткан булыр идем, мөгаен"»***, дигән сүзләремә игътибар итеп, болай дип дәвам итә: *«Әлбәттә, Айдар әфәнде бүгенге мәдрәсәләр турында яза, ләкин бу сүзләр күпмедер дәрәҗәдә Курсави, Мәрҗани, Риза Фәхерддин, Баруди-*

*лар укыган мәдрәсәләргә дә кагыла кебек. Бүгенге мәдрәсәләрне дә алай ук инкяр итәргә ярамый шикелле, алар, ичмасам, башлангыч дини белем биргән очракта да бик кирәкле шәйдер»*.

Борынгы мәдрәсәләр дә, хәзерге мәдрәсәләр дә адәм баласының акылын сүндерү, фикерләү сәләтен үтерү урыннары булганнар, дип уйлыйм. Курсави, Мәрҗани, Риза Фәхреддин, Барудилар һәм башка йөзек кашларына тиң зиһен вә акыл ияләребез булган икән, болар өчен шөкеребез мәдрәсәләргә түгел, Аллаһ Тәгаләгә булырга тиеш, чөнки әгәр Аллаһ Тәгалә үзенең кодрәте белән андый затларга акыл көче вә иман ныклыгы бирмәгән булса, алар да дини фикер тарихы мәйданында эз калдырмаслар иде. Мәдрәсәләрдән бер генә файда булган: искә алынган олуг галимнәребезнең андагы тәртипләр белән килешә алмаулары, андагы гасырлар дәвамында үзгәртелмәгән уку-укыту методикаларына каршы булулары аларның акыл вә фикерләү кылычын кайрак таш кебек кайрарга-үткенләргә мөмкинлек тудырган.

Батулла әфәнде минем ***«“Мөселманнарны шундый көнгә китерүчеләр – “дин галимнәре”. Монысы – чынбарлык. Әмма чынбарлык никадәр ачы булса да, мөселман дөньясы һаман да борынгы галимнәрнең язганнарына ябышып ята. Ул –“галимнәр”нең үзләрен белгечләр дип санаулары, өммәтне гасырлар дәвамында авызларына каратып утыртулары – олы бер бәла”»***, дигән сүземне ала да: «*Айдар әфәнде, Сез дөньякүләм мәшһүр ислам галимнәрен, шулар сафында Мәрҗани, Фәхреддин, Муса Бигиләргә дә кизәнәсез түгелме?*» – дип яза.

Аңларга кирәк: бер якта цитатада куштырнаклап телгә алынган «дин галимнәре» бар, икенче якта Мәрҗани, Фәхреддин, Муса Бигиевләр кебек шәхесләребез бар. Болары чын мәгънәдә дин галимнәре генә түгел, болар – тынгысыз, үткен акыл ияләре, вөҗдан вә намус ияләре. Аларның галим булулары акыл, фикер, вөҗдан кебек нигез ташларына корылган. Шуңа күрә алар, гади «дин галимнәреннән» аермалы буларак, безгә бәрәкәтле мирас калдырганнар. Әмма, ***«чынбарлык никадәр ачы булса да, мөселман дөньясы һаман да борынгы галимнәрнең язганнарына ябышып ята» шул***. Монысы хак. Мәрҗани, Фәхреддин, Муса Бигиевләр кебекләрнең мирасы бу халәтне әлегә кадәр үзгәртә алмады. Шуңа күрә мөселман дөньясында чәчләрне үрә торгызырлык вәхшәтләр әлегә кадәр кыйлына тора, чөнки борынгы «дин галимнәре»нең Коръәнгә каршы килгән карар вә хөкемнәре гамәлдән чыгарылмаган.

* * *

Батулла әфәнде минем язма телемнең үзенчәлекләренә дә игътибар иткән, киңәшләрен тәкъдим иткән. Анысы өчен, әлбәттә, шөкер. Атаклы

язучы белән аралашуымда мин шәкертмен, абруйлы аганың киңәшләренә, әлбәттә, колак салачакмын.

Шулай да, бер тәкъдименә тукталып, эшнең асылын аңлатасым килә. Тегеләй яки болай үзгәртергә, яхшыртырга тәкъдим иткән байтак кына башка җөмләләр арасында Батулла әфәндегә минем ***«бик күптөрле вакыйгалар аша уздырылдым»***, дигән җөмләм дә ошамаган. Ул аны ***«бик күптөрле вакыйгалар аша <u>уздым</u>»***, дип язарга тәкъдим итә. Әмма, бу очракта мин аның белән килешә алмыйм, чөнки алай итсәм, эшнең асылына хилафлык кыйлган булачакмын. *Уздырылдым* – кайтым юнәлешендәгее фигыль. Ул ниндә дә булса эшнең субъект өстеннән башкарылган булуын белдерә. Мәсәлән, *китап укылды*. *Уздым* – төп юнәлештәге фигыль, ягъни бу эшне субъект үзе эшләгән: *мин китап укыдым*. Һәркемнең тормыш юлында үзе эшләгән эшләре бар, әмма аның белән, бәлки, ихтыярыннан тыш, аның өстеннән эшләнгән эшләр дә бар. *Уздырылдым* дип язуымның максаты да әнә шундый хәлләрне чагылдыру өчен иде: ул сүз мине Аллаһ йөрткән очракларны күздә тота, үз теләгем белән эшләгән эшләрне, барган урыннарны, кичергән халәтләрне түгел.

**Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар.**
**Хатлар һәм кайтавазлар**

**Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики**

## ХРОНИКА

16–21 мая 2022 г. в Болгаре РТ состоялся IV Международный Болгарский форум «Богословское наследие мусульман России», объединившее в своих рамках несколько мероприятий. В частности, 16–17 мая состоялась Международная научно-практическая конференция «IV Болгарские чтения “Исламское историко-культурное наследие российских мусульман в системе общечеловеческих ценностей”», в работе которой с докладами приняли участие доктор исторических наук, гл. редактор журнала «Туган җир. Родной край» Д.М. Исхаков, а также ученые, активно занимающиеся краеведением – кандидаты исторических наук Ф.А. Байрамова, З.А. Тычинских (Тобольск).

* * *

21 мая 2022 г. в Тобольске Тюменской области в Центре сибирско-татарской культуры состоялся Первый межрегиональный фестиваль татарского народного творчества «Язгы моңнар»/«Весенние мелодии», организатором которого выступила НКА сибирских татар Тобольска (рук. З.А. Тычинских). Идейный вдохновитель и председатель оргкомитета фестиваля – зам. председателя НКА сибирских татар Тобольска И.С. Уразмаметов.

Проект был направлен на сохранение и развитие традиционной культуры, песенного и хореографического искусства и творческий обмен между коллективами, приобщение молодого поколения к культурным ценностям, традициям и обычаям татарского народа, населяющего территорию Сибири и России. Основная идея проекта – собрать самодеятельные творческие коллективы, работающие на общественных началах.

В фестивале приняли участие творческие коллективы из Омска, Сургута, Лангепаса, Тобольска, Вагайского, Тобольского и Ярковского районов Тюменской области, Колосовского и Большереченского районов Омской области. Также на мероприятии были представлены выставки ИЗО, сувениров, национальной одежды, игрушек и др.

Фестиваль прошел на хорошем уровне. Зрители тепло принимали гостей, начало большому делу положено.

Организаторы благодарят за поддержку Департамент по культуре и туризму Тобольска, депутатов Тобольской городской Думы, председателя Омской татарской НКА «Ибирь» (Сибирь) Т.А. Алимбаева, Центр сибирско-татарской культуры Тобольска.

* * *

Третья декада мая 2022 г. ознаменовалась празднованием 1100-летия со дня принятия ислама в Волжской Булгарии. В рамках празднования 19–21 мая 2022 в Казани состоялся XII Всероссийский форум татарских религиозных деятелей «Национальная самобытность и религия».

Делегаты и гости форума приняли участие в заложении первого камня в основание Соборной мечети в Казани, а также в ежегодном форуме «Изге Болгар җыены».

В мероприятиях приняли участие Государственный Советник М.Ш. Шаймиев, Президент РТ Р.Н. Минниханов, председатель Государственного Совета РТ Ф.Х. Мухаметшин и др.

* * *

8–11 июня в г. Касимов (Ханкермане) Рязанской области прошли торжественные мероприятия «Наша память соткана из света» в рамках 1100-летия официального принятия ислама народами Волжской Булгарии. В их ходе состоялась VI Всероссийская научно-практическая конференция – «Чтения им. Мухлисы Буби по теме “Государство, образование, личность в истории ислама на российском пространстве”». В работе конференции приняли участие с докладами д.и.н., гл. редактор журнала «Туган җир. Родной край» Д.М. Исхаков, к.и.н. А.А. Бурханов (зам. редактора), З.А. Тычинских (спец. корр. по Западной Сибири) и др. ученые.

В ходе секционных заседаний конференции ее участникам был презентован журнал «Туган җир. Родной край» с коротким рассказом о его содержании. Web-редактор данного издания И.З. Гарифуллин объяснил слушателям возможности Интернет ресурсов данного издания.

* * *

27–29 июня 2022 г. в Стамбуле состоялся международный симпозиум на тему «Günumüz islam dünyasinda meseleler ve çözüm yollari». Мероприятие было организовано под эгидой «Türk ocakları» и посвящалось 110-летию данной организации. Из Татарстана с докладами приняли участие д.и.н. Д.М. Исхаков, к.и.н. А. Ахунов и к.ф.н. И. Гумеров и др. Темы докладов казанских ученых были связаны с ролью ислама в татарском обществе, начиная со средневековья и заканчивая современностью.

* * *

## Уфада очрашулар яки милләтнең тамгалы урыны

Язучы, тарих фәннәре кандидаты, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова 2022 елның 23–26 май көннәрендә Уфада халык белән зур очрашулар уздырып кайтты. Аның белән күптән көтелгән очрашу 25 май көнне БТКның Башкортостандагы вәкиллегендә булды, биредә, нигездә, татар зыялылары, язучылар, галимнәр, төбәк тарихчылары, журналистлар, милли хәрәкәт вәкилләре җыелган иде. Очрашуның төп темасы Фәүзия Бәйрәмованың кырык еллык иҗаты булса да, язучы милләт тормышына, бүгенге вазгыятькә дә үз бәясен бирде.

Фәүзия Бәйрәмова беренче тапкыр Уфага 1987 елда, «Болын» әсәре басылып чыккач, педагогия институты студентлары белән очрашуга килгән булган. Шушы вакыт эчендә ул илледән артык китап язган, шуларның күпчелеген үз хисабына бастырып чыгарган һәм халыкка тараткан. Башкортостанда яшәүче татарлар тарихын өйрәнеп, Фәүзия Бәйрәмова күп тапкырлар Иске Балтач районында булган, Батырша хәзрәт турында өч фәнни-популяр китап язган. Шулай ук Урал аръягындагы Бөрҗән, Учалы районнарында булып, үсмер балалар өчен «Нух пәйгамбәр көймәсе» дип аталган маҗаралы роман язып бастырган. Моннан тыш уфалылар Фәүзия Бәйрәмованың татар милли хәрәкәт корылтайларында, фәнни җыеннарда катнашуын да яхшы хәтерлиләр.

Язучы үзенең кырык еллык иҗаты турында яратып һәм җентекләп сөйләде, аны чорларга бүлеп, фәнни бәясен бирде. Беренче чор иҗатын ул лирик-романтик, дип атады, аңа «Болын», «Күл балыгы», «Канатсыз акчарлаклар» повестьларын һәм кайбер драма әсәрләрен кертте. Бу чор иҗатында ул кеше күңеленең тирән кичерешләрен тасвирлый, моның өчен серле символ-тамгалар телен файдалана. Икенче чор – көчеш чоры, автор әйтүенчә, аңа «Кыңгырау», «Кара урман», «Соңгы намаз» әсәрләре керә, монда тема, өслүп үзгәрүе дә күзәтелә. Өченче чор – тарихи романнар чоры, монысы инде XXI гасырда язылган «Кырык сырт», «Караболак», «Күчем хан», «Һиҗрәт», «Гөләйза» әсәрләре. Язучының әйтүенчә, соңгы еллар прозасында аның төп темасы – көчләп чукындырулар һәм 1930нчы еллардагы репрессияләр икән.

Фәүзия Бәйрәмова үзенең, язучы буларак, төрле жанрларда эшләвен, әмма төп жанры проза булуын әйтте. Аның драма әсәрләре дә булуы, кайберләренең сәхнәдә дә куелуы билгеле. Ул шулай ук публицистика, фәнни-популяр җанрда да күп эшли, балалар өчен дә яза, аның татар тарихына, милләт тормышына багышланган дистәләгән документаль китаплары бар. Фәүзия Бәйрәмова аерым шәхесләргә багышлап язган китаплары белән дә аерылып тора – аның Батырша, Күчем хан, Һади Такташ,

Һади Атласи, Габдрәшит Ибраһим, Михаил Худяков һәм Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә апа турында да документаль китаплары бар.

Бу очрашуда Фәүзия Бәйрәмова иҗатының соңгы чорына – тарихи романнарга аерым тукталды. Ул татар язучысы тарихны, сәясәтне, әдәбиятны, милләт тормышын, адашмас һәм укучыны адаштырмас өчен динне яхшы белергә тиешлеген әйтте. «Язучы надан булмаска тиеш, моның өчен гомер буе укырга һәм дөньяны өйрәнергә кирәк. Татар язучысы дөнья мөнбәрләрендә үз милләтен яклап чыгыш ясый алырлык дәрәҗәдә белемле һәм кыю булырга тиеш. Язучыга бәя биргәндә, аның татар әдәбиятына нинди яңалык алып килүенә дә игътибар итәргә кирәк. Ул күтәргән темасы белән аерылып торамы, тел байлыгы, сурәтләү чаралары беләнме, сюжет кору осталыгы беләнме? Идеологиясе, ышерен мәсләге нинди? Кызганычка каршы, татар әдәбиятын хәзер бер көнлек "юрган асты әдәбияты" басып бара, моның югары, нәфис әдәбият белән бернинди катнашы да юк. Шулай ук аерым шәхесләрнең тормыш юлын сөйләп чыгу, аларны роман дип атау да матур әдәбият түгел, бу – публицистика, әдәби портрет. Әмма боларга бәя бирүче юк».

Очрашуда татар-башкорт мөнәсәбәтләре турында да сүзләр булды. «Мин ил һәм дөнья буйлап күп йөрим, бу сорауны бары тик Башкортостанда гына бирәләр, – диде ул соңыннан "Азатлык" хәбәрчесенә. – Беркайда да татар-мари, татар-мордва, яки татар-чуваш мөнәсәбәте турында сораганнары юк. Димәк, сездә проблема бар. Мондагы төп проблема – ул тел һәм тарих буенча. Төп бәхәс шулар буенча бара. Без тарихны, шәхесләрне һәм телне бүлешәбез… Әмма бүген безнең язмышлар ил читендә хәл ителә. Әле дөнья өр-яңадан бүленергә мөмкин. Әзрәк көтик, канлы бәрелешләр нәрсә белән бетәр, шуннан соң һәркем үзенең дәлилләре белән үзенең өлешен алырга тырышачак. Ә тарих кануннар белән хәл ителми, ул милли аңнан тора. Шәхесләр белән дә шулай ук. Башкортларның үз тарихлары, җырлары, менталитеты, холкы бар. Алар – табигатькә якын милләт, аларда халыкчанлык көчле. Ә татарларда интеллект, фәнни як бик көчле. Чөнки бездә дәүләтчелек традицияләре нык. Моны дөнья таный. Башкортларга безнең белән бергәләп, уртак проектларда катнашып, үзләрен күрсәтү яхшы булыр иде. Тик аларның аерым гына дөньяга чыгасы килә, ләкин бу мөмкин түгел. Башкорт зыялыларына бергә, бер-беребезне баетып яшик, дип әйтер идем».

Фәүзия Бәйрәмова очрашуда катнашучыларның күп санлы сорауларына җавап бирде, шигырьләрен укыды, Бөтендөнья татар конгрессының Башкортостандагы вәкиллегенә үзенең китапларын бүләк итте.

Татар һәм башкорт зыялылары белән алдагы очрашу күренекле язучы Мәҗит Гафуриның музей-йортында булды. Очрашу алдыннан Мәҗит

Гафури исемендәге иҗтимагый оешма рәисе Люция Камаева үзләренең нәсел йортында матур, эчтәлекле экскурсия уздырды. Шунысын да әйтергә кирәк, Люция ханым – Мәҗит Гафуриның оныгы Халитның хатыны, нәсел дәвамчысы Мирсәетнең әнисе, шуңа күрә ул бу йорттагы һәр ядкяр турында белеп һәм яратып сөйли. Мәҗит Гафури бу йортта гаиләсе белән 1923–1934 елларда, ягъни, үлгәнче яши, аны язучыга совет хөкүмәте бүләк итеп бирә. Биредә татарның күп танылган шәхесләре, шул исәптән, Һади Такташ, Галимҗан Ибраһимов, Салих Сәйдәшев һәм башкалар кунак була, бу үзе үк махсус өйрәнүне сорый торган зур тема. Шуңа күрә Мәҗит Гафуриның музей-йортында узган сөйләшү дә төбәк тарихын өйрәнүгә, шәхесләр тарихын барлауга багышланды.

Фәүзия Бәйрәмова белән бу очрашуга, нигездә, төбәк тарихын өйрәнүчеләр килгән иде, шуңа күрә ул үзенең чыгышында Себер архивларында алып барган фәнни эзләнүләре турында сөйләде. Биредә дә беренче планга көчләп чукындырулар, сөрген һәм репрессияләр темасы чыкты. Фәүзия Бәйрәмова Себер архивларында, бигрәк тә, Тубыл дәүләт архивында, XVII гасырда көчләп чукындырганнан соң яңадан ислам диненә кайткан татар-башкортларның, кыргыз-кайсакларның хөкем ителү документлары барлыгын әйтте. Ул үзе анда барып, бу исемлекне алып кайткан, башкалар белән дә уртаклаша аласын җиткерде. Шулай ук Екатеринбург архивында, чукынмаган өчен 1739 елда тереләй утта яндырып үтерелгән 60 яшьлек мөселман хатыны Кисәнбикә (Хөснибикә) Байрасова турында документлар саклануын, үзенең аларны өйрәнүен, күчермәләрен алуын сөйләде. Очрашуда тарихи шәхесләр турында да сүз күп булды, Мәҗит Гафури йорт-музееның мөдире, филология фәннәре кандидаты Гадилә Бүләкова тәкъдиме белән, Идел-Уралдагы тарихи шәхесләргә багышлап уртак фәнни конференция уздырырга кирәк, дигән фикергә киленде.

Әйе, Уфа – тарихи шәхесләргә дә, тарихи биналарга да бай шәһәр, милләтнең тамагалы урыны. Ул Казан һәм Ырынбур белән бергә, татар халкының милли-мәдәни, дини вә гыйльми учакларның берсе булган. Шул данлы тарих эзләре буйлап, Фәүзия Бәйрәмова гасырлар ядкяре «Галия» мәдрәсәсендә булды, аның узганы һәм бүгенгесе белән танышты. Заманында Галимҗан Ибраһимов укыган һәм укыткан, Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич, Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш һәм тагы бик күп татар зыялылары белем алган мәдрәсә бит бу! Заманының иң алдынгы карашлы шәхесләрнең берсе Зыя Камали җитәкчелек иткән белем йорты. Әлбәттә, мәдрәсәнең үзен дә, аның җитәкчелеген дә, «Галия»дә белем алган һәм укыткан шәхесләрне дә Сталин чорында юк итәләр. Мәдрәсә бинасы бары тик XXI гасыр башында гына дин әһелләренә кайтарып бирелә һәм яңадан үз бурычын үти. Ул хәзер «Россия ислам университеты» дип ата-

ла, ислам дөньясы университетлары Федерациясендә әгъза булып тора, Мысыр, Иордания, Тунис, Болгар ислам академиясе кебек дәрәҗәле уку йортлары белән хезмәттәшлек итә. Университетның уку-укыту эшләре буенча проректоры Мүрсәл Әхмәтов кунакларны тарихи бина белән таныштырды, киләчәккә планнары белән уртаклашты. Очрашу китаплар бүләк итешү белән тәмамланды.

Әйе, дин галиме Зыя Камали нигез салган «Галия» мәдрәсәсе бүген дә милләткә хезмәт итә, ә менә ул үзе яшәгән йорт бүген ярым җимерек хәлендә. Заманында бөтен урамны биләп торган утар таланган, яндырылган, алма бакчалары юк ителгән, барысы да ташландык хәлгә килгән. Ә бит Зыя Камали инкыйлабка кадәр үз йортына Мәҗит Гафури һәм Сәйфи Кудаш гаиләләрен дә сыендырган булган! Дөрес, Уфада бу тарихи йортны саклап калырга тырышучылар бар, вәгъдәләр дә бирелде, әмма берни үзгәрмәгән булып чыкты. Фәүзия Бәйрәмова фикеренчә, Зыя Камали шәхесе, аның бай мирасы әле тиешенчә өйрәнелмәгән, үз бәясен алмаган, халыкка кайтарылмаган. Һәм моны бары тик милләт үзе генә башкарып чыга ала, чөнки түрәләргә рухи мирас түгел, башкасы кирәк...

Фәүзия Бәйрәмованың Уфадагы очрашуларының таҗы, әлбәттә, Дәрдемәндкә багышланган «Аһ, туган каумем газиз!» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булды. Ул «Нур» татар дәүләт театрында узды, аны «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге оештырган иде. Шунысын да әйтергә кирәк, җитәкчесе галим, Башкорт дәүләт университеты доценты, Башкорт дәүләт опера һәм балет театры солисты Марат Шәрипов булган бу үзәк – максатчан рәвештә, еллар буе Дәрдемәнд иҗатын пропагандалаучы бердәнбер иҗтимагый оешма. Зыялы, затлы милләттәшләребез җыелган бу үзәк даими рәвештә Дәрдемәнд иҗатына багышланган фәнни конференцияләр, әдәби-музыкаль кичәләр, күргәзмәләр, сәнгатьле уку бәйгеләре уздыра, Дәрдемәнд исемендәге татар балалар аланы эшли, сирәк ядкәрләрдән торган Дәрдемәнд музееи оештырганнар.

Кабатланмас талант иясе, шагыйрь, хәйрияче, алтын приискалары хуҗасы, шул алтынга Идел-Уралда йөзләгән мәчет-мәдрәсәләр салдыручы, үз хисабына Ырынбурда «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы чыгаручы, 1921 елда Орскида ачлыктан һәм тифтан үлгән, кабере хәрби завод астында калган Мөхәммәтзакир Рәмиев... Дөнья шигъриятенең таҗы булырлык шигырьләр иҗат иткән Дәрдемәнд... Уфада үткән бу кичә аның тууына 160 ел тулуга багышланган иде, пандемия сәбәпле, халыкны җыеп аны үткәрү хәзер генә мөмкин булды. Кичәдә татар һәм башкорт зыялылары, язучылар, галимнәр, Дәрдемәнд – Закир Рәмиевнең нәсел дәвамчылары, якташлары катнашты. Татарстаннан язучылар Ркаил Зәйдулла, Фәүзия Бәйрәмова, Газинур Морат катнаштылар.

Дәрдемәнд кичәсендә Фәүзия Бәйрәмова тарихчы буларак чыгыш ясады, ул аның иҗаты һәм тормышы бик аз өйрәнелүен, эзләнүләр, нигездә, филологик юнәлештә генә алып барылуын әйтте. Дәрдемәнднең тормыш юлы, тарихчылар тарафыннан, архивларда утырып, өйрәнелмәгән, биографиясенең хронологиясе эшләнмәгән, тормышында ачыкланып бетмәгән, бәхәсле урыннар да шактый. Шуларны ачыклауда Фәүзия Бәйрәмова да үз өлешен керткән. Әйтик, моңа кадәр Җиргән авылында Дәрдемәнднең туган нигезе билгесез иде. Фәүзия Бәйрәмова 2007 елда Германиягә баргач, Мюнхен шәһәрендә яшәүче, тумышы белән Җиргән авылыннан булган Гариф Солтан аңа Рәмиевләр нигезенең планын сызып биргән, аларның ата-бабалары бер урамда, кара-каршы яшәгәннәр. Германиядән кайткач, Фәүзия Бәйрәмова Җиргәнгә барып, шул сызым буенча Дәрдемәнднең нигезен эзләп таба, ул хәзерге Салават Юлаев урамында булып чыга. Язучы бу хакта авыл имамына һәм татар зыялыларына да әйтеп калдыра, моны Уфа сәхнәсеннән дә белдерде.

Бу кичәдә Фәүзия Бәйрәмованың төп чыгышы Дәрдемәнднең Орски шәһәрендәге чоры турында иде. Билгеле булганча, бу калада шагыйрьнең үсмер һәм егет чагы үтә, ул биредә гаилә кора, 1918 елның башында, Ырынбур большевиклар кулына күчкәч, аны ташлап, гаиләсе белән тагы Орскига кайта. Инде мәңгелеккә китү өчен, бөтенләйгә кайткан булып чыга… Дәрдемәнд Орскида өч ел яши, шушы вакыт эчендә аның ишле гаиләсе өстеннән күп фаҗигаләр үтә. Улы Морадны аклар мәҗбүри үз гаскәрләренә алалар, ул шунда тифтан үлә. Улы Җәгъфәрне кызыллар гаскәргә ала, ул сугыштан бер кулсыз кайта. 1919 елның көзендә олы улы Искәндәрнең авырлы хатыны Шәрифзадә тифтан үлә. 1921 елның көзендә (язында, диючеләр дә бар) Дәрдемәнднең олы кызы Өммегөлсем Ырынбурда тифтан үлә. Аны җирләп кайтканда, Дәрдемәнд үзе дә чирләп китә һәм 1921 елның 9 октябрендә вафат була (ачтан яки тифтан, диючеләр бар). Орски янындагы Ильяс авылы зиратына җирләнгән Дәрдемәнд кабере, башкаларныкы белән бергә, сугыш вакытында хәрби завод астында кала һәм юкка чыга...

2013 елның көзендә Орскига барып, анда яшәүче татарлар ярдәмендә, Фәүзия Бәйрәмова Дәрдемәнд үлгән йортны эзләп таба. Ул шәһәрнең иске өлешендә урнашкан, мәчеттән ерак түгел, бер катлы таш йорт, бу йорт Дәрдемәнднең хатынының туганнарыныкы була. Йорт хәзер ташландык хәлдә, чүп-чарга күмелеп ята... Фәүзия Бәйрәмованың сөйләвенчә, бүгенге көндә Орскида Дәрдемәнд истәлегенә бернәрсә дә юк – урам да, истәлек билгесе дә, хәтта шәһәр музеенда бер почмак та... Шул нисбәттән, урындагы татар милли оешмалары менә инде ун елдан артык Орскида Дәрдемәнд истәлегенә стела куярга тели, әмма калада хакимият алышынган саен, эшне яңадан башларга туры килә. Ниһаять, истәлек билгесе ку-

ярга җир биргәннәр, әмма ул шәһәр читендәге мөселман зираты янында һәм Орскида яшәп һәм эшләп киткән өч татар язучысына – Муса Җәлилгә, Дәрдемәндкә, Мирхәйдәр Фәйзигә куелырга тиеш була. Әйтүләре буенча, Дәрдемәндкә иске шәһәрдә дә аерым истәлек билгесе куярга телиләр, әмма хәзергә ул сүздә генә...

Чыгышыннан күренгәнчә, Фәүзия Бәйрәмованы бу истәлек билгесенең урыны да, анда язылган текст та канәгатьләндерми. Зират буендагы буш кырда бу стелаларны беркем сакламаячак һәм аларны вандаллар җимереп китәргә мөмкин. «Дәрдемәндкә истәлек билгесен Җәмигъ мәчете ишегалдына куярга мөмкин, килгән-киткән яныннан дога кылып үтәр иде... Аның җеназасын да шушы мәчет ишегалдында укыганнар бит! Монда ул стела карау-күзәтү астында булыр иде», – диде ул. Стеланың эскизыннан күренгәнчә, анда текст бары тик рус телендә генә һәм Дәрдемәнднең «Мин өмиднең сул кулыннан бер сынык нан алмадым...» шигъри юллары тәрҗемәдә бирелгән. Фәүзия Бәйрәмованың фикеренчә, истәлек билгесенә Дәрдемәнднең татарча башка шигъри юлларын куярга кирәк, һәм ул аны сәхнәдән дә яңгыратты:

«Ни газизрәк – бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!»

*Дәрдемәнд*

Фәүзия Бәйрәмованың әйтүенчә, Дәрдемәндкә истәлек билгесе кую зур чыгымнар сорый, һәм Орски татар милли оешмалары аны үзләре генә ерып чыга алмаячак. Аларга ярдәм кирәк. Бу изге эшкә Бөтендөнья татар конгрессы да, Татарстан Язучылар берлеге дә кушылырга тиеш. Дөресен әйткәндә, алар башлап йөрергә тиеш. Әмма татар Конгрессы да, Язучылар берлеге дә Орскига юлны белми, алар анда бер тапкыр да булмаганнар. Бәлки «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге бу башлангычны үз кулына алып, Орски татарлары белән бергә бу эшне башкарып чыгар? «Хәзер Орскида татарча белгән, Дәрдемәнднең кемлеген белгән соңгы буын татарлар яши. Болар киткәч, андагы татарлар Дәрдемәнднең кем икәнлеген дә белмәячәкләр. Шуңа күрә, Орскида Дәрдемәндкә истәлек билгесен хәзер куеп калырга кирәк. Бу – безнең буын алдында торган олы бурыч, намус эше!» – диде Фәүзия Бәйрәмова үзенең йомгаклау сүзендә.

Уфа белән саубуллашу шәһәрнең мөселман зиратында булды, 26 май көнне биредә күренекле дин галиме Ризаэддин Фәхреддин истәлегенә ме-

мориаль комплекс ачылды. Риза хәзрәт һәм улларының яңартылган кабер ташларын ачу мәрәсимендә мөфтиләр Тәлгать Таҗетдин һәм Камил Сәмигуллин да катнашты, шулай ук биредә Татарстаннан язучылар – Ркаил Зәйдулла, Фәүзия Бәйрәмова һәм Газинур Морат та булды. Кабер ташларын яңарту чыгымнарын «Татнефть» үз өстенә алган. Мәрәсимдә Әлмәттән берләшмәнең рәис урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев һәм Кичүчат авылыннан Ризаэддин Фәхреддин исемендәге музей директоры Диләра Гыймранова да катнашты. Дини мәрәсимдә Риза хәзрәтнең нәсел дәвамчылары да бар иде. Бөтендөнья татар конгрессының Башкортостандагы вәкиллеге оештырган бу чараны «Ихлас» мәчетенең беренче имамы, бүгенге көндә мәхәллә җыены рәисе Мөхәммәт хәзрәт Галләмов алып барды. Коръән уку белән башланган чара әрвахлар рухына дога кылу белән тәмамланды, рухлары шат булсын!

Әмма зиратта, кабер өстендә дә татар-башкорт мәсьәләсе күтәрелмичә калмады, аны дини мәрәсимдә чыгыш ясаган башкорт Конгрессы вәкиле башлады. «Ризаэддин Фәхреддин документларда үзен башкорт дип язган», диде ул, Америка ачкандай. Аның сөйләп бетергәнен тыныч кына тыңлап торган мөфти Тәлгать Таҗетдин: «Тегендә баргач, син татармы, башкортмы, дип сорамаслар, динеңне сорарлар, – дип җавап бирде. – Элек ыру исеме белән йөртмәгәннәр, кешеләр үзләрен мөселман дип атаганнар. Шушыларны бутамыйк!» Мәрәсимгә җыелган халыкта да сорау туды – Ризаэддин Фәхреддиннең чүп баскан, чардуганнары кыйшайган, ташлары җимерелгән кабере өстеннән еллар буе таптап йөргәндә, башкортлар нигә аның «башкортлыгын» искә төшереп, каберен рәткә китермәгәннәр икән соң? Татарстаннан килеп, Риза хәзрәтнең һәм улларының каберен гөлләргә күмгәч, мәрмәргә төргәч, ташларын яңарткач, керү юлларына кадәр салгач – аның «башкортлыгын» искә төшерделәр. Килешмәгәнне эшләделәр, бу кабер өстендә сөйли торган сүз түгел иде…

Фәүзия Бәйрәмованың Уфа сәфәре тәмам, ул инде үзе тарихка кереп калды. Бу очрашуларны оештырган өчен ул «Ихлас» мәчете мәхәллә рәисе Мөхәммәт Галләмовка, «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге рәисе Марат Шәриповка, Бөтендөнья татар конгрессының Башкортостандагы вәкиле, «Ихлас» мәчете имамы Альфред Дәүләтшинга, Мәҗит Гафури исемендәге иҗтимагый оешма җитәкчесе Люция Камаевага, Мәҗит Гафури музей-йорты мөдире Гадилә Бүләковага зур рәхмәтләрен әйтә. «Башкортостан – минем өчен әле ачылмаган йолдыз, планета, – диде ул, хушлашканда. – Биредә зур тарих, милләт тоткан шәхесләр, бөек һәм аянычлы язмышлар... Мондагы һәр шәхес, һәр сала һәм кала турында аерым китаплар язарлык! Һәм язылыр да әле, ин ша Аллаһ! Исән-имин тагы күрешергә насыйп итсен!»

*«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге*

* * *

**Батырша хәзрәтнең туган якларында...**

Билгеле булганча, быел дини һәм милли каһарман Батырша хәзрәтнең – Габдулла Галиевнең тууына – 305, үлеменә 260 ел. Идел Болгарстанында ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгын зурлап билгеләп үткәндә, Идел-Уралда динебез сакланып калсын өчен үзенең гомерен корбан иткән Батырша хәзрәтне искә алмый мөмкин түгел! Шул нисбәттән, Шәһри Болгарда үткән Халыкара фәнни конференциядә дә, 1100 еллык буенча узган милли җыеннарда да аның исеме зурлап искә алынды, рухына дога кылынды. Бу изге эшләрнең төп башлап йөрүчесе һәм Батырша хәзрәт турында халыкка дөреслекне җиткерүче язучы, тарих фәннәре кандидаты, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова булды. Шунысын да әйтергә кирәк, ул аның турында өч фәнни-әдәби-документаль китап язып бастырды – «Батырша җитәкчелегендә милли-азатлык көрәше» (2005), «Баһадиршаһ» (2006) һәм «Батырша явы» (2012) китаплары. Һәм, әлбәттә, язучы һәм тарихчы буларак, Фәүзия Бәйрәмова Батырша хәзрәтнең туган якларында кат-кат була, халык белән очраша, архивларда эшли.

Һәм менә бу көннәрдә, 22–25 июньдә, Фәүзия Бәйрәмова тагы Батырша хәзрәтнең туган якларында – Башкортостан республикасының Иске Балтач районында шушы темага аның якташлары белән очрашулар уздырып кайтты. Бу очрашуларны оештырырга аңа Иске Балтач район үзәгендә Батырша йорт-музеен төзеткән һәм аның директоры булып эшләүче, милли һәм дини каһарманның нәсел дәвамчысы, аның бай китапханәсен саклаучы, Балтачтагы Батырша мәчетенең имам-хатыйбы, мөхтәсиб, Батырша һәм бу төбәктәге татар авыллары, мәчетләр турында 7 китап авторы Рәфис хәзрәт Шәйхәйдәров зур ярдәм итте, аңа Аллаһның рәхмәтләре булсын!

Фәүзия Бәйрәмова белән очрашулар Батыршаның туган авылы – Югары Карыш мәчетендә башланды. Ул җыелган халыкка күренекле якташларының тарихын сөйләде, бу төбәктә ислам диненең сакланып калуында Батырша хәзрәтнең тоткан урыны гаять зур булуын аңлатты. Гомумән, милләтебезнең мең елдан артык ислам динен тотуында, хәтта дәүләтсез калганда да иманны бирмәүләрендә, аерым шәхесләрнең, бигрәк тә Батырша кебек дин әһелләренең, галимнәрнең, милли зыялыларның роле зур булуын әйтте. «Нинди авыр заманнарда да, милләтебез өстендә көчләп чукындыру афәте торганда да, Батырша хәзрәт кебек каһарманнар, үз гомерләрен корбан итеп, динебезне саклап калганнар. Бүген, зурлап, Идел буенда ислам диненең 1100 еллыгын билгеләп үтәбез икән, моның өчен без аларга да бурычлы». Фәүзия Бәйрәмова татар халкының дин һәм ирек өчен гасырларга сузылган тиңсез көрәшен тарихи мисаллар белән, үзе-

нең бу темага язган әсәрләренә дә нигезләп сөйләде. Соңыннан ул мәчеткә Батырша турында язган китапларын бүләк итте.

Бу очрашуда авыл мөселманнары, Иске Балтач авылының Үзәк мәчете имам-хатыйбы Филүс Камалтдинов, Югары Карыш авылы мәчете имамы Фәнәвил Габбасов та катнашты. Алар киләсе елга авылның 330 еллыгы булуын, шул уңайдан, Югары Карышта Батырша хәзрәтнең нигезенә истәлек стеласы кую мәсьәләсен күтәрделәр, аны туристлар маршрутына кертергә теләүләрен әйттеләр, Казаннан ярдәм сорадылар. Шунысын да әйтергә кирәк, Югары Карышта урта мәктәп Батырша исемен йөртә, анда татар теле дә укытыла. Фәүзия Бәйрәмова Батырша хәзрәтнең нигез урынын да барып карады, анда хәзер инде бушлык, билдән үлән үсә... Бирадән ерак түгел, коры елга аша, Батырша хәзрәтнең мәчете һәм мәдрәсәсе булган, шул мәдрәсәдән калган данлыклы китапханә бүген аның нәсел дәвамчысы Рәфис хәзрәттә саклана, ул борынгы китапларны Балтач музеенда күрергә мөмкин.

Фәүзия Бәйрәмова белән очрашу янәшәдәге Чуртанлыкүл авылы мәчетендә дә булды. Бу – атаклы мишәр морзалары Янышевларның туган авылы, бу нәселдән чыккан биш ир туган төбәктәге тагы биш татар авылына нигез салган. Чуртанлыкүл – Рәфис хаҗи Шәйхәйдәровның да туган авылы, ул аның турында китап та язган. Янышевлар заманында мәчетле булган бу авыл озак еллар мәчетсез яши. Рәфис хәзрәтнең зур тырышлыгы белән, бары тик бу елларда гына, элеккеге башлангыч мәктәп бинасы мәчет итеп үзгәртелә, бер бүлмәсендә авылның музеен ачалар. Җомга намазларын Иске Балтачтан килеп Йосып хәзрәт Исмаев укыта. Фәүзия Бәйрәмова биредә дә Батырша хәзрәт турында сөйләде, аның нәсел дәвамчылары Чуртанлыкүлдә дә яшәгәнен әйтте, мәчеткә үзенең тарихи китапларын бүләк итте.

Фәүзия Бәйрәмова белән төп очрашу Иске Балтач район үзәгендәге Җәмигъ мәчеттә, җомга намазыннан соң булды, анда ике мәчетнең дә имам-хатыйплары Рәфис хәзрәт Шәйхәйдәров һәм Филүс хәзрәт Камалтдинов катнашты. Әйткәнебезчә, бу мәчет Батырша исемен йөртә. Башкортостанның төньяк-көнбатышына, Пермь крае чигенә урнашкан бу район, нигездә, татар-мишәрләрдән тора, алар бирегә Казан ханлыгы җимерелгәч, чукындырудан качып киләләр, монда Алтын Урда чорыннан яшәп яткан нугай татарлары янына сыеналар. Шулай ук биредә элек Мещера дип аталган мишәр төбәгеннән күчеп урнашкан затлы морзаларның нәсел дәвамчылары да яши. Күргәнегезчә, аларның бер өлеше, Батырша хәзрәт кебек, динен-милләтен яклап, XVIII гасыр урталарында көчләп чукындыруларга каршы яуга күтәрелә, икенче өлеше, Яныш старшиналар кебек, патша хакимияте белән бергә аларны бастыра. Татарның

зурлыгы да, хурлыгы да янәшә йөри, элек тә шулай булган, кызганычка каршы, хәзер дә шулай...

Фәүзия Бәйрәмова җыелган халык алдында милләтебезнең шушы бөек һәм фаҗигале язмышын сөйләде, чукындыруга каршы күтәрелгән Батырша явының җиңелү сәбәпләрен аңлатты. Батыршаны үзебезнең мишәр-башкорт старшиналары тотып бирәләр, аны Петербургта хөкем итеп, телен, борынын кисеп алалар, маңгаена «вор» дип утлы тамга кыздырып сугалар һәм гомерлеккә Шлиссельбург кальгәсенә ябалар. Шунда дүрт елдан артык газап чигеп, үзен саклаган сакчыларны балта белән бәреп үтереп качарга җыенганда, Батырша хәзрәт үзе дә үлә... Хатынын һәм кызларын чукындырып, монастырьга ябалар, сабый улы Уфадан Мәскәүгә озатканда, юлда катып үлә. Дин-ислам юлында аның бөтен гаиләсе корбан була, әмма милләте исән кала. Батырша күтәрелешеннән һәм Пугачев яуларыннан соң куркуга калган Екатерина II дин иреге турында фәрман чыгарырга мәҗбүр була, көчләп чукындырулар вакытлыча булса да туктап тора. Шушы күтәрелешләр сәбәпле, башкортларга җир хокукы бирелә, кайбер икътисади ташламалар ясала, мөселман татарлар чукынган татарлар өчен налог түләми башлый, керәшеннәр өчен рекрутка солдат бирми, алар булганга карап, башка урынга күчеп китми. Шул чорда Диния нәзарәте төзелә, мәчетләр салына башлый, халык җиңел сулап куя.

Әлбәттә, патшалар алмашыну белән, мөселманнарга караш тагы үзгәрә, көчләп чукындырулар шаукымы XIX гасыр буе дәвам итә, чиркәү кенәгәләренә элек керәшен дип язылган татарларның нәселе бер гасыр буе яңадан исламга кайту өчен көрәшә. Фәүзия Бәйрәмова болар турында да тәфсилләп аңлатты, бигрәк тә, шул хәлләр турында язылган «Гөләйза» романына аерым тукталды, XIX гасырның икенче яртысында чукынмаган өчен Турухан краена сөрелгән татарлар турында, алар эзеннән ерак Себергә барып, эзләнүләр алып баруы турында сөйләде. Дингә каршы көрәшнең хәтта егерменче гасырда да дәвам итүен, советлар иленең атеистик-дәһричелеккә нигезләнүен, атылган, хөкем ителгән, Себергә сөрелгән меңләгән дин әһеленең аянычлы язмышы турында халыкка җиткерде, болар хакында үзенең «Кырык сырт» дип аталган роман язуын әйтте.

«Совет чорында дин тыелган иде, тәмам бетәргә дучар ителгән иде, әмма, Аллаһ рәхмәте белән, динебезне татар халкы үзе саклап калды, – диде ул. – Ул аны күңелендә йөртте, хәтер күзәнәкләрендә саклады, качып булса да, уразасын тотты, намазын укыды... Үзгәртеп кору чоры килү белән, татар тагы күтәрелде, мәчет-мәдрәсәләр төзи башлады, гыйлемгә омтылды, белем алды, китап язды, китап укыды, кыйбласын турылады... Идел-Уралда, котып тарафында ислам дине мең елдан артык сакланып калган икән, иң беренче чиратта без Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт

әйтергә тиешбез, икенче – милләтебезгә, өченчедән, Аллаһ ризалыгы өчен шушы милләткә хезмәт иткән Батырша хәзрәт кебек шәхесләребезгә догада булыйк! Һәм динебезнең, милләт булып яшәүнең кадерен белик, аның өчен әби-бабаларыбыз башларын салганнар бит!»

Батырша мәчете белән Батырша музее янәшә торалар, аның белән Фәүзия Бәйрәмованы музей директоры Рәфис хәзрәт Шәйхәйдәров үзе таныштырды. Дөрес, Фәүзия Бәйрәмованың биредә инде беренче генә тапкыр булуы түгел, аның үзенең дә Батырша турында барлык китаплары һәм хезмәтләре бу музейда бар. Шулай ук монда Ризаэддин Фәхреддиннән башлап, Габделбари Баттал-Таймас, Сәлам Алишев, Җәмит Рәхимов, Мәсгүд Гайнетдинов, Фәйзелхак Ислаев, Вахит Имамов, башкорт язучыларының һәм галимнәренең дә Батырша турында хезмәтләре урын алган. Әмма биредә иң кыйммәтле ядкяр – Батырша китапханәсе. Ул 80 томнан тора, кайбер кульязма китаплар 500–700 битле. Биредә Батырша хәзрәт үлгәч басылып чыккан китаплар да бар, алар аның мәдрәсәсендә тупланган. Мәрҗани институтыннан Казан галимнәре килеп, бу китапларның өлешчә тасвирламасын ясаганнар, әмма күпчелек кульязма китаплар әле өйрәнелмәгән. Шулай ук Уфадан башкорт галимнәре дә килеп, бу китапханәне өйрәнгәннәр, әмма аларның нәтиҗәләре билгеле түгел. Югыйсә, нинди байлык бит, нинди мирас! Тулы бер фәнни институт, еллар буе өйрәнерлек мирас! Кем алыныр бу эшкә? Шунысын да әйтергә кирәк, Батырша китапханәсе – Рәфис хәзрәт Шәйхәйдәровның шәхси милке, ул аны музейга биреп кенә торган. Дәүләт бу бинага хуҗа булса да, Батырша китапларына хуҗа түгел, бәлки, бу яхшыгадыр...

«Тарихта Батыршага хәтле дә, Батыршадан соң да татар-башкорт күтәрелешләре булган, әмма алар аныкы кебек сәяси әһәмияткә ия булмаган. Батырша хәзрәт зур галим, танылган шәхес, бу күтәрелешнең төп идеологы һәм оештыручысы буларак, Коръәнгә таянып, басып алучыларга каршы изге сугыш игълан иткән, Идел-Уралда азатлык байрагын күтәргән. Аның бер кулында каләм, икенче кулында кылыч булган. Аның халыкка мөрәҗәгать итеп язган өндәмәсе һәм кулга алынгач, патшабикәгә язган гарызнамәсе бүгенге көндә Мәскәү-Петербург архивларында саклана һәм фәнни әйләнешкә кертелгән. Шулар буенча XVIII гасырдагы милләт тормышын да, татар язмышын да белергә була, ә ул тоташ фаҗигадән тора! Батырша хәзрәт шуларны язып калдыруы белән дә инде тарихи каһарман! Милләт атасы! Батырша хәзрәт – милләтнең азатлык символы ул! Һәм безнең аны онытырга хакыбыз юк!» – диде Фәүзия Бәйрәмова, музей белән тагы бер тапкыр танышкач.

Аның әйтүе буенча, бүгенге көндә Батырша хәзрәткә, аның хезмәтләренә игътибар җитәрлек түгел. Бары тик Уфада, Әлмәттә һәм Иске Бал-

тачта гына аның исемендә урамнар бар, ә Казанда моны эшләп булмаган. Батырша тарихын һәм мирасын санаулы кешеләр генә өйрәнә, аның буенча фәнни эшләр юк диярлек. Фәүзия Бәйрәмова фикеренчә, моның төп сәбәбе – Батырша хәзрәтнең, үз халкын яклап, империянең татарларны көчләп чукындыру сәясәтенә каршы чыгуы. «Аны шуның өчен кичермиләр, үзен күтәрмиләр, исемен күрсәтмиләр, – диде ул. – 2017 елның 12 апрелендә, Санкт-Петербургта уздырылган “Фәезханов укулары” кысаларында Батырша-Габдулла Галиевнең тууына 300 ел тулуы да билгеләп үтелә. Анда тарихчы Фәйзелхак Ислаев “Батырша һәлак булган Шлиссельбург крепосты диварына аның турында истәлек тактасы куярга кирәк”, дип тәкъдим ясый, әмма бу кайберәүләрдә ризасызлык уята. РПЦга (Урыс православ чиркәве) караган “Всемирный русский народный собор” дип аталган оешма вәкилләре моңа каршы чыгалар, Батырша хәзрәтне “Известный антироссийский националист и религиозный фанатик”, дип атыйлар. Татарның татар булып, үз динендә калырга теләве әнә шулай тамгалана. Хәер, әгәр Идел-Урал мөстәкыйль ил булса, Батырша хәзрәт аның түрендә булыр иде, чөнки ул – милләтнең Азатлык билгесе бит».

*«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге*

* * *

В дни празднования Курбан-байрам в д. Старые Каргалы Тучубаевского сельского поселения прошёл творческий вечер известного композитора и заслуженного деятеля культуры Республики Татарстан Алика Харисовича Лукманова. Мероприятие под названием «Душа, живущая в песнях» собрало всех земляков, односельчан, уважаемых гостей. Концерт проходил на открытом воздухе. Ведущие артисты Татарского театра «Нур» Дамира Саетова и Махмут Фатихов поведали историю возникновения его музыкальных произведений. Зрители стали свидетелями замечательных исполнений песен. Наравне с такими известными артистами, как Фадис Ганиев, Идрис Калимуллин, Флорида Исмагилова, Айрат Халиков, Рамиль Хазиев и другими, выступили на одной сцене и талантливые артисты районного дворца культуры. Алик Харисович был, без сомнения, в центре внимания, поразив всех своей невероятной преданностью истинным человеческим ценностям. После концерта пригласил всех на угощение в честь праздника Курбан-байрам. Хочется пожелать Алику Харисовичу крепкого здоровья и дальнейших творческих успехов! Апофеозом праздника был потрясающий фейерверк.

## Письмо в редакцию

# ТАУ ЯГЫ – ГДЕ ЭТОТ АРЕАЛ И ПОЧЕМУ ОН ТАК НАЗЫВАЕТСЯ?

Эти слова у татар находятся в обиходе ещё со времён образования государства Волжская Булгария. Нам известно, что в Среднем Поволжье по правой стороне реки Волга (Идел) от междуречья Оки и Суры и далее ниже по реке Волга на юго-восток до Жигулёвских гор (*Җигелгән или Жәяүле таулар*) простиралась южная часть огромного государства «Волжская Булгария». Она охватывала территорию восточной части современной Мордовии, правобережную часть Нижегородской области, Чувашскую Республику, Республику Марий Эл, Республику Татарстан, Ульяновскую, Самарскую и часть Оренбургской областей. А на юго-востоке его граница ограничивалась р. Урал (*Җаек*) или Яик. Столицей Волжской Булгарии был Булгар, затем Биляр, располагавшиеся на левой стороне Волги, ниже устье Камы (*Чулман*). По отношению к ранней столице, правобережная сторона р. Волга называлась булгарами-татарами «Тау ягы» (по-русски «Горная сторона»), так как весь правый берег Волги на самом деле является гористой. По правому берегу Волги имеются Васильсурские и Ядринские холмы, Чебоксарские и Козловские возвышенности, Свияжские холмы, Услонские, Камско-Устьинские, Сюкеевские, Тетюшские, Ундорские, Сингилеевские, Симбирские и Жигулёвские горы.

Волжская Булгария в 922 г. приняла мусульманскую религию и стала самой северной исламской страной. Она имела тесные дипломатические, торговые и другие дружественные отношения и связи с Киевской Русью. В 985 г. между Киевской Русью и Волжской Болгарией был заключён договор о дружбе, сотрудничестве и взаимной помощи. В одном из пунктов данного договора записано: «Тогда не будет между нами мира, когда камень станет плавать, а хмель тонуть». Булгары – часть предков современных татар, предлагали князю Киевской Руси Владимиру принять ислам в качестве государственной религии. Но князь после долгих размышлений с учётом склонности славян к всяческим весельям и увлечению винно-водочными напитками, отклонил это предложение и в 988 г. принял крещение и ввел для Киевской Руси православное вероисповедание. Это не мешало нормальным взаимоотношениям между этими двумя государствами.

В 1229/1230 гг. на р. Урал-Яик (Жаек) впервые в истории произошла вооруженная разведочная стычка войск Чингизхана, возвращавшихся из

похода в Афганистан, Персию и на Кавказ с погранвойсками Волжской Булгарии. Монголы при этом убедились в крепкой воинской силе булгарцев и решили лучше подготовиться предстоящей схватке. В 1235 г. войска Бату-хана по пути на Русь решили не оставить сильных булгарцев за своей спиной и покорили всю Волжскую Булгарию.

Потом они присоединили его к Золотой Орде, оставляя возможность за булгарами некоторые права. С ослаблением Киевской Руси и с возникновением Москвы и Московской Руси на базе Тверского и Владимирского княжеств, отношения их с Волжской Булгарией стали обостряться. Московские князья совершали походы на булгарские земли и на их столицу. Во второй половине XIV в. обострилось политическое положение и в самой Золотой Орде. Началась междоусобная борьба за власть. В этот период ещё больше участились походы русских князей на Булгарский улус, что значительно ослаблял экономику этого автономного окраина Золотой Орды. В 1390 г. Тамерлан (Аксак Тимер) сделал ряд военных походов на Золотую Орду, разрушил много городов, в том числе её столицу – г. Сарай.

А в 1392 г. Тамерлан вероятно пошёл войной и на Волжскую Булгарию, сжигая и разоряя по пути деревни и города, убивая всех жителей, не щадя даже женщин, детей и стариков. В этом же году Тамерлан разгромил и сжёг дотла столицу вилайета Волжская Булгария – Булгар, также Биляр и другие города Булгарии. Именно в этот период наши предки, убегая из населённых пунктов Большая Цильна и Большая Задорновка, переправлялись через р. Волга к столице Болгару, а потом, когда появился враг и там, они, убегая, переправлялись через р. Кама со стороны Чистополя в сторону Лаишева, а оттуда опять переправившись через р. Волга, оказались на Горной стороне, но на новых местах проживания.

Таким образом, в 1392–1400 гг. три брата – Хасан, Малик, Курбанбаш или Кырганбаш организовали населённые пункты Хозесаново (*Хужа Хәсән*); Молькеево (*Мәлки-Мәлик*); Старый Курбаши (*Иске Кырбаш – Түбән Кырбаш – Кырганбаш*); часть этой группы во главе с Кырганбашом заселялись, видимо, и по другую сторону р. Кубня и организовали вторую деревню Старый Курбаш (*Иске Кырбаш*). Впоследствии этот Старый Курбаш (*Иске Кырбаш*) стали называть Старая Буа (*Иске Буа*). Видимо туда заселялись в этот период беженцы и из долины р. Аря современного Зеленодольского района (Нурлатская зона), недалеко от деревни Тугаево – Аря. Это подтверждается заключениями обследования Московской генеалогической лаборатории 2018 г.

Далее на разгромленной и сожженной Тамерланом территории в 1437 г. ханом Олы Мухамметом образовалась Казанское ханство, отделив

его из состава Золотой Орды. Казанский хан Олы Мухаммет это он бывший хан Золотой Орды, предательски изгнанный со своего трона Кече Мухамметом, занявшим трон хана Золотой Орды.

При Казанском ханстве территории данного государства по правую сторону Волги (*Идел*) по-прежнему называлась Горной или Нагорной стороной (*Тау ягы*). Это сторона почти не изучена историками, археологами и др. учёными. Здесь проходили сухопутные торговые, дипломатические и военные дороги из Крыма, из Киевской Руси, со Средней Азии, из Персии, Астрахани, Закавказья и Турции в Волжскую Болгарию, а впоследствии и в Казанское ханство. Следует отметить, что здесь проходили военные походы отдельных князей Московской Руси, а также походы войск Степана Разина и Емельяна Пугачева. На этой стороне были многочисленные дозорные посты и городища. Например, на р. Кубня, недалеко от д. Шушерма Кайбицкого района, вблизи слияния р. Кубня со Свиягой, существовало городище «Япанча». Чуть подальше от этого места, в теперешнем Зеленодольском районе РТ, имеется героическая деревня «Утяково», около которой происходили основные сражения сухопутных войск Московской Руси и Казанского ханства.

Считаю необходимым довести до сведения читателей, что казанский хан Олы Мухаммет был грамотным, справедливым и всесторонне развитым руководителем. Он неоднократно спасал московского князя Василия II (Тёмного), несмотря на его предательский поступок по отношению к нему. При нём в ханстве появились русские поселения, в том числе Макарьевский монастырь на Свияге. Молодое Казанское Ханство стало под его руководством сильным государством.

Также нужно отметить, что приток Волги – Свияга, считается единственный рекой в мире, которая рядом и параллельно (недалеко друг от друга) протекают в противоположном к основной реке направлении (Волга протекает с севера на юг, а её приток – Свияга, наоборот, с юга на север, соединяясь у острова Свияжск). Град Свияжск был построен всего лишь за один месяц 1551 г. Для этого стены крепости и православных храмов были заготовлены зимой заранее, скрытно, в Угличских лесах. После пробной сборки материалы были пронумерованы, а потом весной 1551 г. плотами отправлены по Волге вниз к месту их возведения. Территория Свияжска в то время была ещё территорией Казанского ханства. Узнав об этом, джигиты 8 населённых пунктов Горный стороны Казанского ханства, объединившись, совершили нападение на строящуюся крепость Свияжск, но безуспешно. Там вооруженных солдат было предостаточно, а джигитам помощи ждать было неоткуда, так как вся Нагорная сторона к этому времени была уже подконтрольной Московской Руси.

# ТАУ ЯГЫ – ГДЕ ЭТОТ АРЕАЛ И ПОЧЕМУ ОН ТАК НАЗЫВАЕТСЯ?

Весной 1552 г. основные сухопутные силы Московской Руси во главе с Иваном Грозным и касимовским ханом Шах Гали подошли к Алатырю, а оттуда напрямую вышли на р. Якле (под современным Ульяновском). Далее, проходя в день по 25 км, войска дошли до р. Цильна, потом до р. Карла. Там устроили большую трапезу с приглашением представителей местных деревень, в том числе тех, откуда джигиты совершали поход на Свияжск. Царь и его воеводы уговаривали местных жителей присоединиться к ним и идти в поход на Казань. Жителей 8 населённых пунктов (Вожжи, Студенец, Сорок Садак и др.) крестили на месте, то есть по ходу движения и двинулись в путь до р. Була, потом до р. Бия, и далее в лагерь вблизи д. Утяково. Там отдохнув и посовещавшись с прибывшими из Свияжска воеводами, двинулись в град Свияжск. Через несколько дней из Свияжска двинулись на Казань и, соединившись с войсками князей Андрея Курбского, Петра Серебряного и Бахтияра Зизулина и других воевод, окружили город.

В исторических документах и на местах пребывания и движения основных сухопутных войск во главе Иваном Грозным по Горной стороне, остались многочисленные улики и несгладимые следы. На остановках на Цильне и Карле, после гуляния войск и безуспешных уговоров местных жителей присоединиться к походу на Казань, остались крещенными татары 8 деревень. Теперь они опять в исламе. На остановках у р. Була около дд. Чатбашево и Кулькаши, у р. Бия около д. Кабык Купере – Кабы Копры до недавнего времени (1950–1970 гг.) находили отломленные части стрел, саблей, кольчуг и многое другое.

В различных источниках нередко встречаются фамилии и имена воевод – защитников Казани, выходцев из Горной стороны. Например, Япанча, Козья – Би и др. Из них Козья – Би (*Хуҗа – Хәсән – Би*) из Горной стороны Казанского ханства. Такие материалы требуют детального изучения учёными- историками. Имеются мнения, что Козья – Би является основателем деревни Хозесаново (*Хуҗа Хәсән*) Кайбицкого района. А его сын Кугуш и внуки Кугей, Айдар и Ислам являются основателями одноименных деревень Зеленодольского района. Кроме того, бытует мнение о том, что мурза Алиш примерно 1640–1650 гг.р. и его сын Тутай много путешествовали по берегам Свияги, даже по Каме и имели там свои владения, и организовали деревни. Но с началом принудительного крещения их следы внезапно теряются.

С приходом к власти русских царей из династии Романовых после событий 1612 г., то есть после изгнания из Москвы польско-литовских самозванцев, началась новая волна христианизации нерусских народов завоеванных территорий. Для этих целей в граде Свияжск 23 августа

1731 г. открыли «Новокрещенскую канцелярию», которая впоследствии превратилась в «Новокрещенскую контору». Первым его руководителем назначили Алексея Раифского. Новокрещенская контора располагалась в Богородческом монастыре Свияжска. Её работники наделялись неограниченными полномочиями и подчинялись непосредственно Святейшему Синоду. Толмачи с татарского из д. Хозесаново служили у Петра I, а в 1736 г. такие толмачи появляются и в Новокрещенской конторе. От 11 сентября 1740 г. императрица Анна Ионовна подписала Указ «Об отправлении архимандрита с некоторым числом священнослужителей в разные губернии для обучения новокрещеных христианству закону и о преимуществах, новокрещеным дарованиям». В этом Указе были расписаны способы выполнения указов Петра I от 1 сентября 1720 г., 21 августа 1721 г., 17 июня 1722 г. и 3 апреля 1731 г. После этого массовое крещение с особой жёсткостью проводились при руководителе Новокрещенской конторы Луки Канашевиче. Татары называли его «Кара Туном». В этот период принудительного крещения из Горной стороны Казанской губернии многие жители большими группами покидали родные места проживания. Они старались подальше переселиться от места расположения града Свияжска. Покидая свои обжитые места многие из них старались сохранить на новых местах название своих прежних населённых пунктов. Таким образом образовались новые одноимённые населённые пункты, такие как Нурлаты, Кайбицы, Новые Чечкабы, Курбаши, Хозесаново – Кукшем, Суриле, Бикутеево, Тутиял и другие. Эти населённые пункты образовались на территории современного Буинского, Апастовского районов Республики Татарстан, Яльчиковского и Батыревского районов Чувашской Республики. Некоторые принудительно крещеные татары переселялись тайком ещё дальше – на Урал и Зауралье.

Из громадной территории Нагорной стороны Волжской Булгарии и Казанского ханства при организации в 1920 г. ТАССР досталась всего лишь территория от населённого пункта Нижние Вязовые Нурлатской зоны Зеленодольского района и далее по берегу реки Волги до Ульяновской областной границы. Там на сегодняшний день располагаются Нурлатская зона Зеленодольского района, Верхнеуслонский район, Кайбицкий район, Апастовский район, Камско-Устьинский район, Тетюшский район, Буинский район и Дрожжановский район.

Горная сторона Республики Татарстан занимает 10 тыс. км$^2$ земли с населением 265 тыс. человек или 12% от общего числа населения РТ, плотность населения на 1 км$^2$ – 42 человека. Здесь нет крупных городов и индустриальных центров. Городами районного значения являются Буинск, Тетюши и Свияжск. После 1612 г. в современном с. Турминское Хо-

зесановского СП Кайбицкого района организуется усадьба князя Пожарского или, как называли ее позже, дача Пожарского. Когда-то очень давно эта Горная сторона назывались «Жабалстан» (*Җәбәлстан*).

Горная сторона дала стране достаточно много видных личностей – союзных (СССР), федеральных (РФ) и республиканских министров, общественных деятелей, учёных, композиторов, архитекторов, художников, писателей, героев Советского Союза, России, героев Социалистического труда СССР, героев Труда РФ и многих заслуженных людей. Многие из них отражены в недавно построенном и в действующем музее крещенных татар Нагорный стороны Республики Татарстан, расположенном в с. Хозесаново Кайбицкого района РТ. Вот некоторые из них:

***Абрамов Киям Алимбекович***, 07.06.1897 г.р. из д. Старые Тинчали Буинского района, бывший председатель Комитета народных комиссаров СССР (1930–1937);

***Петр Васильевич Дементьев,*** министр авиационной промышленности СССР, 1907 г.р., родился в с. Алешкин-Саплык Дрожжановского района РТ;

***Латиф Хамиди,*** известный композитор, он написал даже Государственный гимн Казахстана, уроженец д. Эбалаково Кайбицкого района;

Капитонов Иван Калистарович, уроженец с. Хозесаново Кайбицкого района РТ. Заслуженный художник Российской Федерации:

***Каюм Насыйри,*** уроженец д. Верхние Ширданы, 1825 г.р., писатель, общественный деятель из Нурлатской зоны Зеленодольского района;

***Зариф Башири,*** уроженец д. Чутеево Кайбицкого района, общественный деятель, писатель, историк;

***Гаврилов Филип Гаврилович,*** уроженец д. Хозесаново Кайбицкого района, 1859 г.р., Старшина Тюмеровской волости (1895–1915 гг.). В 1920 г. организовал Молькеевскую волость отделив 7 населённых пунктов крещенных татар из Чувашии и присоединив их в состав ТАССР;

***Мухамет Латиф Алкин,*** уроженец д. Старая Чечкабы Кайбицкого района, общественный и религиозный деятель, борец-защитник ислама.

Здесь родина знаменитого конокрада ***Шакура***, Министра строительства Республики Узбекистан ***Г.С. Сабирова***, рядом родина Министра культуры Республики Коми ***Н.А. Бобровой***, доктора биологических наук, работающего в Санкт-Петербурге ***И.Н. Коновалова***;

Это родина профессоров ***Р.А. Гарафутдинова***, ***Н.К. Андреева***, доктора филологических наук ***Г. Тагирзянова***;

Артистов ***Фахри Насретдинова, Бану Валеевой, Рафаэля Ильясова, Фердинанта Саляхова, Лены Бичариной, Лидии Ахметовой (Ямщиковой), Бухарского-Галимова***;

Композиторов ***Сары Садыковой, В.А. Мироваева, Галии Кайбицкой***, заслуженных писателей ***Рената Хариса*** и ***Шавката Галиева***.

В Кайбицком районе Горной стороны РТ недавно строители автодороги Москва-Пекин вблизи населенных пунктов Акхужа и Меми случайно раскопали ранее неизвестное древнее кладбище. А совсем недавно второе ранее неизвестное кладбище. Этим я еще раз хочу подчеркнуть, что эта сторона республики малоизучена, необходимо это сделать сейчас, пока есть для этого соответствующие условия.

А исторический пласт здесь очень богатый. Теперь для изучения этого пласта имеется определённая база. В с. Хозесаново действует музей крещеных татар Нагорной стороны РТ. Укомплектовав этот музей соответствующими специалистами и придав ему государственный статус как филиала или же отдела Национального музея Республики Татарстан, можно использовать его как стартовую площадку для историков, археологов и других учёных по глубокому изучению этого края РТ. Для этих целей данный музей в д. Хозесаново Кайбицкого района имеет все условия.

Уверен, что и Минкультуры РТ с уважением прислушается к ходатайству 36 видных ученых и других заслуженных работников РТ, подписавших два обращения Президенту РТ по статусу Музея крещёных татар в д. Хозесаново Кайбицкого района и займёт положительную позицию по данному вопросу.

*В.В. Данилов, заслуженный экономист РТ*

## ОТЗЫВ О ПРОВЕДЕННЫХ МЕРОПРИЯТИЯХ

26 мая 2022 г. в Тобольске прошёл «круглый стол» «Языковая ситуация у сибирских татар: проблемы и решения», организатор ТООО «НКА Сибирских татар». 28 мая 2022 г. в Тюмени прошла XXV Всероссийская научно-практическая конференция «Сулеймановские чтения-2022» по теме «Развитие сибирскотатарской культуры, языка и традиций». Организатор – МОО НКАТГТ «Себер Татарлар».

По поводу данных мероприятий можно резюмировать только одно – все они занимаются разложением татарской идентичности, выдавая желаемое за действительное, плохо знают историю татарского народа, пытаются манипулировать сознанием и не обладают необходимыми знаниями в области истории местных татар, выдавая диалект за отдельный язык, забывая, что их предки в Казани, в Крыму и Сибири общались на одном языке! Во время глобализации и при уменьшении носителей языка все свои силы направляют на деструктивную борьбу с единым литературным татарским языком.

Страшно слышать от людей, имеющих ученые степени, что татары Сибири отдельный народ. Это говорит об их низком профессиональном уровне и незнании истории и лингвистики или политической продажности и следовании за другими нашими братьями тюрками, которые хотят вбить клин в татарский народ! Первые идут за радикально настроенными башкирами и ногайцами, которые хотят включить татар Сибири в свой ареал. Вторые радостно хлопают высказываниям братьев казахов, которые ведут в последнее время экспансию на историю татар Сибирского ханства, через кереитов фактически предъявляя РФ территориальные притязания и пытаются включить Сибирь в историю Казахского ханства через династию Тайбугидов. При этом, на оба мероприятия были направлены письма о поддержке от имени ВКТ.

Народ может сохраниться только тогда, когда у него общий язык, культура и история. Если мы посмотрим на русский народ, который за основу своего литературного языка взял один из диалектов восточнославянского наречия, наиболее распространённого на территории России, то мы увидим, что единый литературный язык помогает сохранять и объединять соответствующий этнос. Хочу закончить одной пословицей: «Аерылганны аю ашар, Бүленгәнне бүре ашар».

*Князь Данияр Ахметов, Тюмень*

## Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр

## Информация о краеведческих трудах. Рецензии

### ИЗДАНА НОВАЯ КНИГА

**Белов С.Г., Хамидуллин Б.Л. Волжские булгары. Путь к исламу: этнополитическая и культурно-конфессиональная история праболгар с древнейших времен до официального принятия булгарами ислама. – Казань: Институт Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2022. – 136 с.**




Книга Сергея Белова и Булата Хамидуллина посвящена 1400-летию Мединской общины – первого государственного образования мусульман, созданного в 622 г. пророком Мухаммадом после переселения из Мекки в Медину, и 1100-летию официального принятия ислама народами Волжской Булгарии. В ней, на основе сведений исторических источников и современных научных исследований, в научно-популярной форме показана история возникновения и распространения ислама, основных достижений средневековой исламской цивилизации, история праболгар Центральной Азии и Северного Кавказа, Великой Болгарии хана Кубрата в Северном Причерноморье, история расселения булгар в Среднем Поволжье и принятия булгарами ислама, как государственной религии Волжской Булгарии, оказавшей существенное влияние на её дальнейшее цивилизационное развитие. Книга, несомненно, вносит свой весомый вклад в изучение и популяризацию историко-культурного наследия народов Среднего Поволжья.

*Л.И. Алмазова*

## ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ҺӘМ ФАЙДАЛЫ ФИКЕРЛӘР

### *А.Г. Хәйретдиновның «“Әт-Тәсһил ад-даруртри ли мәсәил әл-Кудури”: фәнни мөхәррир тәҗрибәсеннән» исемле мәкаләсенә рецензия*

Узган гасырның соңгы дистәеллыгыннан башлап татар иҗтимагый тормышы дини яңарыш кичерә. Табигый ки, әлеге процессның аерылгысыз бер өлеше булып халкыбызга дини әдәбият үрнәкләренең кайтуы тора. Бу күренешнең уңай яклары да, тискәре яклары да бар. Мәсәлән, илебездә яши торган татар мөселман җәмәгатьчелеге борынгыдан башлап Хәнәфи мәзһәбендәге ислам динен тота иде. Әмма совет дәверендә дини традицияләрнең өзелүе нәтиҗәсендә яңарыш җилләре белән бергә халык арасына ят һәм хәтта куркыныч булган дини әдәбият үтеп керә башлады. Нәтиҗәдә җәмәгатьчелеккә күңелсез вакыйгалар кичерергә дә туры килде.

Мондый башбаштаклыкка чик кую йөзеннән, Россия Федерациясе җитәкчелеге илдә яшәүче мөселман халыкларына борынгыдан хас булган традицион дини карашларын кайтарту һәм тарату буенча 2007 елда махсус программа кабул итте. Анда Русиядә яши торган мөселманнарга дини белем бирү мәсьәләләрен тәртипкә китерү һәм камилләштерү чаралары белән бергә дини әдәбият, махсус уку-укыту методикалары һәм башка уку-укыту чараларын булдыру мәсьәләләре дә каралган иде.

Нәтиҗәдә, 2007 елдан башлап хәзерге вакытка кадәр Русия мөселманнары тиешле дини әдәбият белән тәэмин ителеп килә. А. Хәйретдиновның мәкаләсендә искә алынган «Әт-Тәсһил ад-даруори ли мәсәил әл-Кудури» («Кодури мәсьәләләренә зарури булган җиңеләйтү»), дип аталган китап та шундый әдәбият рәтенә керә. Китапны язган һиндыстанлы дин галиме Мәүләна Мөхәммәд Гашыйк Илаһи әл-Барный, үзе дә Хәнәфи мәзһәбен тотучы буларак, китабын татарларга борынгыдан мәгълүм булган һәм танылган Фәкыйһ әл-Кодуринең әсәренә аңлатмалар шәкелендә язган.

Бу йөздән әлеге китап, кайбер архаизмнарны аерып алып укучыларны аларга караган махсус аңлатмалар белән таныштыру шарты үтәлгәндә, бүгенге көн мөселманнарының дини ихтыяҗларының байтагын тәэмин итә ала торган әсәр булып тора. «Мохтасар әл-Кодури»не үзен алганда, бу әсәр борынгыдан башлап бүгенгәчә Хәнәфи мәзһәбендәге мөселманнар өчен иң мөһимнәрдән һәм кирәклеләрдән саналган китапларның берсе булып тора. Ул үз вакытында татар мәдрәсәләрендә фикъһы буенча төп дәреслек булганга күрә, барлык татар дин галимнәренә дә таныш дәреслек булган. Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Г. Утыз-Имәниләр кебек га-

лимнәребез һәммәсе дә бу китапны белгәннәр, аның буенча фикъһыны өйрәнгән булганнар.

А. Хәйретдинов – әл-Барныйның урыс теленнән татар теленә тәрҗемә ителгән «Мохтасар әл-Кодури»га язган шәрехнамәсен фәнни мөхәррир буларак тикшереп чыккан белгеч. Аның әлеге китап белән танышкан дәверендә юлыккан мәсьәләләр белән уртаклашуы аерым әһәмияткә ия, чөнки үзенең язмасында ул кызыксынучы укучыга байтак кына файдалы мәгълүмат та бирә. Мәсәлән, фикъһы фәненең нәрсә белән шөгыльләнүен аңлата, әл-Кодури, әл-Барный турында мәгълүмат бирә. Мондый өстәмә информация бирелүе, укучы өчен китапта әйтелгәннәрне аңлауны күпкә җиңеләйтә.

Әмма А. Хәйретдинов кирәкле дип санаган өстәмә информация бирү белән генә чикләнми. Аның әлеге хезмәткә карата тәнкыйди караштa булуы аерым игътибарга лаек. Мәсәлән, ул китапның җитешсезлекләрен дә күрсәтә, әлеге җитешсезлекләрне шактый кискен сурәттә тәнкыйть утына да тота. Әйтик, А. Хәйретдинов мәшһүр галим Әбу Хәнифә белән аның шәкертләре арасында булган бәхәсле каршылыкларга игътибарны юнәлтә. Әлеге алым борынгы заманда иҗат иткән дин галимнәренең карашларын уйламастан кабул итәргә һәм гамәлгә ашырырга күнеккән замандашларыбыз өчен аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итсә дә, аның файдасын танырга кирәк. Чөнки борынгы хөкемнәрне изгеләштерү, тәкълид кыйлу, ягъни, акыл иләгеннән үткәрмичә кабул итү, үз вакытында мөселман дөньясын торгынлыкка һәм деградациягә дучар иткән бер чир булган бит.

А. Хәйретдинов исә укучыларны шул чирне яңадан йоктырудан кисәтә, дип уйлыйбыз. Бу йөздән, А. Хәйретдиновның мәкаләсе яңа дини китап белән таныштыруга гына багышланмыйча, көн кадагына суга, киләчәктә татарларда исламның нинди булачагы турында борчулы сораулар уята торган, җитди мәсьәләләрне дә күтәрә.

Әлеге мәкаләнең татар телендә язылган булуы да, һичшиксез, аның уңышлы үзенчәлеге булып тора, чөнки ул татар теленең фән даирәсендә кулланылышына, алга таба үсешенә, терминологик яктан баюына хезмәт итә.

Мәкалә үзенең актуальлеге, куелган мәсьәләләрнең җитдилеге сәбәпле, әлбәттә, басылып чыгарга лаек язма булып тора.

Илдус кызы Ләйлә Алмазова, фәлсәфә фәннәре кандидаты,
КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты доценты

## ПӘРӘМӘЧ



«Сандыгым»ның иң түрендә – чын әләзәнчә пәрәмәч пешерү рецептлары саклана. Мин аларны Пенза якларында комплекслы экспедициядә йөргән чакта татар дөньясының иң танылган авылларында – өч Әләзәндә дә булып, анда гомер итүче хуҗабикәләрдән язып алган идем. Шуны да искәртеп үтәм, Пенза якларында кадерле кунакларны алаша (ат) итеннән пешерелгән пәрәмәч белән сыйлау – табигый күренеш.

### Югары Әләзән пәрәмәче

Бу рецептны Равилә Мөкатдәс кызы Кадеркаевадан (1970 елда туган) язып алдым. Равилә ханым авыл Мәдәният йорты сәхнәсендә, совет-студент елларыннан ук күбебезгә таныш гап-гади электр плитасында гаҗәп тәмле пәрәмәч пешереп безне сыйлады.

***Камыр:***

Камырын чүпрәгә изәбез. Йомшак булсын өчен 2–3 кашык кенәләнгич (көнбагыш) мае салып, озаклап басарга кирәк. Камырга үсемлек мае урынына алаша маен эретеп салгач та яхшы була.

***Эчлек:***

1 кг ат яисә сыер итенә 3–4 баш (күбрәк тә ярый) эре суган алабыз, мясорубкадан чыгарабыз. Тагын бер кат тарттырабыз. Ит майлы булсын. Борыч белән тозны тәменә карап салабыз, әйбәтләп бутыйбыз.

***Пешерү:***

Камырны түгәрәк кисәкләр итеп бүлгәлибез, аннары бераз җәеп, 1–2 кашык ит салып өстен матур итеп бөрәбез. Бераз тасмал (*аш сөлгесе-ред.*) белән каплап торгач, майлаган табага салып пешерәбез. Электр плиткасында яки духовкада якынча ярты сәгать пешерергә кирәк.

* * *

**Урта Әләзән пәрәмәче**

Аны бу эшнең профессионалы – мәктәп ашханәсендә ашчы булып эшләүче Румия Таһир кызы Тюгаева (1963 елда туган) тәкъдим итә. «Пәрәмәч пешерүнең һәркемдә үзе генә белгән серләре бар, бөтен кеше аларны ачып бетерми», – ди Румия ханым.

«Безнең 5 кешелек семья, бабаем белән үзем дә өч оныкам безгә җәй буена килә. Үзебез өчен генә пешергәндә продукталарны түбәндәгечә алам».

***Камыр:***

1 литр сөт, ярты литр су, ярты стакан кенәләнгич (көнбагыш) мае, бераз тоз, 1 кашык пәсук (шикәр комы), 1 пачка дража (чүпрә). Онны (күпме керә шуның хәтле) әкренләп салам да камыр басам. Онны артык күп салмаска, камыр каты булмасын. Камырыбыз стенага сылый торган раствор (штукатурка) куелыгында гына булырга тиеш, баса-баса үзләнә ул. Озак басарга кирәк, камыр кулдан үзе кубып төшәргә тиеш.

***Эчлек:***

5 кешегә 1,5 кило алаша ите кирәк. Майлырагын алып мясорубкадан тарттырырга. 5 суганны пычак белән вак-вак кына тапап, аерым табакка салып борыч, тоз белән әйбәтләп изәргә. Тарттырган суганның тәме калмый, ә болай пәрәмәч бик тәмле була. Суганны 6–7 баш итеп тә алырга була. Оныклар өчен суганны мясорубкадан тарттырып кушам, чөнки оланнар авызда суган кисәкләрен тоярга яратмый.

Суганлы, тозлы-борычлы фаршны 1 сәгатькә суыткычта тотарга, шулай эшләгәч тагын да тәмлерәк була.

Сусыл булсын өчен мин фаршка 0,5 стакан су да кушам.

***Пешерү:***

Камыр калыккач, кисәкләргә бүлгәләргә. Җәелгән камыр өстенә 1–2 кашык эчлекне салып, кырыйларын өскә күтәреп бөгәргә.

Пәрәмәчне 220 градуслы духовкада 20 минут пешерергә. Кемнең нинди духовка инде, бераз озаграк та була.

«Бу камырны мин духовка өчен яздырдым. Май эчендә газ өстендә пешерсәгез, камырга үсемлек мае кимрәк салына», – ди хуҗабикә.

* * *

**Түбән Әләзән пәрәмәче**

Әлеге рецептны Наҗия Җамал кызы Кержневадан язып алдым (1960 елда туган). Сыналган ысул бу: пәрәмәчнең тәмлелегенә гарантия бар. Чөнки Наҗия ханым әлеге пәрәмәчне Түбән Әләзән авылы Мәдәният йортында ук – «Каз өмәсе» фольклор күренешен күрсәткәннән соң пешереп, безгә авыз иттерде. Электр мичендә пешкән пәрәмәч телне йотарлык иде!

***Камыр:***

1 литр сөт, 1 стакан су, 1 кашык үсемлек мае, 2 йомырка, тәменчә тоз.

Чүпрәле камыр басабыз, кулга ябышмаслык булсын. Җылы урынга куеп кабартабыз.

***Эчлек:***

1 кг ит (алаша да, сыер терлегенеке дә булырга мөмкин), 4 баш суган.

Ит белән суганны бергә мясорубкадан тарттырып, фарш ясарга кирәк. Ит майлы булырга тиеш. Тик безнең авыл пәрәмәченең өстәмә бер «сере» бар. Без иткә каз мае өстибез! Шулай ук кемгә күпме ошый – кара борыч, тоз кушып уабыз. Пәрәмәч тәмлерәк булсын, дисәгез, тәмләткечләрне бутап кына калмагыз, ит белән бергә уыгыз.

***Пешерү:***

Шарчык формасындагы камыр кисәкләрен җәеп, уртасына берәр кашык ит куябыз. Бөкләп, бераз ял иттергәч, пешерергә куябыз. Пәрәмәчне бездә май эчендә түгел, мичтә пешерәләр.

*Пәрәмәч пешерү ысуллары белән Рузия Сафиуллина таныштырды,*

*Алсу Борһанова фотосы*

* * *

## КОШ ТЕЛЕ

Взбить 1 яйцо + 2 желтка. Добавить 1 ст. л сметаны, 1 ч. л. сахара, щепотку соли. Всю массу хорошо перемешать до растворения сахара и соли. Затем 250–300 г муки просеиваем и добавляем в массу. Тесто должно получиться крутым.

Раскатать на сочни толщиной 3 мл. Далее нарезать острым (узорным) ножом полосы. Готовые полосы нарезать по диагонали ромбиками с зубчатыми краями.

Обжарить на топлёном или растительном масле (во фритюре). Ромбы должны быть слегка золотистого цвета. Подавать посыпанными сахарной пудрой.



*Гульнафис Валеева*

**Юбилярлар турында сүз**

**Слово о юбилярах**

## РӘМЗИ ВӘЛИЕВНЕҢ ТОРМЫШ ЮЛЫННАН КАЙБЕР СӘХИФӘЛӘР



2022 елның 7 маенда тарихчы, тарих фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры Рәмзи Кәлимулла улы Вәлиевкә 85 яшь тулды. Юбилее алдыннан Рәмзи Кәлимуллович белән озаклап сөйләшеп утыру насыйп булды. Күптән күрешмәгәнлектән, бик тансык очрашу иде ул. Башта пандемия, аннары шуңа бәйле чикләүләр арага керде. Ул чорларда телефоннан гына хәбәрләшеп тордык. Бу очрашуыбызда исә остазның яшәеш турында кытай философы Конфуций гыйбарәләрен искә алып, гыйбрәт итебрәк әйткән киңәшләре уйга салды.

Рәмзи Кәлимуллович Вәлиев узган юлның зур өлеше ул студент булып килеп кереп, профессорга кадәр күтәрелгән Казан университеты белән бәйле. Тормышының иң катлаулы чоры, мөгаен, СССР җимерелеп, дөньяның сәяси картасында яңа Россия пәйда булган 1990-нчы елларга туры киләдер. Яңа, көнбатышка йөз тоткан иҗтимагый-сәяси кыйммәтләрнең актив үтеп керүе ул заманда күпләрнең планнарын гына түгел, язмышларын да пыран-заран китерде. Шәрык акыл иясе (Конфуций) төгәл искәрткән: «Күчешләр чорында яшәүдән сакласыннар». Казан дәүләт университетының тарих факультеты деканы Р.К. Вәлиев тә, күпчелек галим-галәмә кебек, шөбһәле билгесезлек халәтен кичергән: фән яшәрме, үзебез дә калырбызмы? Җитмәсә, гаммәви мәгълүмат чаралары утка май өстәп тора: мондый вазгыятьтә тарихчылар кирәкме һәм алар нилектән шулкадәр күп? 1981-нче елдан бирле фән буенча декан урынбасары вазифасын башкарып килгән Рәмзи ага 1995 нче елда декан вазифасына игълан ителгән вакантлы урын өчен конкурста катнаша һәм, яңа идеяләр белән тулы оригиналь программа тәкъдим итеп, көндәшләрен җиңүгә ирешә. Әмма эшне башлау һич тә җиңелдән булмый, бу вазифаны 16 ел

буена башкарып тәҗрибә туплаган, факультет коллективында зур абруй казанган дусты һәм хезмәттәше Индус Рәззак улы Таһировны алыштыру ничек ансат булсын? Өстәвенә, илдәге икътисади вазгыятьнең кискенләшүе сәбәпле югары уку йортлары системасын финанслау кими, болай да мулдан булмаган хезмәт хакын бирү тоткарлана, башка тискәре факторлар да туып кына тора. Әмма тарих факультеты коллективы алдында өмет уты кабына – яшәячәкбез!

Коллектив белән яңа вазифада очрашу вакытында аңа, табигый ки, төп сорау бирелә: «Яңа иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә Сез Татарстан тарих фәненең перспективаларын нинди сурәттә күрәсез?» Рәмзи Кәлимуллович ул мәлдә үтә саклык белән, әмма шул ук вакытта җитлеккән галим һәм практик буларак анык итеп җавап бирә. Еллар уза, икеләнүләр ныклы ышаныч белән алышына, әмма аның кыюлыгы һәрвакыт факультет коллективының фәнни потенциалын бәяләүгә нигезләнә. Үзенең бер чыгышында тарих факультетының беренче деканы, профессор һәм ТФА академигы И.Р. Таһиров түбәндәге сүзләрне әйтә: «Рәмзи Кәлимулловичка тарих факультеты белән Казан университеты өчен иң кыен вакытта җитәкчелек итәргә туры килде. Моның өчен ныклы характерга ия булу гына җитми, куелган максат хакына һич соңармый, нәкъ вакытында туплана белү зарур иде. Факультет җитәкчедән уңды. Вәлиев – белеме буенча тарихчы, холкы белән дипломат, төп эш хакына вак-төякне икенче чиратка куя белү сәләтенә ия зат. Ул коллективны саклап калу, аны яшь кадрлар белән баету белән бергә, яңа юнәлешләр дә булдырды».

Тарих факультетын җитәкләргә алынганда ук Р.К. Вәлиев провинциализмнан арыну, тупланган фәнни потенциалны саклау һәм ныгыту, тиз арада булмаса да, төбәк дәрәҗәсендә генә калмыйча, бөтенроссия масштабындагы фәнни-тикшеренү һәм белем бирү үзәге булып җитешү зарурлыгын күздә тота. Шуңа күрә декан вазифасындагы беренче адымнарыннан ук Татарстанның гына түгел, Идел-Урал төбәгенең тарихын һәм бүгенгесен өйрәнүгә дә комплекслы, күпьяклы якын килү бурычын куя. Әлеге максат белән яңа фәнни юнәлешләр булдырыла, шул ук вакытта университетның тарихи эзләнүләрдәге лидерлык позициясе дә саклана. Рәмзи Кәлимуллович сынауларда сынмаган һәм яңа фәнни юнәлешләр белән киңәя барган факультет өчен биниһая тырышлык куя. Катлаулы шартларда факультет эшчәнлеген нәтиҗәле итеп оештыруга ирешә. Боларга ул диалогка һәрвакыт әзер булуы, оппонент фикеренә карата тирән кызыксынучанлыгы, ышандыра алу сәләте, карар кабул итүдә ныклыгы бәрабәренә ирешә.

Рәмзи Кәлимулловичның деканлыгы чорында тарих факультетының илдәге башка югары уку йортлары, алай гына да түгел, кайбер чит

ил университетлары белән багланышлар мәсьәләсендә мөмкинлекләре киңәя, матди-техник базасы һәм укыту-методик базасы ныгый. Яңа – Татарстан тарихы кафедрасы ачыла, музеология буенча белгечләр әзерләү башлана. Фән дөньясы өчен гадәти күренеш – коллективта кайбер фикер каршылыклары хөкем сөрүгә карамастан, тарих факультетындагы фәнни хезмәткәрләр-укытучылар составының көйле һәм нәтиҗәле эшчәнлеге тәэмин ителә. Шунысын шикләнмичә әйтергә мөмкин: Рәмзи ага үз гамәлләренең барысын мәҗбүрият белән түгел, йөрәге кушканга кыла, коллегаларының фәнни һәм карьерага кагылышлы амбицияләрен чын-чынлап аңлап, аларны хәл итәргә омтылып яши, шуның белән факультетта эшлекле, дустанә һәм тотрыклы иҗади вазгыять тууга этәргеч бирә. Остазыбыз үзе дә, Конфуций әйткәнчә, «кешенең иртән эшкә барасы килеп, кичен өенә кайтасы килеп торса, бәхет өчен шул җитә», дип яши. Табигать Рәмзи Кәлимулловичны тормыш фәлсәфәсен гамәлдә куллана белү, стратегик фикерләү һәм стандарт булмаган карарлар кабул итү сәләте белән бүләкләгән. Безне, аның шәкертләрен, тагын остазыбызның фәнни дискуссияләр белән оста «дирижёрлык итүе» һәм үзенең дә аларга актив катнашып китүе сокландыра һәм гаҗәпләндерә иде.

Фәнгә кагылышлы мәсьәләләрдә җитди һәм җаваплы профессор тормышта бетмәс-төкәнмәс юмор иясе булды: әле генә сөйләмен руслар арасында тәгәрәп үскәннәргә генә хас гыйбарәләр кушып «үрсә», ул да булмый, фикерен татарның тормыш фәлсәфәсен чагылдырган бизәкләр белән баетып җибәрә. Кайбер фәнни җитәкчеләрдән аермалы буларак, ул үз аспирантлары һәм докторантлары алдына беркайчан да шикле шартлар куймый, бирелеп һәм мавыгып эзләнүчеләргә кызганмыйча булыша, кулыннан килгән ярдәмне күрсәтә. Безнең белән эшләү, әлбәттә, аңа җиңел түгел иде, бу эш мәшәкать-кыенлыклар өсти торган, әмма без аңардан һәрвакыт аңлау һәм яклау табып килдек.

Юбилеен билгеләп үтүче остазыбызга карата мөнәсәбәтебездә иң мөһиме – җитәкче һәм кеше буларак аңа булган хөрмәтебез һәм ышануыбыз. Р.К. Вәлиев әзерләгән 20 фән докторы һәм кандидаты – төрле елларда аның шәкертләре булган һәммәбез дә, тарих фәннәре докторы, Ульяновск педагогика университеты профессоры, полковник И.А.Чуканов әйткәннәрне нәкъ үзенеке итеп кабатлый ала: «Хөрмәтле Рәмзи Кәлимуллович! Фәнни даирәләрдә Сезнең яңага булган тоемлауыгыз һәм шул ук кимәлдә коллегаларыгыз, аспирантлар һәм студентлар белән арадашлык итү сәләтегез яхшы билгеле. Сезнең тормыш юлыгыз – тарих фәненә фидакярләрчә хезмәт итү, ә инде казанышларыгызның Татарстан һәм Россия дәрәҗәсендә танылуы – күпьеллык киеренке хезмәтегез өчен бирелгән төп бүләк. Кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен әзерләү һәм

яклау вакытында миңа күрсәткән ярдәмегез, кыйммәтле киңәшләрегез, аталарча кайгыртучан мөнәсәбәтегез өчен зур рәхмәт!»

Шәхсән үзем Рәмзи аганы инде 40 елдан бирле беләм. Студентларның бәяләү шкаласы буенча ул шунда ук «адекват» укытучылар рәтенә куелды. Безнең яшьлектә андый бәягә заман белән бер аяктан атлаучы һәм үз белеме багажын яшь буынга тапшыру теләге белән янганнар лаек була иде. Рәмзи Кәлимуллович аспирантлар өчен һәрьяклап үрнәк булып торды: ул безне фәнни эш алып бару тәртибенә, кешеләр белән аралашырга, тормышта үзең сайлаганны яратырга өйрәтте, чын галим һәм укытучы булу серләренә төшендерде. Тормышыбызда менә шундый гади, ачык, яхшы күңелле, зирәк акыллы кеше очрау, аның барыр юлыбызны билгеләүдә катнашуы, мөгаен, язмыш бүләге булгандыр. Галимнәрдән дә, иҗади һөнәр ияләреннән дә Рәмзи аганың туктаусыз үзгәреш кичереп торучы иҗтимагый-сәяси чынбарлык шартларында заман таләп иткән фәнни юнәлешләр сайлавы турындагы фикерләр ишетергә туры килгәне бар. Үткер һәм сыгылмалы акыл белән кылынган гамәлнең нәтиҗәсе генә шулай төрле яшьтәге һәм төрле социаль статустагы кешеләр тарафыннан уртак хуплау белән бәяләнә аладыр.

Объектив күзлектән караганда, бу галимнең фәнни юлын да күрсәтә. Һәр кеше дә үз эзләнүләренең тематикасын шул дәрәҗәдә кискен үзгәртергә кыймас: 1917-нче елгы революцион хәрәкәт, «Болак арты республикасы», аннары 1920–1930-нчы еллардагы сәяси репрессияләр һәм зыялылар язмышы, милли төзелеш һәм, ниһаять, Кече Ватан тарихы. Әлеге юнәлешләрнең һәркайсында аның саллы фәнни өлеше бар. Татарстанның беренче суверенитеты турындагы идея дә аныкы! Шунысын танымый булмый, аның суверенитетлар турындагы идеясен һәркем дәррәү генә кабул итми. Ул үзе бу турыда менә ниләр яза: «2013 елда минем беренче суверенитет турындагы мәкаләм басылып чыккач, КФУ доценты, тарихчы Җәүдәт Миңнуллин: “Ачыш бит бу, Рәмзи Кәлимович!” – диде. Мин үзем дә шулай уйлый идем, тик бу турыда кычкырып әйтергә җөрьәт итмәдем, ә ул: “Рәхмәт!” – диде. Бәлки, кемгәдер мин мактанам да кебек тоелыр. Юк, бу мәгълүматның һәр укучыга барып җитүе кыйммәт».

Татарстан тарихы Рәмзи Кәлимуллович өчен һәрвакыт төп юнәлеш булып калды. Ул ясаган ачышлар иң яңа Татарстан тарихын яңа материаллар белән баету мөмкинлеге бирде. Мине юбилярыбызның эшкә сәләтлелеге, фәндәге юлының озын һәм киң булуы сокландыра һәм сөендерә. Рәмзи ага 300дән артык фәнни һәм фәнни-популяр хезмәт, шул исәптән 10 фундаменталь монография авторы. Соңгы ике дистә ел эчендә генә ул Татарстанның иҗтимагый-сәяси, милли-дәүләт үсеше, бу юнәлештәге актуаль мәсьәләләргә караган 100дән артык фәнни хезмәт бастырып

чыгарды. Аның эшләре галимнәр һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан хаклы рәвештә югары бәяләнде. Филология фәннәре докторы, профессор, татар факультеты деканы язучы Т.Н. Галиуллинның коллегалары белән үзара сөйләшү барышында әңгәмәдәшләренә Рәмзи Кәлимулловичның үз язмалары геройларын образлы һәм ышандырырлык итеп тасвирлау осталыгын билгеләп үтүе күңелгә уелып калды. Сүз «Фаҗига» китабы герое Галимҗан Шәрәф турында бара, авторның «Черек күл» паркын, шундагы эскәмияләрнең берсендәге Галимҗанны, аның яшәеш турындагы авыр уйларын җанландырып сурәтләве мисал ителгән иде.

Р.К. Вәлиев гомере буе вакытлы басмалар белән актив хезмәттәшлек итә, тарихи белемнәрне популярлаштыруга күп көч куя. Аның мәкаләләре «Звезда Поволжья», «Мәдәни җомга» газеталарында, «Гасырлар авазы-Эхо веков», «Казан утлары», «Мәгариф», «Мирас», «Безнең мирас», «Туган җир. Родной край» журналларында дөнья күрде һәм басыла тора. Олпат галимнең үз фәнни эзләнүләрен алга таба да киңәйтә һәм тирәнәйтә барачагына шик юк. Пандемия чоры «торгынлыгында» – 2020–2021 елларда, нәшер ителгән «Горная сторона ... Наше время» һәм «Борьба за национальную государственность: начало XX века» китаплары шуны раслап тора. Шуларның беренчесен, Р.К. Вәлиевнең тормыш һәм иҗат юлына, нәсел тарихы, гаилә-туганлык мөнәсәбәтләренә багышланганын аерым бер кызыксыну белән кулыма алдым. Китапның эчтәлеге күзалланганнан киңрәкне колачлый булып чыкты. Сюжет сызыгы авторның туган җире – Тау ягы, университет дуслары һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең төп юнәлешләренә кагылышлы фактлар белән үрелеп бара. Китапның ахырында Рәмзи ага шигырьләре урнаштырылган, арадан берсе дөньядан вакытсыз киткән хатыны Люция Сафиулла кызына багышлана. Китапларның икенчесенә килсәк, анысы башлыча гомерләре Россия тарихының текә борылышларына туры килеп, иҗтимагый-сәяси вакыйгалар «тегермәненә» эләккән шәхесләргә багышлана. Китапның идея эчтәлеге ике төп төшенчә: «татарлар» һәм «милли-дәүләт төзелеше» тирәсенә туплап бирелә, автор татар милләтенең һәм Татарстанның суверенлаштырылу этапларын шуларга нигезләнеп аңлата. 2022 нче елда галим милли тематикалы тагын бер хезмәт әзерләп, нәшриятка тапшырды. Хәзерге вакытта ул туган авылы Карашәм тарихын язу белән мәшгуль. Китап «Исәнме син, Карашәм» исеме белән дөнья күрер, дип уйланыла.

Кайтып-кайтып остазымның яшәү фәлсәфәсе турында уйланам. Соңгы очрашуыбызда ул, нәсыйхәт биргәндәй, Конфуцийдан отып, үзе яши-яши төшенгәннәрне үз сүзләребезгә күчереп кабатлады: «Дөрес яшим, дигән кеше тормышта өч нәрсәдән сакланырга тиеш: яшь чакта, дәрт-ярсу ташып торганда, хатын-кыз белән мавыгудан; тормыш иткәндә,

көч туплагач, көнләшүдән; картлыкта, көчләр саекканда, саранлыктан». Гомер юлыңның кайсы чорында ишетсәң дә, уйландырырлык фикерләр.

Рәмзи Кәлимулловичның узган гомерен күздән кичерсәк, аны фәнгә алып килгән юлның шактый ук катлаулы булуын күрербез. Ут Татарстанның Яшел Үзән районында урнашкан татар авылы Карашәмдә, күп балалы (Альберт, Дамир, Рәмзи, Ринат, Фәрит, Фәридә, Хәмит) гаиләдә дөньяга килә. Әтиләре Кәлимулла Миңнулла улы һәм әниләре Шәмсекамәр Низаметдин кызы – гади хезмәт белән көн күрүчеләр – үз заманының алдынгы карашлы, халкыбызның тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре, кече ватан, ягъни нәселләре береккән төбәкнең үткәне белән кызыксынып яшәүче кешеләр була. Алар балаларын да шул рухта тәрбияли. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Рәмзи Вольск авиация училищесына укырга керә. Училищеның ике курсын тәмамлагач, алга таба укуын бәлки шул юнәлештә дәвам итәргә кирәктер, дигән уй белән ул Казан авиация техникумы, Казан авиация институты белән танышып кайта. Әти-әниләренең исә аны инженер итеп күрәселәре килә. Әмма егетнең күңеле тарихка тартыла. Үткәннәр белән мавыгуын, бәлки, Карашәмнең тирә-ягындагы җирләр белән бәйле, татарларның борынгы бабаларыннан калган әкияти хәзинә һәм аның сакчылары – батырлар, алыплар, җеннәр турындагы риваятьләр дөрләтеп торгандыр? Ни булса, шул була, ул документларын Казан университетының тарих факультетына тапшыра, укырга кабул ителә һәм университетны уңышлы тәмамлап чыга. Рәмзи Вәлиев тикшеренүче-тарихчы юлын сайлый. Күрәсең, язмышына ук шулай язылган: көнчыгыш календаре буенча, үгез (сыер) елында дөньяга килгән кеше максатчанлык, эшлеклелек, батырлык һәм тәвәккәллек сыйфатларына ия булып туа. Аңа җаваплылык хисе һәм тәртип, намуслылык, хезмәт сөючәнлек, сабырлык һәм яхшы күңеллелек, шулай ук алдынгы идеяләрне тормышка ашырырга омтылыш, ышандыра белү көче хас.

Рәмзи Кәлимуллович үзенең иптәшләренә, университеттагы хезмәттәшләренә (И.Р. Таһиров, Ә.Г. Мөхәммәдиев, Р.Г. Хәйретдинов, И.И. Шәрифҗанов һ.б.) карата һәрчак ихлас дус булды, кайгыртучанлык күрсәтте. Еллар узып, ул инде мәшһүр галим булып җитлеккәч тә сыналган мөнәсәбәтләр үзгәрмәде, ул аларның һәркайсына элеккечә шат, һәркайсы алдында йөзе ак булды. Аның ТР Фәннәр академиясендәге гадәти, әмма аның дуслары өчен бик мөһим бер утырышта, икесе дә тарих фәннәре докторы, икесе дә профессор Ә.Г. Мөхәммәдиев һәм Р.Г. Хәйретдинов кандидатураларын академиянең мөхбир әгъзасы гыйльми дәрәҗәсенә тәкъдим итү барышында ясаган чыгышы турында берничә кешедән ишеттем. Тарих факультеты деканы буларак, ул аларның икесенә дә уңай һәм тулы характеристика бирә. Чыгышын исә «кешеләргә

исән чакта кадер күрсәтергә кирәк», дигән сүзләр белән тәмамлый. Кызганыч, утырышта аның хуплавын алган галимнәрнең икесе дә бүген инде арабызда юк. Ә бит Р.К. Вәлиев ТР ФА мөхбир әгъзасы дәрәҗәсе өчен үзе дә көрәшә алган булыр иде. Ул шулай эшләргә хаклы һәм ресурслары да җитәрлек иде. Әмма Рәмзи аганың моны һичкайчан үкенечкә санамавын аңлау өчен аның шәхесен белү кирәк. Ул вакытта әлеге гыйльми дәрәҗәгә аның дусты Әзһәр Гатаулла улы Мөхәммәдиев лаек дип табылды.

Рәмзи Кәлимуллович Вәлиевнең фән дөньясындагы юлы сикәлтәләрсез генә тәгәрәмәде. Партия идеологлары арасыннан һәм сәяси дулкын өскә калкыткан галимнәрдән кайберәүләрнең аны, А.А. Бенигсен, Ш. Лемерсье-Келькеже кебек «совет дошманнары» белән бер рәткә куеп, тәнкыйть утына тоткан вакытлары булды. Югыйсә, бүгенге көн күзлегеннән югарыда телгә алынган Көнбатыш Европа галимнәре хезмәтләрендә искитәрлек һични юк: аларда совет милли-дәүләт төзелешенә һәм дәүләтдин мөнәсәбәтләренә бары башка ракурстан карап – «Көнбатыш Европа либерализмы» критерийларыннан чыгып, бәя бирелә. Ә ул вакытта исә «большевиклар буржуаз хакимият органнарында эшләгән», дип раслаучы В.В. Адамов, Э.Н. Бурджалов, Р.К. Вәлиев кебек галимнәргә «фәннең партиялелеге» идеологлары һәм «тарафдар» галимнәр ягыннан тәнкыйть уты ябырыла иде. Шуның нәтиҗәсендә Рәмзи Кәлимуллович аның хезмәтләреннән «Көнбатышның зарарлы йогынтысын» һәм «советларга каршы коткы» эзләү белән мәшгуль идеология фронты хезмәткәрләре һәм шул сәяси дулкындагы галимнәр өчен «персона нон грата»га әверелә. Фәнни җитәкчесе, «троцкистчы» тамгасы тагылган Ә.Х. Борһановка бәйле хәлләрнең күләгәсе дә төшми калмый аңа. Юбиляр җитәкчесенә мөнәсәбәттә шулай ук Конфуций традицияләренә таянуны хуп күрә: «Күралмыйсың икән – димәк, җиңелүгә дучар булгансың». Бу күңелсезлекләр ике араны суытса да, Рәмзи Кәлимуллович Ә.Х. Борһанов белән элемтәсен өзми, аңа мәкаләләр дә багышлый. Фәнни җитәкчесенең вафатыннан соң, галим турында бары яхшы якларын гына искә алып язылган бердәнбер язманың авторы да ул булды дип беләм.

Әйе, Рәмзи ага үз язмышында нинди генә роль уйнамасыннар, остазларына, укытучыларына карата һәрвакыт рәхмәтле була белде. «Борьба за национальную государственность: начало XX в.» китабының ахыргы бүлекләренең берсен («Укытучым турында сүз» – «Слово об учителе») ул тулысынча остазларының берсенә багышлый – анда үтә җылы итеп тарих фәннәре докторы, профессор Иван Михайлович Ионенко турында яза. «Егылмаган бөек түгел, егылганнан соң торып баскан бөек» (Конфуций). Югарыда бәян ителгән күңелсез хәлләр сәбәпле, тарихчы галим Рәмзи Вәлиевнең докторлык диссертациясен яклавы 10 елга кичекте-

релә. Бу хәлләрне бик авыр кичерсә дә, ул диссертация өстендә эшләүдән туктамый. Бу эштә аңа дус-коллегалары, шулай ук тормыш юлдашы зур терәк-таяныч була. Тирән күңел төшенкелегеннән аны нәкъ менә Люция ханым коткара. Һөнәре белән медик, ул ирен җәйне үзенең туган ягында – Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы Карамал авылында уздырырга күндерә. Шулай бервакыт, 1990 нчы елларда, безнең Бөреледәге бакчабызга килгәч, Рәмзи ага, табигатьнең савыктыргыч көчен раслап, үзенең шул җәен, андагы сахралар белән хозурлануын, урман сукмаларыннан атлавын, яңа савылган сөтнең баллырак тәмен, урман һәм дала үләннәре кушып пешерелгән чәйнең хуш исен сагынып һәм рәхмәтләр белән искә алды. Конфуций мең мәртәбә хаклы: «Авыр хәлгә төшсәң – табигатьне тыңла. Җиһанның тынлыгы миллионлаган кирәксез сүзләрдән ныграк тынычландыра». Шунда, табигать кочагында, ихлас һәм эчкерсез авыл кешеләре арасында көч туплап, ул көрәшен дәвам итте.

Әйе, егылганнан соң торып баскан кеше бөек! Табигатьнең сихәтләндергеч көче турында Рәмзи Кәлимуллович бүген дә онытмый. Ул күбрәк шәһәр читендәге йортында яши, берничә умарта оясы тота. Пандемия вакытында хәтта тавыклар да алып җибәргән һәм үз хуҗалыгыннан файда күрүенә ихлас сөенеп, көн итеп ята. Ул мине дә тавыклар алырга каткат кыстап карады, хәтта умарта бүләк итәргә вәгъдә бирде. Аның күңел күзе һәрнәрсәдә матурлык күрергә күнеккән. Ул да, Конфуций кебек, «бар нәрсәдә матурлык бар, әмма аны һәр кеше дә искәрми генә», дип ышана. Рәмзи ага үзен бәхетле кеше дип саныйдыр, дип уйлыйм. «Сине аңласалар, бу – бәхет, сине яратсалар – зур бәхет, әгәр инде үзең яратасың икән – менә монысы чын бәхет» (Конфуций). Ул корган йорт – барлык мәгънәдә җылы йорт. Хатыны Люция Сафиулла кызы Казан медицина институтының дәвалау факультетын тәмамлаган табибә, билогия фәннәре кандидаты дәрәҗәсендәге галимә, биотехнология өлкәсендәге ике патент авторы иде. Тормыш катлаулылыклары аркасында аңа уңышлы башланган фәнни юлын дәвам итү насыйп булмый. Аның өчен гаилә һәм иренең карьерасы беренче урында булды. Авырып, тормыштан вакытсыз киткән Люция ханым иренең фәндәге юлы югарыга таба үрләсен, ул гыйльми дәрәҗәләргә ирешсен һәм үзенә лаек вазифаларга ия булсын өчен барысын да эшләде. Р.К. Вәлиев Россиянең һәм Татарстанның абруйлы галимнәреннән берсе булып танылган икән, монда аның бу дәрәҗәгә ирешүе табигатьтән бирелгән таланты, үзенең тырышлыгы һәм асыл сыйфатларына өстәп, хатыны тудырган шартлар бәрабәренә дә ирешелгән дип аңларга кирәк.

Бүгенге көндә ул кызы Эмилиянең уңышларына сөенеп яши. Эмилия Рәмзи кызы Вәлиева Казан медицина институтын уңышлы тәмам-

лап, башта кандидатлык, аннары докторлык диссертацияләре яклады. Медицина фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры, Эмилия Рәмзиевна кешеләр белән эшләргә әтисенә карап өйрәнүен, горурланып әйтә: «Әти – минем өчен бар нәрсәдә идеал. Ата идеалы, ир-ат идеалы, гаилә алып бару, мөнәсәбәтләрне көйләү, балалар тәрбияләүдә үрнәк. Ул – көчле, яхшы күңелле һәм гадел кеше иде. Аның кайчан да булса тавышын күтәргәнен ишеткәнебез булмады. Дөньядагы иң яхшы андый әти турында хыялланып кына буладыр». Остазыбызның кадерле оныгы, Казан федераль университетының юридик факультетын тәмамлап, инде кандидатлык диссертациясе якларга өлгергән Айгөл дә әни булды: бабасын дәү бабай итеп, Азалина исемле кыз бала алып кайтты.

Тормыш шулай дәвам итә. Рәмзи Кәлимуллович инде менә 50 елдан артык Казан федераль университетында укыта. Аның шәхесе элеккечә иң элек үзенә, аннары башкаларга карата таләпчәнлеге янәшәсендәге кешелеклелеге, идеяләре һәм белемнәре белән уртаклашырга әзер торуы, урынлы киңәшләре, мавыгып эшләве, ачык һәм ихлас булуы, намуслылык һәм принципиальлек кебек сыйфатлары белән үзенә тартып тора. Ә студентлардан (түбәндә Интернет заманы студентлары фикере) ул гомер буе менә мондыйрак сүзләр ишетеп яши: «Рәмзи Кәлимович, Сез факультеттагы иң шат күңелле һәм шаян укытучы, озак вакыт декан булгансыз. Тыштан гади күренсәгез дә, Сез факультет һәм тарих фәне өчен күп эшләгән бик кызыклы кеше. Барысы өчен рәхмәт Сезгә!!! Сезнең студентларыгыз!!!»

Университеттагы коллегалары, фән дөньясына кертеп җибәргән шәкертләре, элекке һәм бүгенге студентлары Рәмзи аганы чын күңелдән юбилее белән котлап, аңа иҗади һәм фәнни уңышлар, оптимизм һәм энергия, уйлаганнарының тормышка ашуын, шулай ук сәламәтлек һәм бәхет телиләр.

*Р.В. Шәйдуллин, тарих фәннәре докторы, профессор,*
*ТФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү*
*институтының Энциклопедистика үзәге мөдире*

## ПСИХОЛОГ, ФИЗИК, ФИЛОСОФ...

### Юбилей мөнәсәбәте илә



